Безнең Мирас

НАШЕ НАСЛЕДИЕ

11

ноябрь 2021

ISSN:2500-011X

КЫЗЫКЛЫ ТАБЫШЛАР ● КАДЕРЛЕ ИСТӘЛЕКЛӘР ● ГЫЙБРӘТЛЕ ЯЗМЫШЛАР

МИРХӘЙДӘР ФӘЙЗИ

Корыч эретүнең «Татара» ысулы: тарих һәм технология

17 бит

Яңгыр астындагы мәхәббәт

84 бит

Каләм! Кальбеңдә ни сер бар – гаян ит,
Килеп кичмешләр әхвален бәян ит.
Дәрдемәнд

Безнең МИРАС
12 +
11
(335)
ноябрь 2021

Фәнни-популяр, әдәби-нәфис
һәм документаль журнал

1991 елның апреленнән башлап «Мирас», 2012 елның маеннан, «ТАТМЕДИА» АҖ тарафыннан кабат гамәлгә куелып, «Чын мирас» исемнәре белән чыкты. 2014 елның маеннан «Безнең мирас» итеп үзгәртелде.

34

Баш мөхәррир
Лемон Лерон улы ЛЕРОНОВ (Ләбиб Лерон)
(843) 222-09-83 (17-92)

Баш мөхәррир урынбасары
Фирдәвес Зарифуллин (Фирдәвес Зариф)
(843) 222-09-83 (17-93)

Киңәшче идарә

Ирада Әюпова
(ТРның мәдәният министры)
Айрат Зарипов
(ТР Дәүләт Советының Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе)
Айдар Сәлимгәрәев
(«Татмедиа» Республика Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе)
Васил Шәйхразиев
(ТР премьер-министры урынбасары, БТК Милли Шурасы рәисе)

Редколлегия

Альберт Борһанов
Разил Вәлиев
Рәдиф Җамалетдинов
Фәнзилә Җәүһәрова
Ильяс Җиһаншин
Фәйзелхак Ислаев
Зиннур Мансуров
Хатыйп Миңнегулов
Ким Миңнуллин
Рүзәл Мөхәммәтшин
Данил Салихов
Индус Таһиров
Данис Шакиров
Илдар Шәфыйков

Җаваплы мөхәррир
Ленар Гобәйдуллин
89196911406

Дизайнер һәм биткә салучы
Алмаз Фәйзуллин
(843) 222-09-83 (17-92)

Мөхәррир
Ләйсән Данилова
(843) 222-09-83 (17-91)

Сайт мөхәррире һәм корректор
Энҗе Хөсәенова
(843) 222-09-83 (17-93)

SMM-белгеч
Ләйләгөл Сафина
(843) 222-09-83 (17-92)

Редакция һәм нәшрият адресы:
420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт
Электрон почта: **yanamiras@mail.ru**
Сайт: **beznenmiras.ru**

**«Безнең мирас» (Наше наследие)
Ежемесячный научно-популярный, литературно-художественный журнал
(на татарском и русском языках)**

Эчтәлек

ДӨНЬЯДА СҮЗЕМ КАЛЫР...

3 Ибраһим Гази

ТАРИХИ МИРАС

4 Кем ул Гуркин? *З.Мөхәммәтшин*
7 Рәссам вә мосаувир татар. *И.Бикколов*
10 Алтайның атаклы рәссамы. *Л.Лерон*
14 Коточкыч ачлык. *Р.Шәрәфиева, Л.Гобәйдуллин*
17 Корыч эретүнең «Татара» ысулы: тарих һәм технология. *Я.Муракамии*
20 Кыр Бикшиге авылының Татарстан халкы белән туганлыгы. *Н.Каштанов*
26 Татар хәйрия җәмгыятьләре. *Җ.Миңнуллин*
34 Имеш, мин чын-чын шагыйрь... *М.Госманов*

Чыганак-текстларда авторларның стиле, шул чор лексикасы һәм орфографиясе саклана.
Мәкалә авторларының фикере редакция фикере белән туры килмәскә дә мөмкин. Редакциягә юлланган язмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Материаллар бары тик электрон вариантта гына кабул ителә. Журналга кергән язмаларны һәм фотоларны редакция рөхсәтеннән башка күчереп бастыру тыела.
Типография гаебе белән киткән хаталар өчен редакция җавап бирми.
Андый хаталар булса, техник контроль бүлегенә 519-44-61 телефоны белән хәбәр итә аласыз.

Бу санда Л.Гобәйдуллин, Л.Лерон төшергән, авторлардан һәм «Татар-информ»нан, Татарстан Милли музееннан, «Татар энциклопедиясе» томнарыннан, җиде томлык «Татар тарихы»ннан алынган фотосурәтләр файдаланылды.

Төзәтмә. Журналның 10 нчы (2021) санындагы 3 нче биттә, техник сәбәпләр аркасында, хата киткән. Журнал укучылардан гафу үтенеп, Мөдәррис Әгъләмовның туган һәм вафат булган елларын 13.10.1946-26.11.2006 дип төзәтеп укуны сорыйбыз.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыятенең «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды. Адресы: 420066, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.

ТАТАР ГАМЕ

40 Казаковлар мирасын саклыйк!
50 Эстәрлебаш дарелфөнүне. *З.Зәйнуллин*
54 Наил Вазыйхов: «Яшьләрне авылда калдыру – мөһим мәсьәлә»
59 «Безнең мирас» котлый!

ДИНИ МИРАС

60 Ислам дөньясы. *Габдерәшит Ибраһимов*
66 Дин дәресләре. *С.Бикбулат*

ӘДӘБИ МИРАС

68 Бөек шагыйребез Котб әсәренең Истанбул басмасы (1968). *Х.Миңнегулов*
70 Соклангыч шәхес иде. *Э.Шәрифуллина*
72 «Ихласым бик дан – милләт юлына». *Ш.Юзеева*
76 Безнең авыл. *И.Гази*
82 Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләре
84 Яңгыр астындагы мәхәббәт. *И.Гази*
85 Кыйсса итеп сөйләрлек. *А.Хәмзин*

ХӘТЕР САНДЫГЫ

87 Остазларым белән горурланам. *Ә.Хәйри*
92 Кара тәкъдир. *Р.Батулла*
94 Мирасыбыз хәзинәсенә бөртекләр. *И.Низамов*
99 Мирхәйдәр Фәйзи кабере – Баймакта
100 Истә, һаман да истә!

СӘНГАТИ МИРАС

102 Алтын йөрәкле кеше. *Ә.Зарипов*
108 «Бөдрә тал» җыры
110 Татар җырчылары. Кадерле мизгелләр. *З.Гыйльметдинова*

ШАЯН МИРАС

112 Көлке куа килә...

БАЛАЧАК МИРАСЫ

114 Без барыбыз да – балачактан

116 «Безнең мирас» хәбәрләре
118 Мирасворд
119 «Безнең мирас» елъязмасы. *Ноябрь*

Заказ №Е-3500. Тираж – 3217 данә. Формат 70x100 $^{1}/_{16}$
Басарга кул куелды: 27.10.2021. Чыгу көне: 02.11.2021.
Айга бер тапкыр чыга. Бәясе ирекле.

Журнал 2012 елның 17 апрелендә Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ПИ №ФС77-57844 нче таныклык белән теркәлде.

Тышлыкның беренче битендә: Мирхәйдәр Фәйзи

Җирдә яралган – җирдән аерыла алмас.

Ибраһим Гази

Рәсемдә (фотофрагмент): алда утырганнар – язучы Ибраһим Гази, язучы һәм журналист Саимә Ибраһимова; артта басып төшкәннәр – шагыйрь Ренат Харис, журналист Хәмзә Зарипов, рәссам Тавил Хаҗиәхмәтов. 1960 нчы еллар ахыры.
Фото Саимә Ибраһимованың гаилә архивыннан

ИБРАҺИМ ГАЗИ

(4.02.1907-21.02.1971)

***

Яшьлек игътибарсыз була.

***

Теләнчене беренче башлап эт каршылый. Эт тавышын ишеткәч кенә, хуҗа башын тәрәзәгә тыга. Сакаллы баш булса, өмет итмә инде, яулык бәйләгән баш булса, өмет бар. Хатын-кыз кызганучан, буш кул белән борып чыгармый.

***

Кешедә беткән, бездә булганы да юк.

***

Дан дигән хәерсез нәрсәне мин ярга яккан учакка тиңләр идем: чыбык-чабык салгалап тормасаң, учак сүрелә, сүнә.

***

Дан кагылса, кайберәүләр шашынып китүчән була.

***

Ике малай сугышкан чакта канаган җир дә, күгәргән җир дә булмый калмый.

***

Хәзерге заманда гына ул китап күп. Авыл саен китапханә, мәктәпләрдә дә китапханә... Без малай чакта алай түгел иде. Китап бик кадерле иде. Әти базарга чыгып киткәндә: «Китап алып кайтырмын», – дисә, ул көнне җанга тынычлык бетә иде инде. Кайчан кайта, дип, алып кайтамы, дип, әллә таба алмыйча буш кул белән кайтып керәме, дип, көн буе ут йотып тора идем. Юлга әтинең каршысына чыгып торулар, кулга китап эләккәч, куанычтан сикеренүләр, китапны тышлаулар, кадерләп укулар... Хәзерге яшьләр андый рәхәтне беләләрме икән?

***

Бүгенге әти-әниләр баланың төпченеп сорашуларына түземлелек белән дөрес җавап бирсәләр, бәлкем, балага ун ел буе мәктәпкә йөрүнең кирәге дә калмас иде. Профессия сайлаганда да аптырамас иде.

*Текстны журналга **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Кем ул Гуркин?

Зөфәр Мөхәммәтшин

Г.Чорос-Гуркин (1870-1937)

Татар халкының сынлы сәнгатьтә беренче адымнары, нигездә, XX гасыр башы иҗтимагый хәрәкәтендәге үзгәрешләр тәэсирендә формалаша башлый. Татарлар арасында китап күчерүчеләр, каллиграфик язу белән шөгыльләнүчеләр һәрвакыт булган һәм алар мөселман дөньясында билгеле урын тотканнар. Бу очракта гарәп хәрефләре белән язу сәнгатенең алдынгы урында торуы сынлы сәнгатьнең формалашуы һәм үсешендә төп фактор булуына да игътибар итү кирәктер. Каллиграфия – мөселманнарда рәсем сәнгатенең башы. Аның катлаулы алымнары белән төрле сурәтләр тудыра алу шәхеснең зур таланты булуын таләп итә. Димәк, тарихи аспекттан чыгып фикер йөрткәндә, милләтнең милли сәнгате күпкә алдарак туган дип карарга мөмкин.

Татар сынлы сәнгать тарихын өйрәнүчеләр аның юл башын XX гасыр башы белән чиклиләр. Татар матбугатында сынлы сәнгатькә карата язылган борчулы язмалар, татарлар арасында беренче һәвәскәр рәссамнар хакында мәгълүматлар дөнья күрә. Тукайның, Фатих Әмирханның матбугатта басылган язмаларында татар рәсем сәнгатенә мөнәсәбәтле борчылу фикерләре һәркемгә мәгълүм.

Г.Ибраһимовның 1915 елда «Аң» журналы бастырып чыгарган «Альбом (сәнаигы нәфисә мәҗмугасы)» җыентыгына «Альбом мөнәсәбәте белән бер-ике сүз» дигән кереш мәкаләсендә аның сынлы сәнгать тарихына уңай һәм шул ук вакытта борчулы фикерләре ачык чагыла. **Б.Урманче** билгеләп узганча, татар һәвәскәр рәссамнары тарафыннан 1912-1913 нче елларда татар мәдәнияте тарихында беренче тапкыр портретлардан торган күргәзмә дә оештырыла. Рәссам: *«1912-1913 нче елларда булса кирәк, Казан «Шәрык китапханәсе»ндә бер кечкенә күргәзмә оештырылган иде. Аның экспонатлары кара (прессланган күмер булса кирәк) белән бер табак стандарттан рәсем кагәзендә ясалган татар әдипләренең (Тукай, Әмирхан һәм башкалар) унлап портреты иде. Боларның авторы Яхшыбаев, тагы берәүсе бар иде. Аның аты (исеме) исемдә калмаган»,* – дип яза әлеге күргәзмә турында «Казан сәнгать мәктәбе һәм ул заман» исемле мәкаләсендә.

Б.Урманченың татар сынлы сәнгать тарихына карата фикерләре турында сүз алып барабыз икән, югарыда искә алып киткәнчә, вакытлы матбугатта профессиональ һәм һәвәскәр рәссам хакында бирелгән хәбәрләрнең дә әлеге язмага кереп китүе комачау итмәс кебек. Мәсәлән, И.Бикколовның «Шура» журналында (1910 ел, 1 май, №9) нәшер ителгән «Рәссам вә мосаувир татар» исемле язмасыннан күренгәнчә, христиан динен кабул иткән Алтай татары Гуркинның Санкт-Петербург сәнгать мәктәбендә укуы әйтелә. Шулай ук аның мөстәкыйль рәвештә рәсем күргәзмәләре оештыруы да искәртелә. Соңыннан **И.Бикколов** аның белән татарча сөйләшүе хакында: *«Рус зыялылары арасында рәссам Гуркин җәнаблары илә татарча сөйләшеп йөрдекемдә, үземне, чыннан да, милли рәссамнарның милли картина выставкасында булган кебек хис иттегемне дә яшерә алмыйм»,* – дип искә алып үтә. «Йолдыз» газетасының 1911 елгы 19 июль (711 нче) санында исә Ерак Көнчыгыш аша Америкага сәяхәткә чыккан Кәлимулла Сәгъдинең «Ундүрт яшьлек рәссам» исемле язмасында да сынлы сәнгать белән шөгыльләнүче бала турындагы хәбәрдә: *«Казан губернасының Мамадыш өязендәге Тау Чөрулин (?) авылының Василий Панфилович Курманаевский** – *ундүрт яшьлек бала – Владивостокта бишенче сәнәдән (елдан) бирле тора икән. Аның атасы илә бертугма агасы үзенең книжная лавкасында хезмәт итәр өчен авылдан алып килгән икән. Ул баланы школага биреп укытучы, рәссамлыкка өйрәтүче булмаса да, үзеннән-үзе рәссамлык илә шөгыльләнеп, бик яхшы рәсемнәр төшерә башлагач, бу сәнәдә яз башыннан Владивостокта булган рәсемнәр выставкасында аның да өч кисәк рәсеме булып, халыкның дикъкатен җәлеп иткән. Шул чагында аның кабилиятен (сәләтен) Владивосток гәзитәләре мактап язганнар»,* – дигән юллар бар. Сәяхәтче һәвәскәр татар рәссам белән горурлануын да сиздереп куя. 1913 елда басылган «Аң» журналында Мәскәү сәнгать мәктәбендә укучы Хәдичә Акчуринаның берничә рәсемен күрергә мөмкин.

Мәгълүм ки, XX гасыр башында татарлар күпләп яшәгән төбәкләрдә – Уральск, Оренбург, Казан, Троицк кебек шәһәрләрдә сатирик журналлар басыла. Алар сатирик рухтагы рәсемнәр белән бизәп чыгарылган. Мәсәлән, Казанда дөнья күргән «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын бизәүче күренекле драматург һәм публицист Галиәсгар Камал булуы билгеле. «Мәктәп» журналының 1913-1914 нче еллардагы саннарында мәгърифәтче, дин эшлеклесе Салих Камалов балаларга рәсем ясау серләрен өйрәткән язмаларын урнаштыра. Б.Урманче «Сынлы сәнгать хакында бер-ике сүз» дигән күләмле мәкаләсендә Г.Камал һәм С.Камаловның татар сынлы сәнгате формалашу-

* *Василий Панфилович Курманаевский* – монда рус рәссамы Василий Панфилович Курманаевский (1894-1958дән соң) күздә тотыла.

Кышкы Катын елгасы. 1909 ел. ***Г.Чорос-Гуркин рәсеме***

ындагы роле хакында: *«...1905 ел революциясеннән соң бөтен мәдәни хәрәкәтебез борынгы шәрык кысаларыннан чыгып Европа ладына уңайлаша башлаган дәвердә, сынлы сәнгатьнең коры декоратив-бизәү кысаларыннан чыгып, сурәтләү сәнгатен ясау белән кызыксыну башлана. Беренче сурәтчеләребез Казан сәнгать мәктәбеннән ерак булган һәвәскәрләр булалар. Болар арасында иң әүвәл атаклы драматургыбыз Г.Камалны атарга кирәк. Аның «Яшен», «Ялт-йолт» сатирик журналларында чыккан карикатуралары, профессиональ кимчелекләренә карамастан, үзләренең үткенлекләре белән әле дә игътибарны җәлеп итәләр... Китап рәвешләгәндә зур хезмәт күрсәткән, озак еллар буе Оренбургта басылган күп китапларның тышларында очрый торган нәфис язучыларның һәм «Шура» журналының нәзек зәвык белән композицияләнгән һәм зур осталык белән язылган тышлыгының авторы Саләх Камал булырга тиеш. Саләх Камал соңгы елларда Казанда булды. Бу икәүнең рәсем техникасы белән танышулары Истанбул мәктәпләрендә булса кирәк»,* – дип яза һәм рәсем сәнгатендә карикатур, китап графикасы жанрларының остазлары нәкъ менә шул шартларда беренче адымнарын ясавына ишарәли. Болар – татар сынлы сәнгатендә беренче «буразна»ларны салучылар. Инде XX гасырның 10 нчы елларында һәвәскәрлектән һөнәри белем алуга да омтылышлар ясала, кайберләре сәнгать мәктәпләрендә уку бәхетенә дә ирешәләр. Б.Урманченың истәлекләрендә «Мөхәммәдия» мәдрәсәсендә укыганда дусты Габделхәй Богданов белән Казанның Россиядә даны таралган Императорская художественнная школасына керергә теләп ишек шакулары һәм христианнарның «Божий закон»ын белү кирәклеге ачыклангач, укуны онытып торырга мәҗбүр булулары хакында языла. Әмма шуңа да карамастан, рәссамның мәкаләләре һәм истәлекләре раслаганча, бу елларда Санкт-Петербургта Штиглиц сәнгать училищесында диплом алып чыккан татар яшьләре булган. Мәсәлән, Б.Урманченың «Сурәтчеләр» исемле мәкаләсендә алар турында мондый мәгълүмат бар: *«Берсе – XVIII гасыр вакыйгаларында чукынмый калган, шул сәбәптән фәкыйрьлеккә төшкән князь Дәүләткилдиев углы Касыйм. Бу рәссам Уфада торды һәм Башкортстан сынлы сәнгатенең нигезен салучыларның берсе булды. Икенчесе – Мирзаҗан ага Байкиев, Ленинградның җир йөзендә дан тоткан музейларыннан булган «Эрмитаж»ында скульптура бүлегенең консерваторы һәм баш реставраторы».* Рәссамның сынлы сәнгатькә багышлап язылган башка мәкаләләре һәм истәлекләрендә бу ике шәхес бары уңай яктан гына искә алына.

Татар халкының сынлы сәнгате формалашуының беренче этабы шулар белән тәмамлана. Икенче этап исә 1917 елгы Октябрь революциясеннән соңгы кискен үзгәрешләргә бәйле. ■

Рәссам вә мосаувир* татар

Ибраһим Бикколов

Г.Чорос-Гуркин

Журнал укучыларына Ибраһим Бикколовның Алтай татарларыннан булган Г.Гуркин хакындагы «Рәссам вә мосаувир татар» исемле мәкаләсен дә тәкъдим итәм. Күп кешедә: «Рус фамилияле Гуркинның татар сынлы сәнгатенә ни катнашы бар соң?» – дигән сорау туарга мөмкин. Алтайда төрки телле халыклар яшәгән, алар бүген дә, аз санлы булсалар да, Алтайда яшәүләрен дәвам итәләр. Чукынмаган мөселманнарга рәсем сәнгатенә тартылу тыелган. Гуркинның чукынган булуы һәм, Б.Урманче язганча, «Божий закон»ны белүе рәсем ясарга, үзен шул өлкәдә сынап карарга этәргеч биргән. Укучы бу мәкаләдән Алтай татарлары, Г.Гуркин турында беренче мәгълүматларны ала алыр дип уйлыйм. Кызыксынган кешегә башка чыганаклар белән танышу өчен дә юл ачар.

Зөфәр Мөхәммәтшин

---

* Мосаувир – сурәтче.

Алтайлылар (Алтай халыкларының көнкүреше). 1907 ел. ***Г.Чорос-Гуркин рәсеме***

Азия кыйтгасында Алтай таглары арасында Алтай татарлары исем илә мәгъруҏ *(горур),* тәкърибән *(якынча)* йитмеш меңләп татарлар тормактадыр. Бу татарлар әүвәлдән дөньяның иң иске дине булган «шаман» динендә булсалар да, соңгы гасырларда, русларның иҗтиһады саясында *(тырышлыгы нәтиҗәсендә)* 5 мең кадәресе христианлык кабул итмәктәдер. Шушы христианлык илә бергә бунлар арасында рус мәдәнияте дә тарала башлап, араларында урта вә гали *(югары)* образованияле яшьләр дә зоһур итмештер *(барлыкка килә, мәйданга чыга)*.

Алтай мәмләкәте, мәнзарә *(күренеш)* вә һава җәһәтеннән Сибириянең, бәлки, бөтен Азиянең иң беренче мәмләкәтләреннән булып, Аурупаның Швейцариясен вә италияннарны оялтырлык улдыкыннан рәссам вә шагыйрьләрнең ватаны улырга бәхакы лиякатьле *(лаеклы хак)* бер мәмләкәттер. Менә шуларга берникадәр Алтай зыялылары астыннан мөкаммәл рәссам исемен алырлык кешеләрнең йитешүе дәлил әүля белер *(нигездә яхшы белер)*. Түгел бөтен Алтай татарларының гына, хәтта бөтен Сибириянең мә биһилифтихары *(мактанырлык, мактанычлы)* улан рәссам Г.Гуркин җәнаблары шушы Алтай татарлары арасыннан заһир булынмыштыр *(килеп чыккан)*. Рәссам Гуркин чын Алтай вә Алтай татарлары булып, христианлыкны кабул идәрәк Алтайдагы Экзархиялный училищены тәмам итмеш *(монда Алтай дини миссиясе каршындагы иконалар ясау мәктәбе истә тотыла кебек. – З.М.)*, рәссамлыкка кабилиятьле *(сәләтле)* булыр кебек күренгәнгә, димләштерү буенча Петербург шәһәренә «художественный мәктәп»тә укымыштыр. *(Чыганаклар буенча Г.Гуркин Санкт-Петербург сәнгать академиясендә укымый, бары берникадәр вакыт аңа ирекле тыңлаучы сыйфатында гына йөри. – З.М.)*

Мәшһүр рус рәссамларыннан Шишкинның шәкерте булып, аның янында озак вакытлар каларак *(калып)* тәрсим *(рәсем)* эшендә мәһарәтен *(сәләтен, осталыгын)* арттырмыштыр. Шуннан соң Гуркин үзенең ватаны Алтайга кайтып, Алтай мәнзарәләрен һәм Алтай татарларының мәгыйшәтләренә даир *(тормышына караган, бәйләнешле)* рәсемнәр тәрсим итү илә шөгыльләнә башламыштыр.

Алтай хан. 1907 ел. *Г.Чорос-Гуркин рәсеме*

Гуркин үзе ир уртасы яшь кеше булып, садә генә һәм бик милли вә татарлыкны бик сөюче, христианлыкны кабул итсә дә, һич руслашмаган бер кешедер. Алтай яшьләренең күбесе миссионерлар мәктәбендә чын руслык вә христианлык рухында тәрбияләнеп, буның өстенә дә әдәбиятсыз бер милләт балалары булдыклары хәлдә мөтәгассыйб *(фанатик)* милли үзләренең шул ярым вәхши, милләте өчен ах итүләренә тәгаҗҗеб иттем *(гаҗәпләндем)*. Рәссам Гуркин картиналарын 1908 сәнәдә Сибирия шәһәрләрендә күрсәтеп йөрмеш вә Сибирия зыялыларының мәхәббәтене үзенә җәлеп итмеш иде. Бу сәнә янә картиналар күрсәтеп йөрергә чыгарак, Томскка килмештер. Март 3-15 кадәр Гуркин картина выставкасыны дәвам иттереп, Томскдан Сибириянең башка шәһәрләренә китте.

Бу сәнә күрсәттеге картиналары 50дән зыядә биек картина, 150дән зыядә этюдлар булып, Алтай мәнзарәләре, кыргыз вә татар типлары вә анларның тормышлары бик мөкаммәл бер гүзәл тәрсим ителмештер. Выставкага кергәч, беренче номерлы картина – «Каракүлнең язгы вакыты». Икенче номерлы картина – «Архит» *(монда Аргут елгасы истә тотыла кебек. Текстта елга исеме «Архит» рәвешендә язылган. – З.М.)* елгасының мәнзарәсе; сигезенче номерлы картина – «Алтай татарларының туй бәйрәмнәре»; йөз туксан икенче номерлы картина – «Мампи-рәис руханиның кәмләви мәрасим гыйбәдәте иҗра ителүе» *(«Мампи-рәис руханиның кәмләви йола гыйбадәтен үтәлүе»)* вә буннан башка халык телендәге легендаларга гаид *(караган)* картиналар вә мәңге кар илә уратлы *(капланган)* Алтай тагларының мәнзарәләре күренеп, инсанга хиссиятьләр *(кешегә тойгылар)* бирәләр.

Сибирия халкына *(мөселманнардан башка)* Гуркин бик таныш булып, аның картиналарын бик яраталар; выставка һәрвакыт халык илә тулы булган кебек, өч йөз вә биш йөз сумлы картиналарына кадәр ашыгып-ашыгып алалар. Бу ел Гуркин җәнаблары картиналарының күбесен сатмый һәм заказ да күп алмыйдыр. «Алтай эчләрен йөреп, тәрсим итәсе хидмәтләрем бик күп», – ди.

Безнең өчен дикъкать итәргә тиешлесе – әдәбиятсыз, мәдәниятсез Алтай татарларының берничә доктор вә адвокатлары арасында мөкаммәл бер рәссам йитештерүләредер. Гәрчә арамыз ераграк булса да, бу бердәнбер татар рәссамы безнең өчен дә мәдари ифтихар әүлә белер *(мактанырлык нәрсә булуын яхшы белер)*.

Рус зыялылары арасында рәссам Гуркин җәнаблары илә татарча сөйләшеп йөрдекемдә үземне, чыннан да, милли рәссамымызның милли картина выставкасында булган кебек хис итдегемне дә яшерә алмыйм. ■

Алтайның атаклы рәссамы

Ләбиб Лерон

Музей-утарда Г.Чорос-Гуркинга нисбәтле стенд

Узган ел сентябрь ахырында Буа дәүләт сатира театры җитәкчесе Раил Садриев белән миңа Таулы Алтайда (элекке исеме – Улала, Ойрот-Тура) булырга туры килде. П.В.Кучияк исемендәге Алтай милли театрында (баш режиссеры – Эмма Иришева) һәм рәисе Алтай Республикасының халык язучысы Бронтой Бедюров булган Язучылар берлегендә булып, театр әһелләре һәм язучылар Николай Багыров (ул театрда да эшли икән, очрашу вакытында «Син сазыңны уйнадың»ны бик шәп итеп җырлады), Таукен Яйтын (Б.Бедюровның урынбасары) белән очраштык. Музейлар белән дә таныштык. Хәтта Алтайның атаклы рәссамы Григорий Чорос-Гуркин (1870-1937) яшәгән Анос авылына бару, 2006 елның 13 гыйнварында Алтайның милли музее филиалы буларак ачылган Г.И.Чорос-Гуркин музей-йортын күрү дә насыйп булды.

Көндәлектән юллар:

«29 сентябрь, 2020 ел.

Иртәнге ашны ашагач, автовокзалга барып (урам аша гына чыгып), такси белештек. Виктор исемле алтайлы безне Челман (Чалман) тарафына алып китте. 80-90 чакрымлап ара. Аскат дигән авыл уң якта – килеп җитәрәк калды. Анос (алтайча – Онос, «әнчек өрүе» дигәнне аңлата) юлыннан барып, «Сибиряки» дигән турбазада тукталдык. Бездән башка кеше юк, чөнки монда сезон ябылган иде. Кешеләр булмавы безгә ошады анысы.

Ике катлы йортның икенче катына урнаштык. Эмма ханым Иришева алдан сөйләшеп куйганча, Алексей дигән егет сәгать бердә килде. Ул безне җәяүләп Анос авылына алып барды. Катунь (Катын, Хатын) елгасы буйлап бер утыз-кырык минут барганбыздыр.

Рәссам Григорий Чорос-Гуркин утарындагы музейда булдык. Шул музейның оештыручысы һәм экскурсоводы Евгений Тукуеков Алексейның икетуган абыйсы икән. Берсенең (Алексейның) әнисе белән икенчесенең (Евгенийның) әтисе бертуган.

Рәссам хакында бик кызыклы мәгълүмат алдык. Ул безнең Алабуга тумасы И.Шишкинның бердәнбер укучысы. Бөек рәссам 1998 елның 8 (20) мартында шәкерте кулында җан биргән. 1897 елның көзендә Санкт-Петербургтагы Сәнгать академиясенә белем алырга дип килгән Григорийга ул болай дигән булган: «Нәрсәгә сиңа Академия? Менә остаханә, мольберт, буяулар, киндер, кил һәм минем белән бергә эшлә!»

Г.Гуркин – фаҗигале язмышлы шәхес. Ул 1917 елда Алтай Республикасын оештырган, аның беренче рәисе булган. Репрессия корбаны. Бер улын үзе белән бергә атканнар. Ярый әле кызларына тимәгәннәр.

Рәсемнәре бик матур. Берме-икеме картинасы бездә – Казан музеенда да бар икән.

Алексей Ямановның (әллә Имановмы) абыйсы шәп сөйли – теле-телгә йокмый. Казанда да булганы бар икән. Безнең ике президент (М.Шәймиев һәм Р.Миңнеханов) белән дә күрешкәне бар. Аларны бик мактап сөйли. Безгә, Татарстанга, өметләнгәне сизелә. Озын сүзнең кыскасы, үз эшенең фанаты.

Музей үзе зур гына йортта урнашкан. Элек монда рәссамның остаханәсе булган дип аңладым...

Аностан кабат җәяү кайттык. Кайтуга, соцчелтәргә музейдан фотолар куйдым. Шул фотоларны күреп, университетта бергә укыган сабакташым, галим Зөфәр Мөхәммәтшин аңлатма биргән: «Гуркин татар бит ул! Алтайдан кайтуыңа Ибраһим Бикколовның Гуркин турындагы язмасын җибәрермен әле сиңа», – дигән...

Шаккаттым! Күңелле булып китте...»

1870 елның 12 гыйнварында Бийск өязендәге Улала авылында (хәзерге Таулы Алтай) туган, чыгышы белән чукынган татарлардан булган Г.Чорос-Гуркин әлеге Анос авылына 1903 елда килеп төпләнә, өйләнә, укытучы булып эшли һәм, үз акчасына утар төзетеп, гомеренең соңгы көннәренәчә (1903-1919 һәм 1927-1937 нче елларда) шунда яши. Рәссамның иң саллы әсәрләреннән булган «Алтай хан» (1907), «Тау иләре күле» (1910), «Катын тажы» (1910) картиналары биредә ясала.

Анос авылы Катын елгасының сул ягында – Иткай (Эткәй яки Эт башы) тавының итәгендә урнашкан. 1856 елда төзелгән бу авылда заманында күренекле язучылар, галимнәр Г.Н.Потанин, А.В.Адрианов, А.В.Анохин (рәссамга әлеге шәхеснең йогынтысы зур була, Алтай Республикасының Милли музее аның исемен йөртә),



Г.Чорос-Гуркин һәм аның музей-утары



Музей-йортка куелган язулы калай такта

Г.Чорос-Гуркинның музей-утарында. Евгений Тукуеков, Казан кунаклары – Раил Садриев, Ләбиб Лерон, Фидания Лерон һәм Эльмира Садриева. 29 сентябрь, 2020 ел



Корбан төне. Камлау (шаманлау). 1895 ел. *Г.Чорос-Гуркин рәсеме*

Г.Чорос-Гуркинның төрмәдә төшерелгән соңгы фотосы. 1937 ел

Г.Д.Гребенщиков, атаклы «Хәсрәт дәрьясы» («Угрюм-река») романы авторы В.Я.Шишков, Г.А.Вяткин еш булган.

Бүген Аноста якынча 420 кеше яши. Халык сыер һәм ат асрый, умартачылык белән шөгыльләнә, яшелчә үстерә, төрле дару үләннәре җыя. Урта мәктәп Г.Чорос-Гуркин исемен йөртә.

1906-1907 нче елларда Томск губернасының (ул вакытта аның составына Таулы Алтай да кергән) үзәге булган Томскида рәссам Гуркинның күргәзмәсе эшли. Аны Гуркин иҗатына мөкиббән булган сәүдәгәр П.И.Гадалов оештыра. 1906-1915 нче еллар эчендә рәссам үзенең күргәзмәсе («Алтай. Тау үзәне» (1909), «Иедыгым елгасы» (1909), «Каракол» (1909)) белән бөтен Себерне урап чыга һәм Себер рәсем сәнгатенең танылган классигына әйләнә. «Алтай хан» картинасын күргәч, географ һәм этнограф, Алтай фольклорын өйрәнүче Григорий Потанин (1835-1920): «Ниһаять, Себернең дә үз рәссамы булды», – дип, соклануын белдерә.

Г.И.Гуркинның Гражданнар сугышы вакытындагы сәяси эшчәнлеге 1918 елда аны кулга алуга бер сәбәп була. 1919-1925 нче елларда ул Монголиядә һәм Тувада мөһаҗирлектә (эмиграциядә) була. 1925 елда Таулы Алтайга – Анос авылына кайта, рәссамга йорты һәм остаханәсе кайтарып бирелә. Гомеренең ошбу чорында ул игътибарын мөгаллимлек эшчәнлегенә юнәлтә, беренче алтай әлифбасын бизәүдә катнаша, җирле халыкның гореф-гадәтләрен өйрәнә. Аның тәкъдиме белән Таулы Алтайда музей һәм Ойрот-Тура сәнгать мәктәбе ачыла. Әлеге мәктәптә ул шәкертләренә рәсем сәнгате дәресләре бирә.

1934 елда Новосибирск чекистлары, «Себер төркиләре берлеге»н советка каршы эшчәнлектә гаепләп, Г.Гуркинны кулга ала. Аңа 1932-1933 нче елларда Новосибирскига барып, Сакабэ дигән япон резиденты (консуллыкта эшләгән, имеш) белән очрашкан, дип гаеп такмакчы булалар. Беренче сорау алу вакытында ук Гуркинның Таулы Алтайдан беркая да китмәгәнлеге, Сакабэ дигән кешенең консуллыкта эшләмәве, ул гына да түгел, рәссамның хәтта паспорты да булмавы ачыклана.

1937 елның маенда алтмыш җиде яшьлек Гуркин янә кулга алына һәм, Япония белән хезмәттәшлек итүдә гаепләнеп, шул ук елның 11 октябрендә атып үтерелә. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

КОТОЧКЫЧ АЧЛЫК

СӘХИФӘ ИДЕЛ БУЕНДАГЫ 1921-1922 НЧЕ ЕЛГЫ АЧЛЫКНЫҢ 100 ЕЛЛЫГЫНА ҺӘМ АЧЫГЫП ВАФАТ БУЛГАН МӘРХҮМНӘР ИСТӘЛЕГЕНӘ БАГЫШЛАНА.

Ачлык нәтиҗәләре белән көрәш

ТАССР ҮБК рәисе урынбасары, ТАССР ХКШ рәисе урынбасары (1921-1923), ТАССР Ачларга ярдәм итү (Татпомгол) комиссиясе рәисе Исхак Мостафа улы Казаков (1876-1939)

Балаларны кайтару. ТатЦИК янында балалар тормышын яхшырту комиссиясе, быел ашлыкларның бертөрле ярыйсы булуы сәбәпле, ата-аналары яки кардәшләре булган балаларны авылларына кайтара башлады. Боларны кайтару өчен Татарстан мәгариф халык комиссариатына бер миллиард ярым акча бирелде.

Ач балаларның саны. Комиссия рәисе Исхак иптәш Казаковның җыйган мәгълүматларына караганда, хәзерге көндә Татарстан җөмһүриятендә атасыз-анасыз калган 30 мең ятим, атасыз яки анасыз 145 мең яртылаш ятим бала бар. Аларның һәммәсенә дәүләт тарафыннан ярдәм бирергә кирәк.

Балалар өчен кайгыру. Комиссия Казанда калган балалар өчен бик күп мәсариф *(чыгымнар)* тота. Соңгы вакытта балалар өчен хәзерләнә торган сабикъ *(элекке)* губернатор һәм архиерей йортларына электр әсбаплары алыр өчен – 4 миллиард сум, балалар йортларын төзәттерергә, саулыкны саклау һәм мәгариф халык комиссариатларына 3 миллиард сум бирелде. Аннан соң мәгариф халык комиссариатының мөәссәсәләрендәге *(оешмаларындагы)* балаларны киендерергә ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү комиссиясеннән – 59 мең аршин, саулыкны саклау халык комиссариаты мөәссәсәләрендәге балаларга 4 мең аршин мануфактура алынды.

Татарстан. – 1922. – 5 ноябрь.

Качаклар йорты

ТатЦИК янындагы ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү мәркәз комиссиясе Балык базары урамында ачлык качаклары өчен ачылган йортны Иҗтимагый тәэминат халык комиссариатына тапшырды. Бу йортка ачлык сәбәпле качып та, соңгы вакытта Казанга кайткан качаклар кабул ителәләр. Качаклар анда үз илләренә җибәреләләр.

Татарстан. – 1922. – 15 ноябрь.

Ач балаларны кабул итү пункты. Араларында татар балалары да бик күп. 1922 ел

Атлар китертү өчен җиңеллек

Татарстан җөмһүриятенең игенчеләре, ачлык сәбәпле, кимегән атларын тутырырга һәртөрле чаралар күрәләр. Шушы максат белән игенчеләр, үз араларыннан акча җыеп, чит вилаятләргә ат алырга китәләр.

ТатЦИК янындагы ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү комиссиясе бу тарика *(болай итеп)* ат алырга баручыларга тимер юлларда арзан хак белән китерергә шәһадәтнамәләр бирә. Беренче ноябрьдән 15енә кадәр ике атна эчендә 108 вәкилгә 11 000 ат китерергә шундый шәһадәтнамәләр бирелде.

Татарстан. – 1922. – 19 ноябрь.

Ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү

Ачлыктан зарарланган игенчеләргә ярдәм. Көз көне яңа ашлык өлгергәннән бирле Идел буенда һәм башка вилаятләрдә ачлыкны беткәнгә хисапларга ярый. Узган ел ачлык булган вилаятләрдә хәзер халыкның күбесе үз азыгын ашый башлады. Фәкать, инде хәзер ул ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү чараларын күрергә кирәк.

Бездә хәзер ачлыктан калган нәтиҗәләр шулар: ачлык сәбәпле иген чәчә алмый калган 350 меңләп хуҗалык, 2 миллионлап тәрбиячесез калган бала, 500 меңләп инвалид, 250 мең эшсез, мохтаҗлыкка төшкән 1 600 000 Кәсептәш Союзлары әгъзалары һәм 2 миллионлап ачлык сәбәпле качкан игенчеләр бар. Менә боларның һәммәсенә дә ярдәм бирергә кирәк. Болар, әлбәттә, ярдәмсез калдырылмаячаклар.

Ачлыктан зарарланган игенчеләргә эш хайваннары алу өчен, ачлык нәтиҗәләре белән көрәшү мәркәз комиссиясе суммасыннан 3 триллион, иген кораллары алу өчен 1 триллион акча бирелде. Дәүләт банкасы аркылы игенчеләргә хуҗалыкларын яңарту өчен 20 триллионлап бурыч бирелә.

Ач вилаятьләргә 1923 ел өчен көзлек чәчеп калдырырга 7 миллион пот чәчүлек бирелде.

Аннан соң быел үз ашлыклары белән тәэмин ителмәгән вилаятьләргә ярдәм итү өчен, казнадан 5 миллион пот ашлык билгеләнде. Мохтаҗ игенчеләргә азык белән ярдәм итү турында безнең Татарстан җөмһүрияте икенче дәрәҗә мохтаҗ вилаятьләр җөмләсенә кертелгән иде, шуңа күрә бундагы мохтаҗларга ярдәм гыйнвар башларында бирелә башлаячак.

Татарстан. – 1922. – 20 ноябрь.

Ачлык нәтиҗәләре белән көрәш

Эшсезлек белән көрәш. Ачлык нәтиҗәләре белән көрәш комиссиясе янында эшсезлек белән көрәш комиссиясе төзелде.

Бу комиссия ачлык булган вилаятьләрдә җәмәгать эшләре оештыру юлы белән эшсезләргә эш табарга чаралар күрәчәк.

Шулай ук нәсел хайваннарын да үрчетергә чаралар күрелә. Хәзерге көндә Татарстан җөмһүриятендә 137 баш үгез һәм айгыр хайван качыру пунктларының хаҗәтләрен үтиләр. Беренче номерлы фермада холмогор үгезе һәм башка төрле нәсел хайваннары бар. Спас кантонында ат заводы ачылды.

Татарстан. – 1922. – 21 ноябрь.

Мамадыш кантонында

1921 елның башында Сатыш авылында 401 йорт булып, хәзердә 300гә калган. Халыкның күбесе читкә киткән һәм ачлык вакытында үлеп беткән.

Уҗым басуы, ат юклыктан, 80 процентка чәчелгән. Сабан басуы мәйданы 570 дисәтинә булса да, бары тик 190 дисәтинә генә чәчелеп калган. Солы, бодай, арпа ярыйсы уңса да, карабодай, тары, җитен, киндер корылыктан һәртөрле кортлардан күп зарар иткән. Арыш саламы яхшы уңса да, орлыгы тук булмаган. Бер дисәтинәдән 8-9 йөз көлтә алынган, әмма орлык 3-4 поттан артык чыкмаган. Аның өстенә, җир дә бик балчыклы булганлыктан, аны тирес белән яхшыртырга кирәк булган.

Хәзер бик күп микъдар кыр тычканнары пәйда булган. Алар кибәннәргә оялыйлар. Шунлыктан халык ашлыкны тизрәк сугып бетерергә ашыга. Гадәттә, кибәннәр мартка кадәр саклана иде.

Саранчадан артык зарар булмаса да, шулай да йомырка салып калдырганлыгы беленгән.

Сабан орлыгына мохтаҗ кешеләрнең исемлеге төзелеп, кантон башкармасына бирелгән. Авылның яртысына орлык ссудасы сорала.

Мөхбир.

Татарстан. – 1922. – 17 декабрь.

*Текстны басмага **Рәйсә Шәрәфиева** һәм **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Корыч эретүнең «Татара» ысулы: тарих һәм технология

Ясуюки Мураками[1]

Япониядәге борынгы металл эретү мичләренең реконструкциясе

«Татара» («татар») – Көнбатыш Япониянең Чугоку төбәгендә буыннан-буынга тапшырыла барган традицион корыч эретү ысулы. Бу якларда тимер рудасы комы, урман ресурслары, энергия чыганагы булырлык күмер һәм мич кору өчен төп материал саналган кызыл балчык («масацучи») бик күп. Мондый шартлар Чугокуда «татара» үсешенә зур этәргеч биргән.

Металл эретүнең «татара» алымы XVII гасырда, Эдо чорында[2] формалашып беткән. Мичтән кала, башка җайланмалар да, биналар да («такадоно») шул елларда тотрыклы формаларын алганнар. Мич шакмак тартма рәвешендә салынган, өрдерер өчен ике ягына бихисап тишекләр тишелгән. Шлак һәм чуенны чыгару өчен мичнең ике ягында янә берешәр яисә өчешәр махсус тишек ясалган. Мичнең нигезенә корылган «токоцури» корылмасы аерым игътибарга лаек: ул җир асты суларын читкә агызырга ярдәм иткән.

«Татара» миче 2,5-3 метр озынлыктагы, 0,8-1,2 метр киңлектәге конструкциядән гыйбарәт. Истә калдырыйк: әле VI гасырда аның прототиплары иңгә-буйга нибары 50 сантиметр булган. Табигый, тимер җитештерү күләме арткан саен, мичне зурайту зарурлыгы да туган. Димәк, өрдерер өчен тишекләр саны да күбәйгән, мич астындагы «токоцури» да киңәйгән. Аның каравы, мичнең 1,5 метр биеклеге 1500 ел дәвамында үзгәрешсез сакланган.

[1] Ясуюки Мураками – Көнчыгыш Азиянең металл эшкәртү мәдәниятен өйрәнү үзәге директоры.
[2] Эдо чоры – Япониядә Токугава кланы идарә иткән 1603-1868 нче еллар аралыгы.

Борынгы металл эретү мичләренең реконструкциясе күренешләре һәм археологик табышлар

Ихтимал, мондый тәбәнәк мичтә югары сыйфатлы корыч һәм чуен эретү гаять читен булгандыр: артык кушылмаларны аерыр өчен металл озак вакыт аралыгында озын юл үтәргә тиеш. Осталарның тәҗрибәлелеге генә бу авырлыкларны җиңеп чыгарга мөмкинлек биргән, күрәсең.

«Татара» ысулында ике төрле эретү алымы бар. Беренчесе «кераоси» дип атала. Бу очракта тимер рудасы комы граниттан («масасецу») алына һәм «турыдан-туры» эретелә. Икенче алым – «дзукоси» – коелма тимер һәм югары карбонатлы корыч әзерләү өчен кулланыла. Аның мичләре «кераоси»некеннән кечкенәрәк тә, таррак та. Бу очракта тимер рудасы комын җитештерү өчен «акомесатецу» – базальт һәм андезит чимал булып тора.

Тартманы хәтерләткән мич, өрдерер өчен ике ягында бихисап тишекләр булу, мич астындагы шактый зур корылма һәм тимер рудасы комын файдалану – болар барысы да «татара» ысулының үзенчәлекләреннән санала. Бу технологиянең тиңе юк. Ул уникаль. Корея һәм Кытай мичләре белән чагыштырсаң, моңа тагын бер кат инанасың. Иң борынгы Корея миче төньяк-көнчыгыш Кытайда табылган. Безнең эраның III яисә IV гасырына караган бу мич цилиндр рәвешендә, 2 метрдан артык биеклектә. Өрдерү өчен торбасы да берәү генә. Эретү чималы – тимер рудасы. Япония һәм Корея тимер эретү технологияләре арасында аерма бихисап.

Аңа да карамастан, VI гасырда борынгы Корея осталары японнарны тимер эретергә өйрәткән дигән фикер һаман да яши. Яңа археологик табышларга нигезләнеп, без бу теориягә карашыбызны үзгәртергә тиеш, минемчә. Японнар безнең эраның 900 нче елларына кадәр тимер коралдан файдаланган, шуның 700 нче елларына кадәр бу коралларны җитештерү өчен чимал Корея ярымутравыннан яисә Кытайдан кайтарылган. Мондый шартларда японнарның металл эретү алымын үзләштерү эше белән гаять кызыксынуы табигый.

Тотрыклы теория рәвешендә тагын бер фикер яшәп килә әле. Японнар, имеш, иң элек турыдан-туры Корея белгечләре җитәкчелегендә металл җитештерү алымына төшенә алмаганнар. Аннары үзлектән Корея тимерен эретү технологиясен өйрәнә башлаганнар, тимерчеләрнең эшчәнлеген үзара яраклаштырганнар. Бу фараз да яшәргә хокуклы. Ул, һичьюгы, Корея ярымутравында һәм Япониядә металл эретүнең бөтенләй үзгә алымнары үсеш алуның сәбәпләрен аңлатырга мөмкин сыман. Моны әлеге ысулның «татара» («татар») дип аталуы да раслый. Мөгаен, әлеге ысул Кореягә татарлардан кергәндер.

Файдаланылган әдәбият:

1. Tawara Kuniichi. Ancient technique of the Iron Smelting using Iron Sand (Tatara Buki Iron smelting). Tokyo, 1933.
2. Kawase Masatoshi. Archaeological Research on the Technique and Structure of Tatara Buki Iron Production. Hiroshima, 1995.
3. Kakuda Noriyuki. Establishment and Evolution of Tatara Buki Iron Production. Osaka, 2014.
4. Murakami Yasuyuki. Archaeology on the Relationship between Ancient Japanese and Iron. Tokyo, 1999.
5. Murakami Yasuyuki. Ancient State Formation and Iron Production. Tokyo, 2007. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Кыр Бикшиге авылының Татарстан халкы белән туганлыгы

Нәкыйп Каштанов

Язучы, табиб, төбәк тарихын өйрәнүче, галим Нәкыйп Каштанов

Авыл ул, барлыкка килеп, үзенең яшәеш дәверендә дәүләтнең терәгенә әйләнгән. Ни өчен терәге? Авыл дәүләт гаскәренә егетләрен озаткан, хезмәткәрләрен ашаткан, киендергән. Шулай ук шәһәр кешеләрен дә ашаткан, киендергән, эшче куллар белән дә тәэмин иткән. Авыл кешесенең үзе турында сөйләп тә торасы юк: үзен-үзе дә ашата, киендерә, яшәү өчен бөтен кирәк-яракны, каралты-кураны, йорт-җирне дә булдыра. Бөек Ватан сугышы елларын алыйк: аның үзенә дә ашарына калмаган (ачтан үлүчеләрнең саны билгесез), җигәргә аты булмаган, техникасы да юк, бөтен көч-куәт фронтка азык-төлек, җылы бияләй һәм оекбаш, башка кирәк-яраклар җитештерүгә, корал ясар өчен акча җыюга кирәк... Билгеле, хәзерге заманда авылның яшәеше, вазыйфасы, сизелерлек үзгәрде. Ул турыда күп язып булыр иде, әмма язмам ул хакта түгел.

Авылның нигезен тәшкил иткән нәселләр, күпбалалы булып, аңа яшәеш биргәннәр. Бүгенге көндә күп кенә нәселләрнең авылда эзе дә калмаган: йә алар читкә киткән, яисә нәселе корыган. Нәсел тотрыклы дәвам итсен өчен, гаиләдә өч бала булу сорала. Хәзерге заманда бер генә балалы гаиләләр күп,

баласы ошбу дөньяны калдырып китсә, әти-әнисенең яшьләре бала табудан узган булса, нәселнең бу ботагы сынып кала, йә булмаса, нәселе бөтенләй бетә. Андый гаиләләр бүгенге көндә аз түгел. Өстәвенә, кияүгә чыкмаган кызлар, өйләнмәгән егетләр дә күп… Аның, билгеле, төрле сәбәпләре бар, ул бик мөһим мәсьәлә булып кала.

Авыллар күптөрле. Дөньякүләм билгеле булган җырчы, артист, композиторларны, әдипләрне биргән авыллар бар. Сабантуй көрәшчеләренә бай авыллар, галимнәрне, дин әһелләрен биргән авыллар халык телендә йөри. Илдә бай һәм ярлы, зур һәм кечкенә авылларны күрергә мөмкин. Һәрбер авылның үзенә генә хас кызыклы тарихы да бар.

Кыр Бикшиге авылын алсак, ул укымышлы авыл, Чуашстанда совет заманында укымышлылыгы буенча икенче урында иде. Бик күп фән докторларын, галимнәрне биргән авыл: Академик-химик Хәбиб Миначев – Казан һәм Нижнекамск химиклары белән ачышлар ясаган, дәүләт премиясе алган зат. Нәкыйп Каштанов – табиб, СССРның сәламәтлек саклау отличнигы, медицина өлкәсендә дөньякүләм мөһим ачышлар ясаган зат. Спорт мастерлары да аз түгел, көрәшчеләргә – Сабан туе батырларына бай иде авыл. Чинкин Сәетзадә – 24 мәртәбә Сабан туе батыры – тәкә откан олуг шәхес. Расыйх абый Камалетдинов СССР, Россия, Чуашстан буенча биш спорт төрендә чемпион титулы (бер генә мәртәбә түгел) яулаган шәхес иде. «Нәселебез Мәрҗәннәре» исемле китапка (2011) егермегә якын авыл шагыйрьләре кергән. Татарстанның дәүләт премияләренә лаек булган галимнәр һәм җитәкчеләр бар. Безнең авылдан Фәсхетдин Каштановның сеңлесе Миңнегаян апа һәм аның ире Хәлиулла җизни Әбелхановның (1938 елдан бирле Казакъстанда яшиләр) кызы Халидә Казакъстанның башкаласы Алма-Атада (элегрәк заманда), Татарстанның тулы вәкаләтле вәкиллегендә консультант булып эшләде. Шул ук вакытта ул музыка училищесында педагог, Татарстан һәм Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе; аның кызы да опера җырчысы, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. Шунысы да кызык: музыкага сәләте Абдерәхим Айсин нәселеннән бара, Миңнегаян апа аның нәсел «агачы»нда утыра. Шул ук «агач»тан, Абдерәхим Айсиннән – Тәфкил Хәмдиев, ул исә үз вакытында Алабугада институт тәмамлап, Мамадышта клуб мөдире булып эшләде. Бередә зур уңышларга ирешә Тәфкил, әмма колхоз рәисе чакыруы буенча, үз авылына – Кыр Бикшигенә кайтты. Монда аның җитәкчелегендә «Халык театры» оештырылды, ул театр хәзер дә, Тәфкил Хәмдиев инде үзе исән булмаса да, эшен дәвам итә. Авылыбыздан чыккан 3-4 прокурор да бар. Мәсәлән, Зәй районы прокуроры Шакир Ярахaнов. Авыл башка күптөрле һөнәр ияләренә дә бай: алдынгы тракторчылар, шоферлар, иген игүчеләр, терлек караучылар, сыер савучылар, агрономнар, вак-төяк әйберләрне – чәйнек, чиләк, киез итек, сәгать һәм башка нәрсәләрне төзекләндерүчеләр, оста тимерчеләр дисеңме… Татарстан җөмһүриятендә эшләүче ветеринарлар, инженерлар, механизаторлар, спорт тренерлары һәм башка төр һөнәр ияләре… Мәсәлән, билгеле шәхес олимпия чемпионын әзерләгән атказанган тренер Чинкин Миңнула да бар иде.

Бүгенге көндә авыл тарихын өйрәнүчеләр, язучылар аз түгел. Бу үзенчәлекле ачышларга да китерә. Мисал өчен, Кыр Бикшиге авылы тарихын архив материаллары нигезендә өйрәнгәндә, кызыклы гына ачышларга тап булдым. Сезгә үземә кагылышлысыннан берничәсен генә әйтәм: беренчедән, ике әбием дә (әтинең әнисе һәм әнинең әнисе) Салей Сулиевның нәсел «агачы»ннан бу-

лып чыкты, бу минем өчен көтелмәгән хәл иде. Үзара бәйләнеш сеңлемнең ире Салей Сулиевның өченче хатыныннан килә. Репрессия корбаны, олуг әдип, җәмәгать эшлеклесе, оештыручы, драматург Фәтхи Бурнашлар нәселе хатын-кыз ягыннан Салей Сулиевның оныгы (улы Әбделмәннең кызы, ул – безнең әнинең дә бабасының әтисе) дәвамчылары һәм башка табышлар. Гомумән алганда, күп алар.

Авыл яшәешенең бер бик мөһим һәм асыл ягы бар: ул – кыз бирү һәм кыз алу (өйләнешү, никах). Еш кына кыз кияүгә күрше авылга чыга яисә килен күрше авылдан килә. Мәсәлән, Буа өязен алсаң, Буа өязе авыллары арасында күбрәк имам, мәзиннәрдә үзара кыз алышу һәм бирешү гадәткә кергән, ә гади халык ешрак якын-тирә авыллар белән туганлаша. Кыр Бикшиге авылы Шыгырдан, Озын Куак, Тимәш, Татар Согыты, Чичкан, Шорт, Урмай, Чути, Тукай, Суыксу, Бакырчы һәм башка авыллар белән туганлашкан. Мәсәлән, Буа өязе имамының кызы (Буадан), Кыр Бикшиге авылы егетенә – Сәйфулла улы Талюска кияүгә чыга. Ул, күрәсең, затлы нәсел егете булган. Легенда буенча, тотрыклы кавем – сәүдәгәр Абдерәхим Айсин нәселе.

Иң бай алпавыт, морза, сотник Салей Сулиевның сигез хатыныннан берсе – Уфа өязеннән, икенчесе – Мөслим авылыннан (Чистайдан ерак түгел), калганнары исә тирә-як авыллардан һәм Кыр Бикшигеннән. Аның җирләре күп, сәүдәләре тотрыклы була, авыл халкына 28гә якын тегермәне булуы турында билгеле. Авылның бер өлеш җире – аның җирләре. Үзе үлгәч, аның улы, авылның җире аз булу сәбәпле, үзенең җирләрен авыл файдасына тапшыра. Сулиевларның җирләре күрше авылларда да була. Әбделмән исемле улының үз йорт-җире белән Шорт авылында торганлыгы билгеле.

Заманында Кыр Бикшиге авылы волость үзәге булып торган. Үзәктә йомышлы татар һәм чуаш авыллары, тагын керәшен катламнары очрый. Шунысы кызык (метрикә кенәгәләрендә йомышлы татар дип язылган): йомышлы татар егете үз халкына, ягъни йомышлы татар кызына өйләнә, кызы йомышлы татарга кияүгә чыга, ә керәшен – керәшенгә. Дин әһелләре ешрак үзара яисә башка тотрыклы гаилә белән туганлаша. Мәсәлән, Салей Сулиевның оныгы мелла Ает улы Вәлит хәзрәткә кияүгә чыга. Алдарак әйтеп үткәнемчә, Вәлит хәзрәт – Фәтхи Бурнашның бабасының әтисе. Фәтхи Бурнашның әнисе – морза кызы, аларның да нәселендә имамнар бар, Шыгырдан авылыннан булган морзаның нугай татарларыннан булуы ихтимал.

Кыр Бикшиге авылы йомышлы татарлар авылы буларак формалаша. Бирегә иң элек Зөя өязеннән 24 йомышлы татар килә (1647) һәм алар – Кыр Бикшиге авылын нигезлиләр. Алар арасында Борнаш исемле кешенең малае да бар, Борнаш төрки телле халыклар арасында билгеле исем. Икенче төркем – Салей Сулиев һәм Абдерәхим Айсин (Казан өязеннән) Аскы (Нижний) Бикшик исеме белән Зирекле елгасы буена урнаша (кайчан килүләре билгеле түгел). Шулай итеп, бу авыл калкулыклы җиргә һәм зур булмаган Зирекле елгасы буена нигезләнә. Авыл калкулыктан астарак урнашкан. Калкулыктан чыккан авыл юлы кыр буйлап олы юлга таба күтәрелә (гел сөзәк тауга менгән кебек), ә олы юлдан соң аска таба төшә, монысы инде Озын Куак авылына илтә. Соңыннан авылга тагын 4 йомышлы татар килеп урнаша, алары Курмыш ягыннан, Петрякс дигән авылдан күчеп килгән. Бу төркем йомышлылар Мещерадан дип санала. Алар Арзамас «Приказ йорты»нда исәптә торалар. Бирегә, Петряксска, Мещерадан йомышлы татарлар, указ буенча засечный линияләр төзү уңаеннан

җибәрелгән була (1578). Алар янына Әстерханнан һәм Касыймнан йомышлы татарлар төрлесе төрле вакытта килеп урнашалар.

Күренеп тора, авылның барлыкка килүе һәм үсеше волость үзәге булуга бәйле. Йомышлылар булгач, указ буенча татарларны, кирәк булса, башка җирләргә дә күчерә алганнар. Дөрестән дә, авылдан да төрле вакытта 5 гаилә указ буенча күченеп утыра: икесе – Озын Куакка, ә өчесе (архив язуын гөмбәчек ашаган, укылмый), минемчә, Чүти авылына, Гөбнә елгасы буена (Гөбнә елгасы буена дигән җире укыла иде). Ник дисәң, шуннан Чүти белән Кыр Бикшиге авыллары кыз бирү-кыз алу буенча бәйләнештә тора башлыйлар.

Нугай морзалары дигәч, шуны әйтәсе килә: Салей Сулиевның да, нугай татары – нугай морзаларыннан яисә кыпчаклардан булуы ихтимал. Аның кабере бүген дә билгеле. Ул 2х3 метр зурлыкта известняк ташлар белән эшләнгән (40х50 см йә 60х70 см зурлыктагы ташлар, калынлыклары 15-20 см булыр). Салей Сулиев 1769 елны үлә. Ул бик каты куллы зат була, караклар аның хәтта «саламы»на да тияргә куркалар. Үзе үлгәч, ике малаеның да милкен урлыйлар. Бер каракны тоталар һәм ул: «Әтиегез безне «ежовых руковицах» тотты, хәзер ул юк, без сезне талыйбыз, – ди. Әлеге тоткын кача. Аны янә тотканнармы-юкмы – билгесез.

Авылның килеп чыгышы турындагы риваятьләр мин кече сыйныфларда укыганда да сөйләнә иде. Шул халык арасында йөргән риваятьләрнең берсендә Курмыштан килгәннәр диелә. Дөрестән дә, Ринат Яраханов (аларның риваяте буенча Петрякстан 5-6 гаилә килгән дип фаразлана, архив буенча – дүрт йомышлы; Курмыш, Түбән Новгород, Арзамас, Сергач, Петрякс – бер тирәдә) үз нәселенең шәҗәрәсен бабаларыннан сорашып калып ясаган иде.

Ринатның әтисе Миначетдин Яраханов Бөек Ватан сугышында катнашкан кадровый офицер. Ул Кыр Бикшиге авылының җидееллык мәктәбендә биология укытучысы, эшен бик яратып башкара, балалар да аны бик яраталар. Мин дә биологияне аңарда укыдым. Мәктәптә ул хәтта бакча да булдырды, шунда бай, матур күптөрле җимеш агачлары да утырткан идек. Мәктәбебезнең бәрәңге басуы да бар иде.

Бүгенге көндә авылның нигезен җиде зур нәсел тәшкил итә. 1647-1700 нче еллардан бирле билгеле алар. Авыл татар-мишәр авылы булып санала, ягъни йомышлы татарлар авылы

Ул вакытта, мишәр сүзе ревизская сказкаларда да, ни мәчет метрикәләрендә дә очрамый – бары тик – йомышлы татар. Аннан соң йомышлы татарлар лашманга әйләнәләр һәм аларга мишәр атамасы тагалар. Тарих битләрендә мишәрләрнең эзен ялгыш артык тирәннән, гасырлар төпкеленнән эзләү гадәткә кергән. Баксаң, мишәрләрнең (мищеракларның) килеп чыгуы уч төбендә генә тора – 1578 ел. Алар – «засечный линия»ләр төзү уңаеннан, патша указы буенча барлыкка килгән, төрле төбәкләрдән тупланган йомышлы татарлар, ягъни татарларның бер катламы гына.

Кадровый офицер Миначетдин Яраханов

«Шулай итеп, геногеографиягә таянып, шуны әйтеп була: Кыр Бикшиге авылының халкы – татар мишәрләре (йомышлы татарлар) белән Татарстан җирлегендә яшәгән татарлар арасында туганлык бәйләнешләре ачык күренеп тора.

(соңрак лашман авылына әйләнә). Күргәнебезчә, авыл халкы өч яктан килеп формалашкан һәм аңа төрле татар авылларыннан йомышлы татар кызлары килеп, аның генофондын – нәселен ныгыткан. Шуны да әйтәсе килә: авылның җирләре аз булу сәбәпле, 1830-1832 нче елларда авылдан 70тән артык гаилә Имәнкисәге, Әләбашы, Кече Бикшик авылларына күченә. Аннан соң 1921 елда 250 кешене, ачлыктан коткарып калу өчен, план буенча Себергә озаталар. 1924 елны авылда 50-60 чакрым ераклыктагы (чит авыллар аша барырга) 800 гектар җиргә илледән артык гаилә барып урнаша. Алар биредә революциядән соң анда тынычрак булыр дип уйлыйлар. Әлеге урынга урта хәлле гаиләләр күченә.

Колхозлашу чорында тагын шуның кадәр үк гаиләне, кулаклар, дип, авылдан алар янына куалыйлар. 1938 елда ике вагон кеше, килешү белән, Казакъстандагы Амангильде авылына (Аккүл станциясе, Амангильде авылы) озатыла. Алар анда саман кирпечле йортларга барып урнашалар. Ул йортлар күченүчеләргә алдан ук әзерләп куелган була. Без, әни һәм улым белән, Амангильде авылына туганнарны күрер өчен барганда (барганыбызга 30 елдан артык), ул авылда бездән киткән дүрт кенә гаилә калган иде, өчесе безнекеләр – апа һәм җизни Әбелхановлар аларның кызының (кызлары һәм кызларының кызы казакъ телен һәм әдәбиятын казакъларга укыталар) һәм малаеның гаиләсе. Шулай итеп, Кыр Бикшиге авылы үсә алмый, җир җитмәгү фаҗигасе, ачлык-ялангачлык. Бүгенге көндә анда барлыгы 300 йорт, меңнән артык кеше яши.

Архив чыганакларыннан ачылмаган нәсел бәйләнешләрен табу өчен, заманча генетик анализ-гаплогруппаларны да эшләдем. Илле бер анализ ал-

ган идем дә, шуларның унбере килеп чыкмады. Барлыгы кырык гаплогруппа эшләнде. Мин аны «геногеография» дип бирәм. Геногеография ул минем фикерләрне исбатлар өчен дә кирәк булды. Тагын шунысын да әйтәсе килә: анализларны үзебезнең авылда билгеле нәсел кешеләреннән алдым. Татарстан буенча да «случайная выборка» ысулы белән бераз гына анализлар алган идем. «Татарстаннан да анализлар алырга» диган фикер миңа соңрак кына килде, әмма кызык булды.

Илле бер пробадан, әйткәнемчә, икесе җитәрлек дәрәҗәдә килеп чыкмады, тугызы, гомумән, эшләнерлек дәрәҗәдә булмады. Кырык анализ – гаплогруппа яхшы дип табылды, калган сигезе башка төбәкләрдән иде. Гаплогруппа буенча, әлеге авылдагы ике гаиләне архив белән тоташтырдым.

Гаплогруппаларның бәйләнеше менә ничек килеп чыкты: Биектаудан (ТР) «ГРР» – кешенең исем-фамилиясенең баш хәрефләре – бер кешедән алганмын, аның гаплогруппасы Кыр Бикшиге (Кыр Бикшиге авылында 5 төрле гаплогруппа) авылындагы 4 кеше гаплогруппасына туры килә, бертөрле ыру (1 нче төркем); Саба районыннан ике кешедән анализ алганмын «НРГ» һәм «СМА», беренчесенә Кыр Бикшигендә өч гаплогруппа туры килә – өч кеше (2 нче төркем), икенчесенә 4 кешенең гаплогруппасы туры килә (3 нче төркем); бу төркемгә Елховое Озеро авылы кешесе «ФФ» туры килә. Билгеле, ул Казанда туып-үскән. Елховое Озеро авылы Буадан ерак түгел Ульяновск өлкәсенә керә. Ике анализ, ягъни – ике кеше гаплогруппасы Шыгырдан+Буага туры килде (4 нче төркем), Кыр Бикшегендә андый гаплогруппа булмады. Тугыз кеше гаплогруппасы (Кыр Бикшиге), Шыгырдан (Шыгырданнан ике кешедән анализ алган идем) авылының кешесенә туры килде, ягъни бер ыру (5 нче төркем). Ундүрт кешенең гаплогруппасына (Кыр Бикшиге) бер кеше анализы – гаплогруппасы Апас ягы кешесенә («ВРР») туры килде (6 нчы төркем). Шунысы да кызык: Саба ягындагы кеше («СМА») Петрякстан килгән кешеләргә, «Мещера» ягынан килгән йомышлы татарларга тәңгәл килде. Шулай итеп, геногеографиягә таянып, шуны әйтеп була: Кыр Бикшиге авылының халкы – татар мишәрләре (йомышлы татарлар) белән Татарстан җирлегендә яшәгән татарлар арасында туганлык бәйләнешләре ачык күренеп тора. Ә геногеографияне өйрәнү исә әле дәвам итә.

Хәзерге заман кысасыннан чыгып шуны әйтәсе килә: авыл тарихларын өйрәнгәндә геногеография – гаплогруппа анализларын да алуың яхшы, һичьюгында – төп нәселләрдән. Бер нәселдән, бер ир кешедән алсаң да яхшы, ул вакытта күбрәк анализ алып була. Бу – Y – гаплогруппа – ир кешеләрдән алына торган анализ. Әйтергә кирәк, бүгенге көнгә килеп җиткән халыкларның 90 проценты күп компонентлы, ягъни аларны формалаштыруга күптөрле ырулар катнашкан. Мин алган аз санлы гаплогруппаларда гына 6 төр ыру күренә, ә аларның биш төре Татарстан буенча да бар. Аерым, аз санлы релектив халыкларның гына күпмедер дәрәҗәдә азрак компонентлы булуы ихтимал. ■

Татар хәйрия җәмгыятьләре

Җәүдәт Миңнуллин

Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин (1953-2019) – тарихчы-галим, археограф, текстолог, РФнең атказанган югары белем бирү эшлеклесе, «Шәхесләребез» фәнни-популяр сериясенең фәнни мөхәррире. Ул Кама Тамагы районындагы Чаллы авылында туган.

Казан университетында татар халкы тарихы, чыганакчылык, историография, текстология, иске татар имлясы, шәрык палеографиясе, татар иҗтимагый-сәяси шәхесләре курсларын укытты. Галим КДУның Фәнни китапханәсендә Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлегенең көнчыгыш секторы мөдире булып эшләде.

Җ.С.Миңнуллин озак еллар дәвамында археографик экспедицияләр оештырды, татар хәйриячелек тарихын өйрәнде, гомеренең соңгы елларында Татарстанның 100 еллыгына багышланган республикакүләм проект белән шөгыльләнде.

Игътибарыгызга тәкъдим ителә торган мәкалә галимнең Казан университеты студентларына укыган лекцияләреннән алынды.

Татарны милләт буларак саклап калуда иң зарури эшләрнең берсе

Шәфкатьлелек, авыр чакта ярдәм кулы сузу –татар халкына борынгыдан хас күркәм сыйфатларның берсе. Мәгълүм булганча, IX гасырда ук шәфкатьлелек безнең бабаларыбызга ислам дине кануннары аша да иңдерелгән һәм шәригать таләпләренә нигезләнеп җайга салына башлаган. Мохтаҗларга, ярлы гарип-горабага, ятимнәргә, төрле бәла-казаларга дучар булганнарга ярдәм итү өчен, ислам динендә махсус салым – зәкят түләнгән. Иҗтимагый әһәмияткә ия булган корылмалар – мәчет-мәдрәсәләр хәлле мөселманнар акчасына төзелгән һәм карап тотылган. Бу җәмәгатьчелек тарафыннан саваплы һәм мәртәбәле эш буларак кабул ителгән.

XIX гасырның икенче яртысында Россия индустриаль үсеш юлына баса һәм җәмгыятькә капиталистик мөнәсәбәтләр үтеп керү хәйрия эшен заман таләпләренә җавап бирерлек итеп яңача оештыруны таләп итә. Татарның алдынгы карашлы катлавы – җәдидчеләр, милли яшәешне үзгәртеп коруның бер чарасы буларак, хәйрия җәмгыятьләре оештыруга зур игътибар бирәләр. Күренекле җәмәгать эшлеклеләре җәмгыятьләр оештырып эш алып баруны татарны милләт буларак саклап калуда иң зарури эшләрнең берсе дип саныйлар.

Татар хәйрия оешмалары барлыкка килүен һәм үсешен шартлы рәвештә 4 этапка бүлеп карарга мөмкин:

• беренче этап – 1844 елдан алып 1897 елга кадәрге вакытны үз эченә ала;
• икенче этап – 1897-1905 нче еллар;
• өченче этап – 1905-1917 елның февраль революциясенә кадәр;
• дүртенче этап – 1917 елгы февраль революциясеннән башлап октябрь көннәренә кадәрге вакытны үз эченә ала.

Татар хәйрия җәмгыятьләре ни өчен соң ачылган?

Россия империясендә җәмәгатьчелек тарафыннан оештырылган хәйрия оешмалары 1810 нчы елларда ук пәйда була. Ә татар җәмгыяте хәйрияләре 1867 елда оеша башлый. Татар хәйрия оешмаларының русларныкына караганда берникадәр соңлабрак оешуының берничә сәбәбе бар. Беренчедән, закон буенча хәйрия җәмгыяте ачканда 1862 елга кадәр рөхсәтне Министрлар Комитеты аша патшаның үзеннән сорарга кирәк була. Мондый бюрократик киртәләрне үтү русларның үзләренә дә кыенга туры килгән. Шуңа күрә Александр I идарә иткән чорда эшли башлаган җәмгыяте хәйрияләрнең кайберләре ябыла һәм кабат ачылмый. 1862 елга кадәр гаять зур Россия империясе территориясендә бары тик 8 хәйрия җәмгыяте эшләвен, 1917 елга кадәр үк, рус галимнәре әнә шуның белән аңлатканнар. 1862 елда хәл үзгәрә, хәйрия җәмгыяте ачу мәсьәләсен эчке эшләр министры хәл итә башлый. Ләкин яңа тәртипләр буенча да җәмгыять ачу юлында шактый күп бюрократик киртәләрне узарга туры килгән. Бу өлкәдә хәлләр уңай якка 1897 елларда үзгәрә: җәмгыять ачу эше тагы да гадиләштерелә, үрнәк уставлар дөнья күрә, губернатор, уставны раслап, аны җәмәгать оешмалары реестрына керткәч, хәйрия оешмасы

рәсми сурәттә эшли башларга хокук ала. Шулай итеп, бу хәйрия җәмгыятьләре мәсьәләсе Россиядә демократик институтларның бик акрынлык белән булса да тернәкләнүе, бигрәк тә хокукый җәмгыять нигезләренең кайбер элементлары барлыкка килә башлавы кебек катлаулы һәм озакка сузылган процесс белән тыгыз бәйләнгән.

Икенчедән, хәйрия оешмасы ачу өчен җәмгыятьнең өлгергәнлеге, ягъни зыялыларның, эшкуарларның җәмәгать оешмалары ачу зарурлыгын аңлавы һәм икътисади яктан да моңа әзер булуы таләп ителгән. Нәкъ менә шушы чорда, ягъни XIX гасырның икенче яртысында татар сәүдәгәр һәм эшкуарлар катлавы икътисади яктан аякка баса. 1880-1890 нчы елларда татар акционерлык җәмгыятьләре оешу шул хакта сөйли.

Сәүдәгәр һәм эшкуарлар катлавының сан ягыннан үсеше дә татар җәмгыятенең яңа дәвергә аяк басуын раслый. Икътисади куәт арту һәм акрынлап гомуммәдәни дәрәҗә үсү, үз чиратында, җәмгыятьнең бу катлавында иҗтимагый мәсьәләләргә торган саен күбрәк игътибар артуга китерә. Социаль катлауның азмы-күпме тәрәккыйпәрвәр өлеше, руханилар, зыялылар белән союзга кереп, милли үсешнең актуаль мәсьәләләрен чишәргә омтыла. Икенче төрле әйткәндә, бу чорда эшкуарлар катлавының җәмгыятьтә үзенең тоткан урынын һәм җәмгыять алдындагы җаваплылыгын аңлау дәрәҗәсенә күтәрелүе күзәтелә. Хәйрия җәмгыятьләре ачылу һәм андагы әгъзаларның абсолют күпчелеген шушы катлау вәкилләре тәшкил итүе – моның ачык мисалы.

Алар капиталны тәртипсез рәвештә сарыф итүгә каршы

Хәйрия җәмгыяте – ачык типтагы һәм үзара теләктәшлеккә, бер максатка хезмәт итүгә нигезләнгән коммулятив төркем рәвешендәге ирекле җәмәгать оешмасы ул.

Хәйрия оешмалары җәмгыятьнең аерым әгъзалары кулында тупланган капиталны тәртипсез рәвештә сарыф итүгә каршы чыгалар. Тупланган байлыкның бер өлешен иҗтимагый, социаль-икътисади тормышның аерым тармакларын заман таләпләре дәрәҗәсенә җиткереп үзгәртеп кору өчен бер урынга туплау һәм җыелган акчаларны шушы юнәлештә системалы рәвештә сарыф итүне дә җәмгыяте хәйрияләр оештыра. Бу оешмалар милли консолидация һәм социаль парнерлыкны җайга салуга да мәгълүм өлеш керткәннәр. XIX гасыр ахыры-XX гасыр башы татар чынбарлыгы шартларында хәйрия җәмгыятьләре иҗтимагый, мәдәни һәм өлешчә дини тормышны тәэмин итүче структураларны теге яки бу дәрәҗәдә оештырып һәм әйдәп баручы оешма рәвешен ала. Хәйрия җәмгыятьләре оешу белән татарда чын мәгънәсендә җәмәгать тормышы барлыкка килә. Татар җәдитчеләре шушы оешмалар аша үз максатларын тормышка ашырырга омтылалар.

Татарлар ачкан беренче хәйрия җәмгыятьләре

Татарлар 1867 елга кадәр, ягъни беренче хәйрия җәмгыяте оешканчы ук бу юнәлештә кайбер адымнар ясыйлар. Мәсәлән, 1844 елда Казанда сәүдәгәр Юнысовлар балалар йорты – ятимханә оештыралар.

Беренче татар хәйрия җәмгыяте 1867 елда Санкт-Петербургта Касыйм татарлары тарафыннан оештырыла. Соңрак, 1877 елда Уфада отставкадагы гвардия полковнигы С.Ш.Тәфкилев җитәкчелегендә караучысыз калган өлкән яшьтәге мөселманнар өчен картлар йорты һәм ятим балалар өчен ятимханә оештырыла. 1891 елда, бөтен Идел буе губерналарын чолгап алган коточкыч ачлык елында, Казан губернасының Мәмсә волостенда мөселман хәйрия комитеты барлыкка килә. Шушы елларда ачлыктан интегүче татарлар өчен эшкуарлар бушлай хезмәт күрсәтүче ашханәләр ачалар, халыкка азык-төлек, киемсалым таратуны оештыралар.

1897 елдан татар һәм башка милләт хәйрия оешмалары барлыкка килү тагын да активлаша төшә. Эчке эшләр министры карары белән хәйрия җәмгыятьләре уставларын кабул итү берникадәр гадиләштерелә, аларның үрнәк уставлары да бастырып чыгарыла. Җәмгыятьләр эшчәнлекләрен губернатор тарафыннан расланган устав нигезендә генә башлап җибәрә алганнар һәм аларның уставтан читкә чыгарга хаклары булмаган. Уставны төзү һәм раслау, әлбәттә, шома гына бармаган. Хакимият әһелләре, бер яктан төрле бюрократик киртәләр корсалар, икенче яктан, хәйрия эшен Европа ысуллары кулланып яңа формада оештыру иске карашлы муллаларның каршылыгына очрый. Һәр яңа эшнең теге яки бу дәрәҗәдә каршылыкка очравы табигый хәл, әлбәттә.

Татар хәйрия җәмгыяте – демократик оешма

Атаклы мәгърифәтче һәм җәмәгать эшлеклесе И.Гаспринский һәм аның «Тәрҗеман» газетасы хәйрия оешмаларының барлыкка килүендә зур роль уйный. И.Гаспринский аларның эшчәнлегенә зур игътибар бирә, укучыларның күпсанлы сорауларын искә алып, хәйрия җәмгыятенең үрнәк уставын татарчага тәрҗемәдә бастырып чыгара.

Төзелеше һәм эш тәртибе ягыннан караганда хәйрия җәмгыятьләрен чын мәгънәсендәге демократик оешмалар дип атарга тулы нигез бар. Закон һәм устав буенча җенесе, милләте, дине һәм социаль чыгышына карамастан, балигъ булган, җәмгыятьнең максатларын таныган, взнос түләгән теләсә кем аңа әгъза булып керә алган. Балигъ булмаганнар, мәктәп-мәдрәсәләрдә укучы шәкертләр, гаскәри хезмәттәге түбән дәрәҗәле гаскәриләр, ягъни солдатлар, юнкерлар һәм хөкемгә тартылганнар җәмгыять әгъзасы булудан мәхрүм ителгән. Җәмгыять әгъзалары төп өч категориягә бүленгән: фәхри (мактаулы), гомерлек һәм хакыйкый. Мактаулы әгъзалар арасында еш кына җирле хакимият әһелләрен һәм, үзләре бу шәһәрдә яки авылда яшәмәсәләр дә, татар, мөселман дөньясында теге яки бу өлкәдә шөһрәт казанган мәгълүм затларны күрәбез. Теге яки бу җәмгыятьтә әгъза булу мәртәбәлелек билгесе рәвешендә кабул ителә башлый. Хәйрия җәмгыятьләре эшендә катнашу, төрле мәдәнимәгариф чараларына матди ярдәм итү татар эшкуарларына, рухи канәгатьләнү хисе белән бергә, сәяси һәм икътисади файда да китергән.

Эшне алып бару өчен, устав нигезендә гомуми җыелышта җәмгыятьнең идарәсе, аның рәисе, урынбасары һәм казначы сайланган. Җәмгыятьнең финанс һәм башка эшчәнлеген тикшерү өчен һәр ел саен ревизия комиссиясе (һәйәте) тәгаенләнгән.

Җәмгыятьләрнең таралу географиясе

Җәмгыятьләр Казан, Оренбург, Троицк, Касыйм шәһәр хәйрия җәмгыятьләре дип аталсалар да, үз эшчәнлекләрен мөмкин кадәр киңрәк даирәгә җәелдерергә омтылганнар яки шулай эшләргә мәҗбүр булганнар. Мәсәлән, 1913 елда Казан җәмгыяте хәйриясенең ятимханәсендә губернаның Казан, Лаеш, Тәтеш, Спас, Чистай өязләреннән һәм Кострома шәһәре Татар бистәсеннән килгән 3 бала, җәмгысе 29 фәкыйрь-фокара тәрбияләнгән. Җәмгыятьнең ир һәм кыз балалар мәктәбендәге ятимханәдә тәрбияләнүче балалар белән бергә, губернаның төрле өязләреннән килеп укучылар саны 125кә җиткән.

XIX гасыр азагында мондый оешмалар эшчәнлекләрен Казан, Санкт-Петербург, Троицк, Касыйм, Петропавловск, Әстерхан шәһәрләрендә башлап җибәрәләр. Якынча исәпләүләр буенча, 1917 елга кадәр аларның гомуми саны 150гә җитә. Шунысы игътибарга лаек: татар хәйрия оешмалары Архангельск, Вологда, Ростов-Дон кебек чиста урыс шәһәрләрендә дә, шулай ук чит илләрдә дә (Төркия, Кытай һ.б.) ачыла.

Хәйрия җәмгыятьләренең кереме һәм төрләре

Хәйрия җәмгыятьләренең төп яшәү чыганагы булып взнослардан, төрле иганәләрдән, күчемсез милекнең табыш процентларыннан кергән акча суммалары тора. Православие хәйрия җәмгыятьләреннән аермалы буларак, татар оешмалары төрле хәйрия спектакльләреннән, кинематография сеансларыннан, концертлардан, әдәби-музыкаль кичәләрдән, милли бәйрәмебез Сабан туеннан һәм башка күңел ачу чараларыннан тупланган керемнәрдән дә файдаланганнар.

Эшчәнлекләренә һәм составына карап, хәйрия җәмгыятьләрен берничә төргә бүләргә була:

1. гомуми характердагы җәмгыятьләр;
2. хатын-кыз җәмгыятьләре;
3. махсус җәмгыятьләр;
4. катнаш оешмалар (хәйрия, мәдәни, икътисади җәмгыятьләр).

Шулай итеп, хәйрия оешмалары төрле юнәлештә эшчәнлек алып баралар.

Вилядатханә һәм дарелгаҗәзәләр

Фәкыйрьләргә, ярдәмчесез калган карт-корыга һәм балаларга айлык яки вакытлы рәвештә матди ярдәм күрсәтү барлык хәйрия җәмгыятьләренең төп бурычларыннан берсе саналган.

Хәйрия җәмгыятьләре фәкыйрьлектә вафат булган мөселманнарны соңгы юлга озатудан да читтә калмаганнар. 1914 елда Казан мөселман хәйрия җәмгыяте 96 ир-атны, 55 хатын-кызны һәм 89 баланы җирләүдә акчалата ярдәм итә. Башка җәмгыяте хәйрияләр дә бу эшләргә даими рәвештә матди булышлык күрсәткән.

Халыкка тыйбби (медицина) хезмәт күрсәтү өлкәсендә дә җәмгыяте хәйрияләр мәгълүм эш башкарган. Бу юнәлештә Казан мөселман җәмгыяте хәйриясе аеруча активлык күрсәтә. 1903 елда җәмгыять тарафыннан фәкыйрь



УСТАВЪ

общества пособія бѣднымъ мусульманамъ

Г. КАЗАНИ.

ТИПОГРАФІЯ
Б. Л. Домбровскаго въ Казани.
1898

Казан мөселман хәйрия җәмгыятенең уставы

«

Хәйрия җәмгыятләре халык мәгарифен үстерүгә дә зур өлеш керткән. Һәр җәмгыять бер яки берничә мәктәпне үз карамагына алган. 1912 елда Оренбург хәйрия җәмгыяте үз хисабына 3 мәктәп тоткан, шәһәрдәге калган татар мәктәпләренә дә матди ярдәм итеп торган.

авыруларга медицина ярдәме күрсәтү өчен амбулатория (хәзерге Ф.Кәрими урамы, 6 нчы йорт) ачыла. Шушы амбулатория 25 ир-ат, 1453 хатын-кыз һәм 495 авыру баланы кабул итә, барлыгы 4000 кешегә медицина ярдәме күрсәтә. Бу авыруларның 98 проценты җәмгыять амбулаториясенең даруларыннан бушлай файдалана, бары тик 2 проценты гына даруларны ирекле даруханәдән сатып ала. Авыруларга бушлай дару биреп ярдәм итүдә дә Казан мөселман җәмгыяте күпләргә үрнәк булып торган.

1912 елның 22 гыйнварында, халык ихтыяҗларын игътибарга алып, Казан җәмгыяте иң ярлы мөселманнар өчен түләүсез хезмәт күрсәтә торган вилядатханә, ягъни бала тудыру йорты ачып җибәрә һәм шул ук елны аның файдасына төрле кешеләрдән, шул исәптән Мәскәүдәге мөселман ширкәтләреннән 5192 сум иганә акчасы җыела. Казанның күренекле табиблары Александр Иванович Захарьевский, Софья Соломоновна Надель-Пружанская, Әбүбәкер Гомәр улы Терегуловлар амбулатория һәм бала тудыру йортында зур тырышлык куеп эшләгәннәр. Татарлар өчен махсус медицина хезмәте күрсәтүче оешмалар ачылуның әһәмиятенә басым ясап әйтергә кирәк, чөнки

ул заманнарда татарлар, бигрәк тә хатын-кызлар, хөкүмәт тарафыннан ачылган сырхауханәләргә, аеруча бала тудыру йортларына бик теләп йөрмәгән.

Тәрбиячесез калган яки фәкыйрь балалар һәм картлар өчен ятимханәләр ачу – татар җәмгыяте хәйрияләренең мөһим бер тармагы. Казан җәмгыяте 1900 елда ук тәрбиячесез һәм якын туганнарсыз калган карт-корыны тәрбияләү өчен дарелгаҗәзә, ягъни картлар йорты ача һәм ул, идарә әгъзалары тырышлыгы нәтиҗәсендә, үз юнәлешендә уңышлы гына эшләп килә. Төрле ятимханәләр ачып, Казан, Троицк, Уфа, Оренбург, Семипалатинск һәм башка шәһәрләрдәге җәмгыяте хәйрияләр бу игелекле эшкә зур өлеш кертәләр. Шунысын әйтергә кирәк: ятимханәләрдә тәрбияләнүче балалар бер үк вакытта мәктәпләрдә башлангыч белем дә алганнар һәм төрле һөнәрләргә дә өйрәнгәннәр. Мәсәлән, Казан җәмгыяте ятимханәсендә тәрбияләнүчеләр өчен тимерчелек, слесарьлык һөнәрләрен өйрәнү буенча остаханә ачыла.

Хәйрия җәмгыятләре халык мәгарифен үстерүгә дә зур өлеш керткән. Һәр җәмгыять бер яки берничә мәктәпне үз карамагына алган. 1912 елда Оренбург хәйрия җәмгыяте үз хисабына 3 мәктәп тоткан, шәһәрдәге калган татар мәктәпләренә дә матди ярдәм итеп торган. Мөселман кызлары өчен ачылган 7 мәктәп 1914 елда Уфа мөселман хатын-кызлар җәмгыяте карамагында була, биредә укучы 517 кыз кул эшләре курсларын үтә. Санкт-Петербург мөселман җәмгыяте хәйриясе 1913 елда төрле югары һәм махсус уку йортларында белем алучы 21 студентка акчалата ярдәм күрсәтә.

1905-1907 нче еллардагы революциядән соң татар укучы яшьләренә ярдәм итү өчен, махсус җәмгыятьләр барлыкка килә. Бу юнәлештә аеруча Оренбург җәмгыяте максатчан эшләп килгән.

1906 елдан башлап Россия империясеннән читтәге көнчыгыш илләрендә, Истанбул, Каһирә, Мәккә, Мәдинә, Бәйрут шәһәрләрендә татар шәкертләренең якташлык тибындагы үзара ярдәмләшү җәмгыятьләре эшли башлый.

Татар хәйрия оешмалары яшьләрнең профессиональ-техник белемнәрен үстерүгә зур көч куйган. Алар төрле шәһәрләрдә һөнәр мәктәпләре, курслар ачалар. Анда укучы яшьләр кыска гына вакыт эчендә төрле һөнәр үзләштергән. 1911 елда Пермь мөселман мәдәни-икътисади һәм хәйрия оешмасының һөнәр мәктәбе укучылары, үзләренең экспонатлары белән Омск күргәзмәсендә катнашып, көмеш медальгә лаек булган.

Хәйрия оешмалары китапханәләр, уку йортлары ачуда да зур тырышлык куялар. Татар халкы китапханә фондларыннан аеруча яратып файдаланган. Хәзерге Азәрбайҗан, Казакъстан, Үзбәкстан, Кыргызстан, Төркмәнстан, Себер һәм Ерак Көнчыгышта татар колонияләренең барлыкка килүе һәм ныгуы белән татар китапханәләре дә оештырыла башлый. Алар татар хәйрия оешмалары башлангычы белән Баку, Нәманган, Әндиҗан, Алма-Ата, Ташкент, Куканд, Петропавловск, Сергиополь, Капал, Керки, Омск, Томск, Иркутск, Благовещенск һәм Казалинск шәһәрләрендә ачыла. Шулай итеп, хәйрия җәмгыятьләре земстволар һ.б. мәдәни-агарту оешмалары белән берлектә, татар китапханәләре челтәрен булдыруга күп көч куялар. Шул заманга хас булган мәгълүмат системасының төп коралы саналган китапханәләр татарлар йогынтысында башка төрки халыклар арасында да үсеш ала. Хәйрия җәмгыятьләре ярдәмендә башка милләтләргә дә татар, көнбатыш һәм көнчыгыш әдәбияты үрнәкләре, дөньяви һәм фәнни белемнәр тарала.

Беренче һәм соңгы корылтай

Беренче бөтендөнья сугышы башлангач, хәйрия эше тагын да җанлана төшә. 1914 елның 6-10 декабрендә Петроградта Мөселман җәмәгать оешмаларының корылтае уздырыла. Корылтайда Русиянең 15 шәһәреннән килгән 28 делегат катнаша. Анда каралган төп мәсьәлә: фронтка ярдәм итү һәм бу эштә мөселман хәйрия җәмгыятьләре эшчәнлеген координацияләү; яралы мөселман солдатлары һәм аларның гаиләләренә ярдәм оештыру була. Бу эшләрне тормышка ашыру өчен, 1915 елның 5 февралендә «Яралы мөселман гаскәриләренә һәм аларның гаиләләренә ярдәм итү максатыннан Вакытлы мөселман комитеты» төзелә. Ул үзенең эшчәнлеген империянең барлык төбәкләрендә диярлек җәелдерә. Комитет тарафыннан күчмә мөселман лазареты төзелә һәм фронтка җибәрелә, төрле шәһәрләрдә лазаретлар оештырыла. Шулай ук Русиянең көнбатыш төбәкләреннән килгән мөселман качакларга (Литва татарларына) һәм әсирләргә (төрек солдатларына) ярдәм эше оештырыла. Фронтка җылы кием-салым, татар китаплары һәм газета-журналлар җибәрү эше дә юлга салына. Яралы солдатлар файдасына иганә җыю өчен төрле кичәләр оештырыла, концерт-спектакльләр куела, аларның гаиләләренә дә ярдәм күрсәтелә.

«Кызыл авызлар»га һөҗүм

Җәмгыяте хәйрияләрнең эшчәнлеге рәсми төстә рөхсәт ителүгә карамастан, аларны хакимият әһелләре һәм миссионерлар ныклы контрольдә тоткан, мондый оешмаларны арттырмас һәм эшләтмәс өчен барысын да эшләп калырга тырышкан. 1911 елда, мәсәлән, Сенат карары белән, Әстерхан, Сембер, Ставрополь шәһәрләрендәге татар хәйрия оешмалары, Мәкәрҗә ярминкәсендәге мөселман җәмгыяте ябыла. Уставында кайбер кирәкле параграфларның булмавын сылтау итеп, хөкүмәт «Тәрәккыюне ислам» исемле Томск мөселман җәмгыятенә китапханә ачарга һәм анда әдәби кичәләр үткәрергә рөхсәт бирми. Патша хакимияте әһелләре, татар мәдәниятенең империядәге башка төрки халыкларга тәэсиреннән куркып, 1911 елда Оренбург казакъ мәктәбе укучыларын татар җәмгыяте китапханәсенә йөрүдән тыя. Консерватив даирәләр дә җәмгыяте хәйрияләр эшчәнлегенә мөмкин кадәр аяк чалырга тырышалар. 1909 елда, мәсәлән, Каргалы (Оренбург губернасы) җәмгыяте хәйриясе, җирле хакимияткә китапханә өчен җир бирүләрен сорап мөрәҗәгать иткәч, «Дин вә мәгыйшәт» журналының кайбер тарафдарлары, анда дини фәннәрнең өйрәнелмәвенә, китапханәгә фәкать «кызыл авызлар» гына йөрүенә басым ясап, каршы төшеп карыйлар. «Кызыл авызлар» дип кадимчеләр XIX гасырның соңгы чиреге-XX гасыр башында татар иҗтимагый хәрәкәтенең прогрессив агымын тәшкил итүче җәдидчеләрне атаган. Кайбер төбәкләрдә искелек тарафдарлары хәйрия оешмаларын бидгать эш дип бәяләп, аларны ачуга аяк чала. Әмма, бернинди киртәләргә карамастан, Россия империясенең төньягында – Архангельск шәһәре, көнбатышта – Варшава, көньякта – Керки һәм Термиз, Ерак Көнчыгышта – Благовещенск шәһәренә кадәр булган гаять зур территориядә татар хәйрия җәмгыятьләре нәтиҗәле эш алып баралар. ■

Имеш, мин чын-чын шагыйрь...

(Археографик көндәлек)

Миркасыйм Госманов

Миркасыйм Госманов гаиләсе һәм туганнары белән. 1966 ел

VII сәфәр
Волгоград өлкәсенең Ленин районындагы Бәхтияр, Мәләй һәм Сарай авыллары

Студент чакларда Сарай-Бәркәне казуга катнашып, 2 мәртәбә Волгоград өлкәсендә булып кайткан идем. Шунда Ленин районындагы берничә татар авылында да (Бәхтияр, Мәләй һәм Сарай) булынган иде. Соңрак, археография белән шөгыльләнә башлагач, менә шул авылларның икенчесен язмалар күзлегеннән бер тикшереп чыгу теләгем туды. Һәм бу максатыма быел гына ирештем. Өметем, ышанычым зурдан иде, чөнки бу якларда утырып калган мишәрләр [19]30 нчы еллар шаукымыннан читтә торган булырга тиеш. Аннары иске танышларның булуы да ярдәм итәргә тиеш (узган елларда ул авылларда йөреп, фольклор материаллары җыеп, шактый кешеләр белән танышкан идем).

9.09.1966. Иртәнге сәгать 9:40 минутта Волгоград поезды белән юлга чыктым (пароходка билет алырга тырышмадым, чөнки срок кыска булгач, юлга вакыт әрәм итәсе килмәде...). Ә вагонда бөркү...

10.09.1966. Көндезге 2:40та Волгоградта идем. Шул ук көнне автобус белән Ленинскийга, аннан Царев поселогы янындагы Сарайга, ягъни анда һаман казынып яткан егетләр янына киттем. Автобуска эләгүе бер мәшәкать булды (2-3 җирдә автобус алыштыргач бигрәк тә). Ә юллар таныш!..

Сарайдагы археологлар лагерена төнге уннарда гына җиттем. Лагерьдагыларның күпчелеге кинода икән. Экспедиция башлыгы, МДУ доценты Герман Алексеевич Федоров-Давыдов[1], хатыны Марияны каршылар өчен, машина белән станциягә киткән икән. Учак янында утырган Әзһәр Мөхәммәдиев[2] исә бик эре генә кылана, күрәсең, ул үзен монда бик зурдан хис итә.

Бераздан, хатынын «төяп», Герман кайтты. Күңелле генә очрашу. Аның хатыны белән художник егет Борис Дашков[3] килгән. Бергә-бергә бер шешәне «сыттык», озак кына сөйләшеп утырдык.

Минем берүземә бер чатыр әзерләп куйганнар икән (алдан КДУ отрядының башлыгы И.С.Вайнерга хәбәр иткән идем...). Теләгәнчә ял ит! Әйе, быел экспедицияләрдә шактый йөрелде, шуңа күрә 3-4 көн ял итеп, балык каптырып алсаң да, начар булмас. Әлеге Мәскәү егете дә балык тотарга дип килгән икән. Ярар, егетләр, сез казына торыгыз, ә мин печтек кенә ял итәм (3-4 авылны тентеп чыгар өчен күп вакыт кирәкми бит!).

14.09.1966. Бары бүген генә эшне башладым. Моңарчы Борис белән Актүбә буенда берничә көн балык каптырып, су кереп, ял кисәге оештырдык. Тик һавалар рәтсез – җилле булганга, балык күп эләкмәде, шулай да һәр көнне үзебез пешереп ашарлык, аннары лагерьга да алып кайтырлык тотыла иде. Әмма бер зур оптыш [җерех], якынча 100-110 см булыр, бергәләшә-бергәләшә тартып чыгару гомергә онытылмас!

Егетләрнең берсенең велосипедын алып, Сарайга килдем. Көн матур, авыл буш. Искә Сәгыйть Рәмиев төшә:

И авыл, син мең шәһәрдән,
Мең кабат ямьле вә хуш;
Бер кеше юк бер урамда,
Нинди тын һәм нинди буш...

Әйе, авыл буш булып чыкты. Эзләп килгән Кутуев бабайны да таба алмадым – ул каядыр киткән. Аннары Ибраһим Акчурин дигән бер бөкре картка кереп, шактый гына ләчтит сатып утырырга туры килде. Төрле «тарихлар» сөйләде, черемәгән мәет табуны да (1913 нче еллар тирәсе...). Авыл исә моннан 150-200 еллар элек нигезләнгән. Ә язма әйберләргә килсәк, карт бернәрсә дә белми. Моннан соң тагы берничә «могътәбәр» һәм «күпне белә торган» бабайлар

[1] Герман Алексеевич Федоров-Давыдов (1931-2000) – Алтын Урда археологиясе һәм нумизматикасы буенча белгеч, МДУ профессоры.
[2] Мөхәммәдиев Әзһәр Гатаулла улы (1933-2018) – галим, тарих фәннәре докторы.
[3] Дашков Борис Григорьевич (1929-2015) – совет рәссамы, иллюстратор, совет чорында «Наука и жизнь» журналының баш рәссамы.

белән сөйләштем. Ләкин шул ук нәтиҗә: тетелеп беткән иске Коръәннән башка бернәрсәләре дә юк. Күпчелеге яза да алмауларын аңлаттылар. Гаҗәп!..

Ә нәрсәгә гаҗәпләнергә? Гел иген һәм вак сәүдә белән шөгыльләнгән халыктан ни көтмәк кирәк?

15.09.1966. Ленинск шәһәренә барып, райбашкармага кереп, тиешле мәгълүматларын алып, документларны җайлау белән мәшгуль булып, көннең иң әйбәт яртысын үткәрдем. Ә төштән соң яңадан лагерьга кайтып, Актүбә буенда «су сөзеп» йөрдем. Тик балык начар чиртте... Ә көн җилсез, матур иде...

16.09.1966. Бүген пәнҗешәмбе – лагерьда ял. Студентлар ял итә. Ә мин Германга ияреп, Царевтан 18-20 чакырым җирдәге Зубаревка дигән бер авыл янындагы иске шәһәрлекне (городище) карарга киттем – Алтын Урда чоры шәһәренең урыны. Керамика һәм Алтын Урда тәңкәләре күп табыла. Тик XVIII-XIX гасырларда шуның өстенә, ягъни иске шәһәрлек өстенә, килеп руслар авыл салып утырганнар – Зубаревка дигән авыл барлыкка килгән. Соңрак Совет чорында ул авыл таралып беткән... Шәһәрлек мәйданы, анда табылган әйберләрнең характерына караганда, дәверендә биредә бик зур гына бер шәһәр булганга охшый. Димәк, бу тирәләрдә Сарай Бәркә ялгыз гына булмаган!.. Тик дуңгыз кебек казынган соңгы чор кешеләре археологик хәзинәнең зур өлешен харап иткән булырга охшый.

Кичен балыкка киттек. Бер зур судакны качырдым. Их...

17.09.1966. Ашыкмыйча, җәяүләп, Ленинскийга киттем. Анда машина көтеп торган арада бер төркем татарлар белән таныштым.

Бәхтияр авылына төш вакытында гына җиттем. Минем Бикмәмәтов Шакир дигән бер танышым бар иде. Ул хәзер юк – 2 ел элек вафат икән. Шуның хатыны Хәнифәгә килдем. Туганын каршылаган кебек кабул итте. Сәгатьләр буе иренең ничек авырып, ничек үлүен сөйләп утырды. Әңгәмәгә дип, күршесендәге Харрас Фәйзуллин дигән бер абзый да керде. Сөйләшә торгач, моннан ничә еллар элек бер иске йортны сүткәндә, гарәпчә язулы тире рулон чыккан булуы да беленде. Тик аннары ул язулы тире юкка чыккан... Их, бер кисәген генә табасы иде...

Берничә йортка кердем. Шакирның әтисе Рәҗәп бабай Бикмәмәтов һәм башка картлар белән дә очраштым. Бер кульязма да юк. Ә аракыны һәр өйдә тәкъдим итәләр...

18.09.1966. Арылган булганга, яхшы йокланды бу тәбәнәк кенә мазанкада! Ә иртән исә хуҗабикә Хәнифә түтәй бик шәп табын әзерләгән булган: майлап, борычлап кыздырган бер әтәч!

Иртәлектән соң Хәнифәнең энесе Мостафа белән тау өстенә менеп, курганнар карарга киттек. Һәм менә дигән Алтын Урда чоры шәһәрлегенә тап булдык: кирпечләр, керамика, тәңкәләр!.. Аннары кирпеч шлагы! Димәк, биредә кирпеч сугып яндыру урыны булган! Шушы көннәрдә ук Германны китерергә кирәк. Димәк, Зубаревкадан соң тагы бер шәһәрлек ачылды!

19.09.1966. Көне буе авылны кыдырдым. Төштән соң Бәхтиярдә бер китап кисәге таптым: фарсыча Коръән тәфсиренең бер кечкенә бүлеге: «Тәфсир-е Хөсәен». Урта Азия кульязмасы. Бу надан якларга каян эләкте икән?!

Кичке якта Мостафаның мотоциклында Ленинский аша Сарайга – лагерьга кайттым. Мин үзем бу Бәхтияр түгел, хәтта бөтен сәфәр (хәтта переспективадан да) бик ризасыз идем. Әмма башкалар, бигрәк тә исә Герман, әлеге тәфсир кисәгеннән һушларыннан язардай булдылар. Яңа шәһәрлек табылуы да аңар бик ошады...

20.09.1966. Көн бик җилле иде. Ком оча. Тешләр шыгырдый. Мәләй авылына киттем. Иске таныш Габдерәхим Тюменев дигән кешегә бардым (китапханә мөдире). Әйтүенә караганда, аның бабайлары Түбән якларыннан килгән. Ләкин аның кайсы Түбән булуын белми – Себердәгеме яки Пензадагымы (минемчә, соңгысы, ягъни Темников булырга тиеш). Авыл исә 1860 елгы реформадан соң салына башлаган булырга тиеш. Тюменевның әйтүенә караганда, кулъязмадан өметләнеп торасы юк: халык элек-электән ук бик надан булган, әзме-күпме укымышлылары да күптән таралып, сибелеп беткән.

Шулай да авылны айкадым. Ләкин мәгънәсез. Бик күп йортларны йөреп тә, Х.Мөслиминең алама «Тәварихи Болгариясе»нең парчасыннан башка бернәрсә дә тапмадым. Ә соңгы елларда надан имля, начар почерк белән күчерелгән догалык кисәкләренә килсәң, алар очраштыргалый...

Кичен лагерьга кайттым. Көн бик җилле иде. Багана-багана булып ком өермәләре оча... Әйе, бу сәфәр уңмады. Күрәсең, монда артык вакыт уздырудан бернәрсә дә чыкмас. Үкчәне күтәрү хәерледер...

21.09.1966. Мин кайтырга ният кылдым. Машинада Ленинскийга киттек. Минем белән бергә, әлеге Бәхтияр янындагы шәһәрлекне карар өчен, Герман да килде. Озак кына карап йөрдек. Минем фаразларым белән Герман да тулысынча килеште.

> «
> **Яшьлегемнең якты, хәсрәтле, олы мәхәббәте яңадан баштан кичә. Күңелем сөенү аралаш көенә; күкрәгемдәге нәрсәләрдер сызып, өзелер төскә җитеп әрни...**

Төштән соң Ленинскийга килеп, таксига утырып, Волгоград ягына киттем. Ә көн бик җилле, комлы иде. Хәтта ашказанына хәтле ком тулды!.. Шәһәргә килеп, гостиницага урнашып, душка кереп юынгач кына, бераз хәл керде. Чиста һәм йомшак түшәктә рәхәтләнеп бер йоклыйсы бар...

Кичке салкында шәһәр урамнары күңелле генә иде. Шактый вакыт хозур итеп йөрдем. Шәп итеп салынган бу Волгоград. Тик нәрсә исәбенә?..

22.09.1966. Баштан гаҗәп хәлләр кичә: имештер, мин беренче мәхәббәтем М-рне очратканмын. Ул иргә чыккан. Анысы да әллә ничек таныш, бик таныш кыяфәтле берәү. Ә үзе (М-р үзе) бик картайган: ябык, сары йөзле. Бик бәхетсез, имеш, ире исә явыз, имеш. Мин хәсрәттә. Яшьлегемнең якты, хәсрәтле, олы мәхәббәте яңадан баштан кичә. Күңелем сөенү аралаш көенә; күкрәгемдәге нәрсәләрдер сызып, өзелер төскә җитеп әрни... Бу М-р белән икәү яшеренеп кенә бик гади һәм бик самими итеп серләшәбез, моңланабыз, сагышлы сагыну белән узганны искә төшерәбез. Ул исә үзенең бик-бик бәхетсез булуын әлеге истән чыкмас зур якты күзләре белән «сөйләп» тора. Ә күзләре һаман

шул элеккечә зур, ачык, чак кына яшьле, гаҗәеп нурлы иде... Ул шундый тутырып карый да, мин эреп китәрдәй булып югалам... Әллә нинди сүзләр арасында миңа әйтеп куя: «Синең хатының – яхшы кеше» (бары бер шул гыйбарәсе генә ачык). Ул арада нәҗес ире килеп чыга да (кемгәдер бик охшаган ул!) минем алда үзенең күп хатын алып аерган булуы белән шапылдап мактана башлый. Минем саруларым кайный. Шунда ук М-рне тотып кыйнарга итә, мин аңар ташланам... Вакыйгалар бутала, үзем саташа язам, ул арада гаҗәеп моңлы, ялкынлы сагыш белән тулы бер газәл укый башлыйм. Имеш, мин чын-чын шагыйрь...

...Уянып киттем. Төнге сәгать 3 иде. Бөтен дөнья тын. Бүлмә дә тып-тын. Ә күңел тулы татлы һәм якты сагыш... Тәмәке артыннан тәмәке тартам. Күз алдында беренче олы мәхәббәт ләззәтен татып, беренче олы хәсрәт дәрьясына чумган яшьлек чакларым – [19]50 нче еллар... Көрпә карлар сибәләгән әлеге беренче гыйнвар иртәсе... Минем иң бәхетле көнем, иң бәхетсез көнем!.. Ә без, Яңа елны каршылагач, таралашып бара идек. Без икәү, мин аны озата барам. Шундый матур итеп сөйләшеп... Һәм бөтенесе дә шул ук иртәдә, көрпә карлар сибәләгән серле бер иртәдә җимерелде, ишелде...


38

VII сәфәр

Волгоград өлкәсе, Ленин р-ны Бәхтияр, Мәлүш һәм Сарай авыллары

9/IX — 26/IX 1966 ел

Студент чакларда Сарай-Бәркәне казуга катнашкач 2 мәртәбә Волгоград өлкәсендә эзләнеп кайткан идем. Шунда Ленин районындагы берничә татар авылында да (Бәхтияр, Мәлүш һәм Сарай) булмаган иде. [illegible]

Археографик көндәлекнең бер бите

Күңелемдә әлеге газәлнең моңнары уйный. Гаҗәп газәл... (рифма-рефрены аның исеме). Чын шагыйрьләргә илһам менә ничек килә икән...

Менә шулай, 18 яшьлек чагымда кичергән иң якты, иң олы, иң хәсрәтле, иң трагик (минем өчен) яшьләрем яңадан күңелемнән кичте... Җыр булып, бер гаҗәеп, серле газәл булып... Бу да табигый иде, чөнки шул мәхәббәттән соң мин шигырь яза башлап, әдәбият дигән бер дөньяга якынлаша башладым. Ул исә минем биографиямне үзгәртеп, яңа сукмакка борып җибәрде...

Ә М-рнең алдында, гәрчә ул минем мәхәббәтемне кире какса да (бәлки, үзем тәкъдим итә алмаганмындыр...), мин бик бурычлы. Мәхәббәт дигәннең нәрсә булуын белүем өчен, хәсрәт дигәннең ни икәнлеген аңлау өчен, самими кайнар яшьләрем өчен бурычлы... Менә шул саф, олы мәхәббәтем белән мин бүген төшемдә очраштым. Язмышыма тагы бер кат рәхмәт...

Әйе, мин хәзер хатынлы кеше. Хатыным әйбәт. Мин аннан риза. Ләкин беренче мәхәббәт... Әмма күңелдә әлеге җыр:

Аккош күлләрдә була,
Борна суларда була...

Гаҗәп, нилектән бу төш миңа 14 ел узгач күренде?.. Рәхмәт күренүең өчен... Күңелдә әлеге газәл. Газаплы да, рәхәт тә...

Бары иртәнге 5ләрдә генә йокыга киттем.

Иртән вокзалга барып, пароходка билет алдым. Пароходның исеме «Богатырь» иде, үзе иске лахан...

23-24.09.1966. Бу «Богатырь» бөтен мәгънәсе белән дә иске лакан булып чыкты: пассажирлары да карт-коры, карчык-парчык, аксак-туксак. Эч поша, язып-сызып алыр өчен дә урын юк.

Ә төш һаман күңелдә. Кайларда икән ул хәзер?.. Җыр да истән чыкмаслыкны әйтә...

... яшьли өзелеп кемне сөйсәң,
күңелең шуларда була...

25.09.1966. Бүген төштә Ульяновск шәһәренә туктадык. Ә иртәгә иртәнге якта Казанда булырбыз.

...Пароходы да, каютасы да, пассажирлары да бер чыбыктан сөрелгән: гел иске-москы. Яхшы әле Мөхәммәт Гайнуллинның соңгы монографиясен кыстырып алган идем (Мөхәммәт Мәһди белән рецензия язарга сөйләшеп куйган идек...), шуны укып мавыкландым. Дөресрәге, вакыт уздырдым. Нигездә, чимал... Көне дә салкын...

26.09.1966. Иртәнге сәгать 5тә Казанга җиттек. Юеш, җепшек иртә каршылады. Типик көзге Казан: нурсыз, җан өшеткеч сорылык, сөяккә үтә торган юеш... Ә яшьлегем узган якларда сентябрьдә кояшлы, җылы, якты була иде.

... яшьли өзелеп кемне сөйсәң...

Йомгак

Экспедиция нәтиҗәсе бик начар. Авыз тутырып сөйләрлек бернәрсә дә юк. Димәк, киләчәктә бу якларга экспедиция оештырып торуның бернәрсәгә дә кирәге юк. Димәк, түбәнрәк төшеп, Әстерхан ягына китү хәерлерәк...

Истә калган әйберләр:

1. Чи кирпеч, балчыктан ясалган, балчык түбәле мазанкалар, тузаннары күпереп утырган урамнар... Ком очуы, җил. Теш түгел, ашказанга хәтле үтеп кергән ком...

2. Надан, мәгәр якты чырайлы, әңгәмә сөюче кешеләр.

3. Кулъязма юклыгы...

4. Актүбә буенда Борис Дашков белән балык каптырып, аш пешереп йөрүләр. Әлеге дәү опты...

5. Волгоградтагы серле төш. Беренче мәхәббәтемнең үзе кебек серле, моңлы, гаҗәеп татлы бер төш...

*Текстны басмага **Диләрә Госманова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Казаковлар мирасын саклыйк!

Рәсем астына: «Казанда потомственный гражданин хаҗи Мөхәммәдҗан Назыйр углы Казаков тарафыннан 1876 нчы елда 20 нче декабрьдә бина кылынган мәсҗеднең рәсеме», – дип язылган.

8 сентябрьдә, Татарстан Диния нәзарәтенең баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, ТФ Академиясе академигы Индус Таһиров, ТР Мәдәният министрлыгының массакүләм мәгълүмат чаралары һәм иҗтимагый оешмалар белән хезмәттәшлек бүлеге мөдире, тарихчы Айрат Фәйзрахманов, Татарстанның атказанган урманчысы Ирфан Халитов, авыл хуҗалыгы белгече, галим-агроном Харис Камалиев, тарихчы, «Безнең мирас» журналы хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин, Гомәр хаҗи Гайнетдинов, мөгаллим-остаз Зөлфәт Мингалиев һәм шәкертләр катнашында, Казандагы Ал мәчеттә күренекле шәхесләребезнең исемен мәңгеләштерү, тарихи биналарны саклау мәсьәләләре турында «түгәрәк өстәл» утырышы узды.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин:

«Казаковлар мәчетен торгызу авыр мәсьәлә»

– Ал мәчет, безнең мәдрәсә бинасы – татар зыялылары өчен билгеле урын. Монда 1786 елда патша хөкүмәте тарафыннан беренче рәсми теркәлгән мәдрәсә ачылган. Мәдрәсәдә халкыбызның танылган мәгърифәтчеләре – дин әһелләре, аталы-уллы Хәмит һәм Мөхәммәт Мортазиннар, Шаһиәхмәд һәм Габделгани Имәнколовлар, Габделкаюм һәм Мөхәммәтгабдулла Габделбадыйковлар, Галимҗан Барудиның энесе Салихҗан Галиев гыйлем биргән.

Мәдрәсәдә 1907 елның маенда татар мөгаллимнәре өчен беренче Бөтенруссия педагогик курслары уза. Анда Казан, Вятка, Пермь, Уфа, Ырынбур, Түбән Новгород һәм башка губерналардан килгән мөгаллимнәр белем ала. Аларга, дин белеменнән тыш, арифметика, геометрия, география, тарих, педагогика фәннәреннән дә дәресләр бирелә, Гаяз Исхакый һәм Әхмәдһади Максуди кебек олуг шәхесләр доклад сөйли. Курслар халкыбызның үткәнен өйрәнү, киләчәген күзаллау мәйданчыгына әйләнә.

Кызганыч, укулар нибары ун гына көн эшләп кала. Тиешле рөхсәт алмаган дигән сылтау табып, Казан губернаторы Стрижевский курсларны ябу хакында күрсәтмә бирә. Мөгаллимнәр арасында тентү үткәрелә, уку әсбаплары, эш дәфтәрләре тартып алына. Шушы вакыйгадан соң Галимҗан һәм Салихҗан Галиевлар, сәүдәгәр Габдулла Апанаев һәм Габделхәмит Казаковлар революцион фирка төзүдә гаепләнеп, Вологда губернасына сөргенгә озатыла. Татар зыялылары бу хәлне чын фаҗига итеп кабул итә. Ике газиз баласы берьюлы читкә озатылган Мөхәммәтҗан Галиев зур хәсрәтеннән вафат була.

Мәдрәсәбез янәшәсендә Яңа Татар бистәсе зираты бар. Казан шәһәрендә инкыйлабка кадәр хезмәт кылып, бакый дөньяга күчкән хәзрәтләребез шунда дәфен кылынган. Аларның исемнәрен барлау юнәлешендә зур эш алып барабыз. Күптән түгел генә атаклы имам Шәйхелислам Хәмидинең каберен табып, аңа таш куйдык. Шиһабетдин Мәрҗани мәдрәсәсен тәмамлаган әлеге хәзрәтнең ике томлык «Әл-иткан фи тәрҗемәтел-Коръән» исемле китабы, Казаннан кала, Истанбулда һәм Катарда да нәшер ителгән. Ошбу бинада Шаһиәхмәд хәзрәт Иманколый имам-хатыйп булып эшли. Аның газиз улы Мөхәммәдсадыйк Иманколый хәзрәтләре ике томлык «Тәсһил әл-бәйән фи тәфсир әл-Коръән» авторы буларак билгеле. Дөрес, репрессия корбаны булган бу хәзрәтебезнең кабере сакланмаган. 1931 елда аны, кулга алып, Пермь ягына озаталар. 400ләп тоткынны кечкенә елга пароход трюмына дыңгычлап төйиләр. Карт, авыру кеше, юлда өзлегеп, Красновишерск шәһәренә җиткәч, төрмәдә вафат була. Мәетне җирләргә шәһәр мөселманнарына бирәләр. Ул бу шәһәрнең татар зиратында күмелә. Әлеге зират кәгазь-картон фабрикасы астында кала. Әмма аның Яңа Татар бистәсе зиратында җирләнгән әтисе Шаһиәхмәднең каберен саклап калдык.

Безнең мәдрәсәдә укытып, тәҗвид һәм гарәп теле дәреслекләре язган Салихҗан Мөхәммәтҗан улы Галиевның һәм башкаларның каберләре дә тәртипкә китерелде.

Бүгенге җыенлыбызны әлеге бинада татар зыялыларының беренче укуларын оештыруга зур көч куйган Габделхәмит Казаковның нәселенә багышларга булдык. Казаковлар нәселе татар халкының бик күп танылган шәхесләре белән мөнәсәбәттә торган. Моңа мисал итеп, Мөхәммәтҗан Казаковның Бәдыйгыҗамал аркылы атаклы Юсуповлар нәселе белән бәйләнешен әйтергә була. Оныклары Зөләйханың Абдулла Апанаев белән, Бибирабиганың профессор Газиз Гобәйдуллин белән никахлашуын беләбез. Атаклы революционер Мулланур Вахитовның әнисе – Өммегөлсем Казакова. Мостафа Казаковның оныгы Мәрьям – Гражданнар сугышы герое, генерал-лейтенант Якуб Чанышевның хатыны. Исхак Казаков – Татарстанда Халык Комиссарлары Шурасы рәисе булып эшләгән шәхес. Казаковлар нәсел агачының тамырлары тирән булган кебек, ботаклары да бик югары сузылган. Бу бик шанлы нәсел.

«Дөрес, Казаковлар мәчетен торгызу авыр мәсьәлә. Аның урыны хәзерге Татарстан урамындагы 13 нче йортка, юл читенә үк туры килә. Казанга Феофан хәзрәтләре килгәч, ул Казан Изге Ана иконасы соборының борынгы фундаментын ачтырып, шул нигездә өр-яңа гыйбадәтханә төзетте. Бәлки, бездә дә, шуннан үрнәк алып, Казаковлар мәчетен торгызыргадыр.

Дөрес, Казаковлар мәчетен торгызу авыр мәсьәлә. Аның урыны хәзерге Татарстан урамындагы 13 нче йортка, юл читенә үк туры килә. Казанга Феофан хәзрәтләре килгәч, ул, Казан Изге Ана иконасы соборының борынгы фундаментын ачтырып, шул нигездә өр-яңа гыйбадәтханә төзетте. Бәлки, бездә дә, шуннан үрнәк алып, Казаковлар мәчетен торгызыргадыр.

Ләбиб Лерон:

«Тәтештә татар музее булырга тиеш»

– Бу ел башында Тәтештә булдым. Тәтештә татарлык юк! Шәһәрдә 99 урам исеме бар. Шуның нибары 4есе генә татар исемендә: Мулланур Вахитов, Муса Җәлил, Гыйлем Камай һәм Габдулла Тукай урамнары. Тәтеш музеенда, ике стендтан кала, татарның бер әйберсен дә күрмәссез! Әтрәч авыллары белән данлыклы Тәтеш ягы!.. Шушы шәһәрдә совет властен урнаштырган кешеләрнең

берсе – Исхак Казаков. Казаковның укучысы Гыйлем Камай – атаклы химик, Казан университетының ректоры булган шәхес. Һади Маликов – полковник, разведчик, СССРның Ирандагы хәрби атташесы, Кытайның Синьцзян провинциясендә хәрби киңәшче булган кеше. Ул да Казаковның шәкерте. Мулланур Вахитов та Тәтешкә кайтып йөргән. Декабрь аенда Исхак Казаковның туууына 130 ел тула. ТАССРны оештыруда 7 кеше катнаша. Шуларның берсе – Исхак Казаков. Ә аның улы Хаҗиморат Казаков – күренекле рәссам, ул нәни Апуш картинасын иҗат иткән. Хәзерге көндә Тәтештә Исхак Казаков яшәгән бинага истәлек тактасы куйдырырга, иң матур урамнарының берсенә Исхак һәм Хаҗиморат Казаковлар исемен бирергә кирәк. Өченчедән, Тәтеш шәһәрендә татар шәхесләренә нисбәтле музей булырга тиеш һәм ул Исхак Казаков укыткан мәктәп бинасында булса, тагын да яхшырак булыр иде.

«

Хәзерге көндә Тәтештә Исхак Казаков яшәгән бинага истәлек тактасы куйдырырга, иң матур урамнарының берсенә Исхак һәм Хаҗиморат Казаковлар исемен бирергә кирәк. Өченчедән, Тәтеш шәһәрендә татар шәхесләренә нисбәтле музей булырга тиеш һәм ул Исхак Казаков укыткан мәктәп бинасында булса, тагын да яхшырак булыр иде.

Индус Таһиров:

«Кадимилек – татарның көч җыйган чоры»

– Хәзерге көндә милләтебез исән икән, монда ислам диненең роле зур. Кадимилек – татарның үз-үзенә бикләнеп, ныгып, көч җыйган чоры. Шушы көч тупланганнан соң гына, җәдитчелек үсеп чыккан. Без бу күренешләрне бер-берсенә каршы куярга түгел, ә чагыштырып, аларга гадел бәя бирергә тиеш.

Татарлар революциягә кадәр Россиянең иң укымышлы халкы була. Һәр авылда мәктәп-мәдрәсә эшләгән. Татарлардан руслар да киңәш ала торган булган, чөнки халкыбыз мәгълүмати яктан күпкә баерак. Бабаларыбыз шәрык телләрен белгән. Димәк, алар өчен дөнья киңрәк булган. Монда мәдрәсәләребезнең роле искиткеч зур.

Мәчетләрдә вәгазьләрнең татар телендә баруы бик күркәм күренеш. Кайвакыт: «Монда башка милләт кешеләре дә бар», – дип әйтәләр. Әгәр дә син татар мәчетенә килгәнсең икән, татар телен тыңла, белмисең икән, өйрән! Мәчетләребездә татарлык һәм татар теле тантана итәргә тиеш!

Шанлы дәүләтләр төзегән халык бүген ни өчен дәүләтсез калды? 1552 елгы фаҗига нигә барлыкка килде? Ни сәбәпле татар коллык упкынына төште. Төп сәбәп – татарның бердәмлеге җитмәү. Бер-берсенә ук атып яшәде татар. Данлыклы татар нәселләре, чукынып, рус милләтен алга сөрде. Камай морза кебек мөртәтләребез Явыз Иваннарга Казанны яуларга булышты. Бүген бер-беребезгә ярдәм итеп тору кирәк. Син теге яки бу кешене күңелең белән кабул итмәсәң дә, аның татарлыгын, динебезгә, милләтебезгә хезмәтен кабул ит. Ызгышма, талашма, бердәм бул!

Шикләнмим, халкыбызның киләчәге зур. Җир Кояш тирәсендә никадәр әйләнсә, татар да шулкадәр яшәячәк. Бөек һәм мисали халык булып гомер итәчәк!

Ильяс хәзрәт Җиһаншин:

«Бу мәчетләрне безгә амәнәт итеп татар байлары төзеде»

– Татар теле асылда мәчетләрдә булды. Әмма Россиянең татарлар төзегән күп кенә мәчетләренең бер ишләренә башка милләт вәкилләре хуҗа. Кайчандыр бу мәчетләрне безгә амәнәт итеп татар байлары төзеде. Алар аны безнең балаларыбызга, оныкларыбызга тапшырды. Бу мәчетләр татарлар кулында булырга тиеш! Андагы вәгазьләр дә татарча укылсын иде. Аллаһы Тәгалә каршына без татар булып килгәнбез икән, шулай яшәргә һәм алга барырга тиешбез.

«Аллаһы Тәгалә каршына без татар булып килгәнбез икән, шулай яшәргә һәм алга барырга тиешбез.

Җәлил хәзрәт Фазлыев:

«Күзгә төтен җибәрү өчен генә булмасын»

– Социологлар фикеренчә, бер фикердә булган 200 кеше теләсә кайсы массаны үз артыннан ияртә ала. Шөкер, галим-голәмәбез җитәрлек. Әмма үткәндәге фидакярләребезне барлау гына җитми, бер-беребезне бәяли дә белергә тиешбез. Бер татар фәнни ачыш ясый икән, өчесе аңа каршы чыга!

Хәзерге көнгә кадәр без татар телендә сөйләшүне модага, мәчеткә йөрүне гадәткә кертә алмыйбыз. Күпләребез мәчеткә картаеп, гөнаһ кылырга «хут» беткәч кенә килә. «Аллаһының җебенә ябышыгыз, аерылмагыз», – дигән аятьне әйтә-әйтә утыз ел таркалып барабыз. Хәлебез мактанырлык түгел…

Тәтештәге рус-татар мәктәбенең бер бинасы

Бу уңайдан бер мәзәк искә төште. Сталин поездда бара икән. Поезд туктап калган да: «Юл бетте!» – дигәннәр аңа. Сталин: «Иртәгә үк юлны төзеп бетерергә һәм алга барырга! Юл булмаса, гаеплеләрне атарга!» – дип боерган. Хрущев шундый ук ситуациядә: «Арттагы юлны сүтегез дә алга салыгыз, хәрәкәтне дәвам итегез!» – дигән. Брежнев: «Күп итеп халык җыегыз да поездны селкетеп торыгыз, өстәгеләр поезд бара дип уйласыннар», – дип җавап биргән.

Безнең җыелып сөйләшүләр, аеруча тел мәсьәләсендәгеләре халык алга барабыз дип уйласын, күзгә төтен җибәрү өчен генә оештырылырга тиеш түгел. Аның нәтиҗәсе булсын иде.

Айрат Фәйзрахманов:

«Хәтер тамгалары кирәк!»

– Казаков мәчетен, олы юл читендә булу сәбәпле, социалистик проспектны бизәми, дип сүткәннәр. Мәчет нык булган, аны башка максатларда да файдалана алырлар иде, сүтәр өчен ихтыяҗ да булмаган. Мәчетне, күпләр әйткәнчә, бер төндә түгел, ә берничә ай сүткәннәр. Яңа бистә кешесе булган әтием бу вакыйганы бик яхшы хәтерли иде. Бина шулкадәр яхшы төзелгән ки: аны зур техника ярдәмендә генә җимерә алганнар. Мөгаен, бу эш җиренә җиткереп башкарылмагандыр, мәчетнең нигез ташлары сакланып калган булырга тиеш.

Хәзер Казанның юкка чыккан монастырьлары урынына хәтер тамгалары кую буенча эш башланып китте. Кремльдәге Спасо-Преображенский монастыре урынына хәтер тамгасын кую буенча Президентыбыз исеменә хат язылды һәм уңай хәл ителде дияргә була. Милли китапханә урынында элек Троице-Феодоровский монастырь эшләгән. Монда да хәтер тамгасы куярга уйлыйлар. Шулай итеп, юкка чыккан мәчет һәм хәтта зират урыннарына да хәтер тамгаларын кую буенча эшне башлап җибәрергә кирәк. Аерым архитектура композицияләрен дә булдырырга мөмкин.

Казандагы Казаковлар мәчете зират өстендә урнашкан була. Күптән түгел генә КФУ хастаханәсе янындагы борынгы зират урынында парковка ясалды. Югыйсә андагы кабер эзләре ачык беленеп тора иде. Юкка чыккан монастырьларга хәтер тамгалары куела икән, нигә сүтелгән мәчет, борынгы зират урыннары халыкка билгеле булмаска тиеш?!.

«Юкка чыккан монастырьларга хәтер тамгалары куела икән, нигә сүтелгән мәчет, борынгы зират урыннары халыкка билгеле булмаска тиеш?!.

Ләбиб Лерон:

«Тукай янына җыелганда ишаннарның каберен таптыйбыз»

– 1986 елны Габдулла Тукай каберен яңарткан вакытта аның янәшәсенә җирләнгән бик күп ишаннарның каберләре юкка чыга. Тукай кабере янына җыелганда, без башкаларның каберләрен таптыйбыз. Мөгаен, бу урында да, кемнәр җирләнгәнен күрсәтеп, истәлек билгесе куярга кирәктер.

Ильяс хәзрәт Җиһаншин:

«Бу – мөхтәрәм хәзрәтләр җирләнгән урын»

– Әлбәттә, бу – мөхтәрәм хәзрәтләр җирләнгән урын. Габдулла Тукай вафат булгач, аны атаклы имам Шәйхелислам Хәмиди янына дәфен кылалар. Әхмәдһади Максуди, Мөштәриләр, Әҗем мәчетенең Хисаметдин хәзрәтләре дә шул тирәдә күмелгән.

Юрьев полкының рядовой солдаты
Исхак Казаков

Тәтеш рус-татар мәктәбе мөгаллимнәре:
Исхак Казаков, Нәфисә Казакова,
Кәбир Ихсанов, Фатыйх Шәмсетдинов

Гомәр Гайнетдинов:

«Безне, кечкенә малайларны, зиратка йөгертәләр иде»

– Яхшы хәтерлим: зиратның элеккеге таш коймасы Тукай кабереннән бер метр чамасы гына читтә иде. Якында гына җәяүлеләр керә торган капка. Аның ике ягында да әбиләр утыра иде. Капканың сул ягында пәйгамбәребезнең (с.г.в.) нәселеннәнме, сәедләрдәнме булган изге зат җирләнгән, диләр.

Яңа Татар бистәсе зиратында икенче изге җир – җиде игезәк кыз күмелгән урын. Анда куаклык, ә әйләнәсен әбиләр урап алган иде. Кемнең сәдака бирәсе яки берәүнең рухына Коръән чыгасы бар – әлеге изге гамәлләрне шунда башкаралар иде. Берәрсе авырып китсә безне, кечкенә малайларны, сәдака бирергә йөгерттеләр.

Соңрак зират зурайтыла, Фатих Әмирханнар иске койманың тышына җирләнә. Хәзерге вакытта да борынгы койманың калдыкларын очратырга мөмкин. Ул кызыл кирпечтән салынган, киңлеге 50-70 см чамасы. Аның кеше керә торган урыны тапталып, уелып беткән иде.

Совет чорында Казанда гает намазларын кимендә ике мәртәбә укыдылар. Беренче укучылар – көндезге сменага эшкә баручылар. Аннары картлар, пенсионерлар, бала-чага җыела. Сталин заманында да гаеткә тәкъбир әйтеп, Тукай, Каюм Насыйри урамнары буенча Мәрҗани мәчетенә баралар иде.

Безнең ишегалдында өч йорт иде. Берсе – Сираҗетдин улы Мөхәммәдгали ишан йорты. Икенчесе – Хәсән абзыйныкы, өченчесе – Долговларныкы. Элек Бишбалта ягында су күтәрелгәнче Долгое исемле күл була. Аларның фамилиясе шуннан килеп чыккан. Җәмил һәм башка күлләр бар иде.

Харис Камалиев:

«Тәтеш музеена кереп чак еламадым. Анда безнең шәхесләр юк...»

– Тәтешнең дөньяга мәгълүм илле йортлык Үтәмеш авылы бар. Ул авылдан ике академик, бер герой, дүрт министр чыккан. Мозаффар Таҗетдин улы Мөштәри дә – Үтәмештән, ул Истанбулда белем алган. Аның улы Хәмит Мөштәри – Тәтештә ачылган мөгаллимнәр курсында укыта, татарлар арасында беренче физика-математика фәннәре докторы, профессор, татар телендә беренче физика дәреслеген язган кеше.

«Алга» колхозы җитәкчеләренең, баш белгечләренең 90 проценты Үтәмештән иде. Бу авылда без укыганда да дүрт класс иде, хәзер дә шулай. Авыл яши! Тәтеш, Буа Сабан туйларының да баш батырлары Үтәмеш егетләре.

Кызганыч, Тәтеш музеенда мәшһүр якташларыбызның хезмәте бик аз яктыртылган. Анда булып, чак кына елап чыкмадым. Дөрес, Идел буендагы Тәтеш – сәүдәгәрләр шәһәре, анда балыкчылар яшәгән, әмма татар тарихы да үзәктә булырга тиеш! Тәтеш районыннан чыккан шәхесләрнең исемен мәңгеләштерү юнәлешендә бергә эшләсәк иде.

«Кызганыч, Тәтеш музеенда мәшһүр якташларыбызның хезмәте бик аз яктыртылган. Анда булып, чак кына елап чыкмадым. Дөрес, Идел буендагы Тәтеш – сәүдәгәрләр шәһәре, анда балыкчылар яшәгән, әмма татар тарихы да үзәктә булырга тиеш!

Догалы эш уңышлы. Фотода «түгәрәк өстәл»дә катнашучылар

Ирфан Халиков:

«Гади генә эшләрне дә башкарырга мөмкин»

– Татар тарихын пропагандалауда гади генә эшләрне дә башкарырга мөмкин. Мисал өчен, татар телендә өстәл календарьлары бастырырга һәм аны һәр җитәкченең өстәленә салырга кирәк.

Зөлфәт хәзрәт Мингалиев:

«Иске кабер ташларын саклау буенча фонд оештырырга кирәк»

– Киләсе елда Беренче Бөтенроссия мәдрәсә мөгаллимнәре корылтае узганга 115 ел тула. Бу зур вакыйганы онытырга ярамый, шул уңайдан да мәдрәсәбезгә истәлек билгесе куйсак, бик яхшы гамәл булыр иде. Әйткәнебезчә, курсларны оештыруда Габделхәмид Казаков та катнашкан. Мәдрәсәбез мөгаллимнәре Габделкаюм хәзрәт Габделбадыйков һәм Шаһиәхмәд хәзрәт Иманколовларның кабер ташлары тиздән төзекләндереләчәк. Казанда тарихи яктан әһәмиятле иске кабер ташларын саклау буенча фонд оештырырга кирәк дип уйлыйм.

*Текстны басмага **Ленар Гобәйдуллин** әзерләде.* ■

Эстәрлебаш дарелфөнүне*

Зәки Зәйнуллин

Баш мөхәррирләр Вахит Имамов, Рөстәм Галиуллин, Ләбиб Лерон каләмдәшләре Хисаметдин Исмәгыйлев һәм эшкуар Ягъфәр Хисмәтуллин белән мәгърифәтче Мөхәммәдшакир Тукаев һәйкәле янында. Эстәрлебаш, 2021 ел

Башкортстанга сәфәребез вакытында Эстәрлебаш авылындагы бай татар мирасы белән дә таныштык. Заманында биредә университетка тиң булырлык мәдрәсә эшләгән. Әхмәдзәки Вәлиди, Мирсәет Солтангалиевләр кебек шәхесләр шунда белем алган. Аларның остазы данлыклы мөгаллим, ахун, 2 нче һәм 3 нче чакырылыш Дәүләт Думалары депутаты ***Мөхәммәдшакир Мөхәммәтхарис улы Тукаев*** *(1862-1932) була. Эстәрлебашлылар әлеге шәхесне зурлый, аның исемен мәңгеләштерү өчен һәйкәл ачканнар, музейда махсус экспозиция эшли һәм шушы авылда яшәп, күптән түгел генә бакый дөньяга күчкән каләмдәшебез Зәки ага Зәйнуллин (1933-2021) да аны үзенең әсәрләрендә еш искә ала. Язучының «Эстәрлебаш дарелфөнүне» исемле әсәреннән өзек тәкъдим итәбез.*

Редакция

---

* Шул исемдәге повестьтан өзек.

Мөхәммәдшакир Тукаев

Мөхәммәдшакирның улы Мөхәммәдзакир Тукаев

Ишан, мөдәррис Мөхәммәдшакир Тукаев урыныннан тормыйча бик озак утырды. Башыннан төрле-төрле уйлар үтте. Тик аларның берсе дә якты, өметле түгел иде...

Шәкертләрне ике көндә тараттылар. Шакир мәгъзүмнең башында иң мөһим бер генә уй калды: «Эстәрлебаш мәдрәсәсе китапханәсен нәрсә эшләтергә, кая куярга? Анда бит 65 меңнән артык кульъязма, ташка баскан, нәшрият бастырган китаплар бар. Зур гыйльми байлык – күбесе дөньяда сирәк китаплар санала бит...» Атна үтми, карар кылынды: «Китапларны Уфа, Казан, Ырынбур китапханәләренә таратырга!»

Шул ният белән алты шәкертне кала китапханәләренә җибәрде: «Сирәк, кыйммәтле китаплар. Үзегезнең китапханәгә бер өлешен алыгыз!» Атна-ун көн узуга, шәкертләр барып кайттылар. Өч каладан да җавап бер иде: «Совет хакимияте китапханәсенә дини китаплар кирәкми. Теләсә кая куегыз!»

Шәкертләр кайтканнан соң, Мөхәммәдшакир ишан берничә көн уйланып вакытын уздырды: «Берничә йөз ел җыелган китапханә бит. Аны бит Салавыч авылында ук Урманай бабай җыя башлаган. Габтукай бабай Бохарадан йөздән артык китап алып кайткан. Мәккәгә хажга барган авыл мөселманнары аннан да алып кайтканнар. Галишәр, Гайни, Фирдәвес, Гомәр, төрек шигырьләре бик күп. Нәрсә эшләргә?»

Бер карарга да килә алмагач, мәдрәсәнең гыйлемле хәлфәләреннән саналган ике дустын чакырды. Берсе – Эстәрле Каргалысы авылына нигез салучы Монасыйп мулла нәселеннән килгән Вахит хәлфә, икенчесе Коръәнне яттан белгән бик белемле Мәҗит Карый хәлфә иде.

Майлы коймак ашап, чәй эчә-эчә, бик озак утырдылар идәндәге асыл палас өстендә. Асрау кыз керткән ике самавыр чәй эчеп бетерделәр. Тик күпме генә баш ватсалар да, китапханәне нәрсә эшләтергә дигән сорауга җавап таба алмадылар.

Кәефләре бозылып, таралырга кирәктер дигән уй керде башларына. Шунда Вахит хәлфәгә җан кергән кебек булды. Ул болай дип сөйли башлады: Мәгъзүм

Эстәрлебаш музеендагы экспонатлар

абзый! – диде ул ишанга. – Минем башка әйбәт бер фикер килде бит. Аны безгә Ходай җибәргәндер дип уйлыйм мин.

– Шулаймы? – диде ишан. – Безгә дә әйтеп кара, тыңлыйк. Ходайдан булса, безнең өчен дә мәслихәт булыр.

– Менә теге Ходай бәндәсе, ике көн элек сиңа кереп мәдрәсәне яптырган мәхлук җанны әйтүем. Үзе безгә акча түләмәсә дә, эшләгәнебез өчен Совет хакимияте исеменнән мәдрәсәне яптыра. Без хәзер, ике йөз елдан артык халыкка белем биргән, агарткан, алга алып барган мәдрәсәсез калдык. Мондагы, урындагы хакимият Мәскәүдән Лениннан килгән күрсәтмәләрне, указ-кануннарны үтәп кенә яши. Үзеннән бернинди канун да чыгармый. Мәскәүдән Уфа аша нәрсә кушалар, шул аларга канун. Монда бит безнең белән җитәкчелек итүне тик Мәскәү генә

алып бара. Минем уемча, Мәскәүгә барырга һәм мәгариф буенча үтенеч белән Халык комиссары Луначарскийга керергә кирәк.

– Нинди үтенеч булырга тиеш?

– Мәскәү Көнчыгыш мөселман илләре белән мөнәсәбәт урнаштыра. Әфган, Пакистан, Иран, Төркия һәм гарәп илләре белән мөнәсәбәтләр алып бару өчен Рәсәйдә ислам белемле шәхесләр кирәкме? Кирәк. Әйдә, без үтенечне Луначарскийга җиткерик. Безнең авылда – Эстәрлебашта – ислам университеты ачсыннар. Безнең китапханә бик бай, сирәк мөселман илләрендә генә мондый китапханәләр бар. Авыл уртасында койма эчендә халык йортларыннан аерылып утырган менә дигән мәдрәсә биналары бар. Егерме өч йорт. Өч мәчет, чишмәдән торба белән су үткәрелгән. Барлык зур урамнарга, Тукаевлар йортларына һәм мәдрәсәләргә, олы мәчеткә су агып килә. Ике йөз елдан артык ислам динен, ислам фәннәрен, җәграфия, арифметика, тарих укытыла. Өстәвенә, дүртьеллык урыс телендә укытыла торган ышкулыбыз да бар. Безнең авыл кебек гыйлемле, белемле, зур мәдрәсәле башка авыл юк Рәсәйдә.

Хәзрәтнең кызлары Мәрьям һәм Рабига

Мәскәүдә, Ленин хакимиятендә, Луначарский фамилияле Халык комиссары бар. Белем, уку йортлары буенча халык комиссары. Шуңа барыйк, керик, безне кабул итәр. Сөйлик аңа Эстәрлебашның борынгы мәдрәсәсенең бүгенге хәлен, аның биналарының күплеген һәм зур китапханәсе барлыгын. Хәлфә-укытучылар – бар да үз урыннарында.

Шакир мәгъзүм:

– Безне тыңласалар ярый да бит. Ленин хакимиятендә моңарчы эш белән шөгыльләнмәгән, рибәлютсия дип кенә йөргән белемсез халык кереп тулган. Күреп торасың бит, бөтен җирдә Гражданнар сугышында камисар булганнар утыра. Тиешле белем юк аларда. Безнең авылны гына кара, рибәлютсиягә хәтле ат карагы булган Хәйбер Чолык бүген дә ярлылар кәмитите рәисе. Авыл Сәвитенә дә буйсынмыйча, азык атрәтләре белән егерме икенче елга хәтле авылны талады. Ул ярлылар кәмититенең бүген кирәге бетте, ә Чолык һаман халык өстеннән күзәтчелек итә, ГПУга хәбәр биреп тора икән. Мәскәү?! Нишләргә?!

Вахит, синең уй бик төпле. Мәскәүгә барырга кирәктер. Мин инде урысчам бик йомшак карт, Мәҗит тә урысча белми диярлек. Вахит, сиңа барырга туры килә инде. Мин юллык акча бирермен. Кайчангарак юлга чыгарсың икән? Уфага барып шуннан поезга утырып китәргә кирәктер инде…

– Мин атна-ун көннән юлга кузгалырмын. Сузарга ярамый, барырга кирәк.

Шул сөйләшүдән соң Вахит Монасыйпов унике көн узгач, 1923 елның апрель башында Мәскәүгә сәфәргә чыгып китә… ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Наил Вазыйхов: «Яшьләрне авылда калдыру – мөһим мәсьәлә»

(Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы Наил Альберт улы Вазыйхов белән Ләбиб Лерон әңгәмәсе)

– Кама Тамагында туып-үскән кеше буларак, Сез аның табигатен, кешеләрен яхшы беләсез. Татарстаныбыздагы иң гүзәл районнарның берсен җитәклисез. Идел һәм Чулман елгалары кушылган урын – ата-бабаларыбызның мал токкан, иген иккән борынгы җирләре. Җитәкчелек эшенә керешеп китү тарихы ничек булды?

– Кама Тамагындагы рус мәктәбен, Казан авыл хуҗалыгы институтын тәмамлап, туган ягыма кайтып инженер булып эшләргә теләдем. Әмма бу юнәлештә эш булмау сәбәпле, суднолар ремонтлау заводына эшкә урнаштым. Механизация факультетын тәмамлаганга күрә, миңа сызымнарны уку бик җиңел бирелде. Әлеге заводта мастер, цех начальнигы, прораб, директор булып хезмәт иттем.

Шуннан соң Кама Тамагы районын җитәкләргә тәкъдим иттеләр. Безнең тормышта иң кадерлесе – кешеләр. Аларның сиңа мөнәсәбәте синең аларга мөнәсәбәтеңә турыдан-туры бәйле. Бу җәһәттән мин үзебезнең район кешеләренә бик рәхмәтле. Алар миңа һәрчак терәк булдылар. Дөрес, халыктан мөрәҗәгатьләр күп килә, барысын да гел уңай хәл итеп бетереп булмый. Финанс һәм юридик

яктан да каршылыклар чыгып тора. Мәсәлән, хәзерге вакытта районда туризмны үстерү юнәлешендә актив эш алып барабыз. Әмма дәүләт саклавында булган табигый территорияләрне туризм максатыннан файдалану, җирләрне бер категориядән икенчесенә күчерү, урман фонды мәйданын туристик рекрацион максатларда рациональ куллану буенча проблемалар бар. Болар – озак вакыт хәл ителә торган мәсьәләләр. Әмма, ничек кенә булса да, районда яшәүче халыкка уңай, яхшы шартлар тудырырга омтылам.

Әтием Альберт мәктәптә хәрби хәзерлек, физик тәрбия фәннәре укытучысы иде, ә бабам – Авыл Советы рәисе, май заводы директоры, аэропорт начальнигы булып эшләде. Ул лаеклы ялга киткәч, аның хезмәтен әтием дәвам итте. Әнием Әминә гомере буе икътисадчы булып хезмәт куйды.

– Һәр районның үзенчәлеге бар. Сез туризмны үстерү белән ныклап шөгыльләнә башладыгыз...

– Туризм – заманча юнәлеш. Әмма Кама Тамагы – авыл хуҗалыгы районы. Кызганыч, соңгы елларда инвесторлар еш алышынды. Шул сәбәпле авыл хуҗалыгы шактый түбән тәгәрәде. Узган ел «Август» фирмасы үзенең филиалын булдырды, аңа гаять зур өметләр баглыйбыз. Алар, миллиардларча акча кертеп, күпләп техника сатып алды, ашлык киптерү җайланмалары, складлар төзеде. Игенчелекнең киләчәге булыр дип уйлыйм. Дөрес, терлекләрнең баш санын күпкә киметтеләр. Барлык авылларда да терлекчелек комплексларын яптылар. Сөйкидә генә 750 баш мөгезле эре терлеккә исәпләнгән заманча фермалар калды, киләчәктә аны зурайтырга ниятлибез. Заманча терлекчелек комплекслары алга таба да төзелер дип уйлыйм. Бу турыда сөйләшүләр бара.

– Кама Тамагын алга җибәрү, таныту юнәлешендә тагын нинди үзгәрешләр кертергә ниятлисез?

– Районыбызның табигате гаҗәеп матур, туристларны үзенә җәлеп итеп тора. Әмма туризмга гына ябышып ятарга ярамый. Дөрес, туризм кибетләр, кунакханәләр, гомумән, шәхси бизнесның үсешенә зур йогынты ясый. Шуңа ияреп, авыл туризмының да үсеше сизелә. Киләчәктә бу юнәлеш өстенлекле булырга тиеш. Бүген авыллар үсеше өчен бөтен мөмкинлекләр дә бар. Инвестордан бушап калган иске фермаларда фермерлык эшен дәвам итәргә була. Без аларны бик очсыз бәягә, хәтта бушлай диярлек озак вакытка арендага бирә алабыз. Авыл җирендә рәхәтләнеп бизнес белән шөгыльлән. Авыл туризмы өчен сарык, кәҗә, каз, үрдәк тә асрарга була. Елга һәм күлләр, табигый болынлыклар җитәрлек, эшлә генә.

Туристларның табигатькә мөнәсәбәтен үзгәртергә телибез. Гадәттә, турист безнең районга килә, палатка корып йоклый, үзеннән соң учак көле, янган үлән, ә кайбер намуссызлары чүп өеме дә калдырып китә. Безнең бурыч – Аллаһы Тәгалә яралткан күркәм табигатебезне саклау һәм аны киләчәк буынга шундый хәлдә тапшыру. Менә шушы туристларны авыл җирлекләренә якынайтасы, аларга кемпинг урыннары, яхшы туристик продукт тәкъдим итәсе иде. Шәһәр кешесенә авыл өендә йоклау рәхәт булыр дип уйлыйм. Ул шунда тавык йомыркасы ашасын, яңа сауган сыер һәм кәҗә сөте эчсен, азык-төлек җитештерү процессын, авыл тормышын күрсен һәм бу эшкә үзе дә катнашсын иде. Шул очракта авылларда җитештерелгән продукция дә сатылыр, өстәмә эш урыннары да булыр.

Кооперативларны, эре фермер, шәхси хуҗалыкларны үстерү бурычы да актуаль. Шуңа өстәп, районда сәнәгать парклары да кирәк. Татарстандагы күп районнарда сәнәгать парклары булса, бездә әлегә алар юк. Хәзерге вакытта инвестор

КАМСКОЕ УСТЬЕ

АРГАМАК

«Кама Тамагы минем изге төбәгем. Анда минем ата-бабаларымның каберләре, ул җирдә мин дөньяга беренче кат аваз салганмын, шул җирнең туфрагына беренче тапкыр аяк басканмын. Ул җир минем җанымның, рухымның иң газиз кисәге. Илһамымның чыганагы».

Туфан Миңнуллин

эзлибез, җир һәм мәйдан әзер, газ, электр кертелгән. Дөрес, Кама Тамагының гипс руднигы яхшы гына эшләп килә. Алар Тенишево авылы янында гипс ташы чыгара, төрле фракциядә ваклый. Моннан тыш «AKSOLIT» заводы да уңышлы гына эшли. Алар гипс чыгарып кына калмый, аны эшкәртеп, гипсокартон, штукатурка, җилем (кләй) һәм башкаларны җитештерәләр. Судно ремонтлау предприятиесе дә яхшы эшли. Әмма боларда гына тукталып калырга ярамый, алга таба үсәргә, яңа эш урыннары булдырырга кирәк. Максатыбыз – яшьләрне районда калдыру.

Кызганыч, әлегә реаль картина шатланырлык түгел: елына 200-300 кеше читкә китә, туу күрсәткече түбән, авылга кайтучыларның да күбесе пенсия яшендә. Келәнчедә нинди зур мәктәп бар, яхшы ремонт ясалган, тик анда нибары ике бала белем ала. Районны яшәртергә, кешеләрне саклап калырга кирәк. Туризм, аерым алганда, авыл туризмы бу юнәлештә ярдәмче булсын иде.

Идел һәм Кама елгаларын балыкчылар бик ярата. Әмма хәзерге көнгә кадәр Кама Тамагында балык эшкәртү заводы юк. Бу совет чорында да булмаган. Балыкчыларыбыз тоткан балыкны Лаешка тапшыра. Балык эшкәртү цехы әзер, инде җиһазлар сатып аласы калды.

Район үзәгенең, авылларның матурлыгын, төзеклеген кайгырту да мөһим мәсьәлә. Бетеп баручы авылларда җимерек йортлар, каралмаган нигезләр күбәя. Әмма аларга кагылырга, сүтәргә яки төзекләндерергә безнең хакыбыз юк. Чөнки варислары барлыкка килеп, безгә җитди дәгъва белдерергә мөмкиннәр. Бу йортлар авылның йөзен бер дә бизәми, янгын куркынычсызлыгы турында да онытырга ярамый. Хәзер ташландык йортларның варисларын ачыклау, аларны туган нигезйортка тарту, аның турында кайгырту мәсьәләсендә дә җитди эш алып барабыз. Алар бирегә кайтсыннар, ата-бабалары нигезләрен тәртипкә салып, чистартсыннар, төзекләндерсеннәр иде. Бәлки, шуннан соң туган җиргә, туган нигезгә даими тартыла башларлар иде. Туган нигез үзләренә кирәк булмаса, балалары, оныклары кызыксыныр. Күрәсез, Кама Тамагы искиткеч гүзәл урын. Биредә рәхәтләнеп яшәргә, агротуризм һәм бизнес белән шөгыльләнергә мөмкин.

– Районнарның нуры – шәхесләр. Кама Тамагыннан да гаять күп талантлы шәхесләр чыккан...

– Туфан абый Миңнуллин – районыбызның йөзек кашы. Ул үзенең туган ягы Мәрәтхуҗаны бик яратты. Хәзер анда музей булдырдык, асфальт салынды, йортын төзекләндердек, күлне чистарту проекты эшләнде. Андагы авыл халкы тырыш, бердәм, эшчән һәм бик тә актив. Үзара салым программасында катнашып, һәр йорттан бишәр мең сум акча җыйдылар һәм шул суммага зиратның киртәсен күгәрми торган калайга алмаштырдылар, хәтта зиратка бара торган күперне дә төзекләндереп куйдылар. Район үзәгендә 300 сум салым җыю да зур авырлык белән башкарылса, алар 5әр мең җыйды һәм бу акчаны авыл файдасына тотты.

Классикларыбыз Фатих Халиди, Ибраһим Газиләр дә бередән чыккан. Районда талантлы шәхесләр җитәрлек. Әйткәнемчә, бүген иң мөһиме – эш урыннары булдыру, яшьләрне авылда калдыру, аларны агробизнеска, фермерлык эшенә җәлеп итү.

Кама Тамагы

(Казандагы якташлар җыры)

Рәдиф Сәгъди шигыре,
Зиннур Гыйбадуллин көе

Каршы яктан алтын кояш чыга,
Нур сибелә Болгар җиреннән.
Җәй айлары матур Тау ягында,
Китә алмыйм кайткач өемнән.

Кушымта:
Кама, Кама – минем туган ягым,
Гашыйк булып ярлар сөйгән як.
Үткәннәргә юллар булмаса да,
Онытылмый шунда үскән чак.

Тау ягында калды сөйгән ярлар,
Ай яктысы, учакта утлар;
Алма, чия бакча эчләрендә
Бергә үткән татлы минутлар.
Кушымта.

Кайткан саен тау башына менеп,
Күзем салам тирә ягыңа.
Гөлбакчалар, чишмә-сулар аша
Юллар төшә Идел ярына.

Кушымта:
Кама, Кама – минем туган ягым,
Гашыйк булып ярлар сөйгән як.
Үткәннәргә юллар булмаса да,
Онытылмый шунда үскән чак. ■

«Безнең мирас» котлый!

Танылган шәхесләребез – галимнәр, язучылар, журналистлар, дин һәм сәнгать әһелләре ноябрь аенда үзләренең гомер бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Менә алар:

1 ноябрь – композитор, фольклорчы галим, ТР һәм РФ Композиторлар берлеге әгъзасы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2002) **Котдус Мирзасалих улы Хөснуллин**га 80 яшь (1941);

11 ноябрь – шагыйрь һәм драматург, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе (2002), Республиканың М.Җәлил исемендәге премиясе лауреаты (2007), «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире **Ләбиб Лерон**га (Лемон Лерон улы Лероновка) 60 яшь (1961);

17 ноябрь – язучы, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе **Рауль Мирсәет улы Мирхәйдәров**ка 80 яшь (1941);

22 ноябрь – балетмейстер, Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбленең баш балетмейстеры (1977), ТАССРның халык артисткасы (1987), РФнең атказанган артисткасы (2017) **Раилә Мөхәммәтхан кызы Гарипова**га 75 яшь (1946);

23 ноябрь – рәссам, ТР Рәссамнар берлеге әгъзасы (1998) **Рәүф Талип улы Минияров**ка 80 яшь (1941);

25 ноябрь – график, каллиграф, Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе **Рушан Галәветдин улы Шәмсетдинов**ка 75 яшь (1946).

Олуг затларыбызның барысын да юбилейлары белән ихластан котлыйбыз һәм аларга саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз! ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Ислам дөньясы

Габдерәшит Ибраһимов



Пекин. XX гасыр башы

Пекинда өченче буын Сарайга караган бер мәчет бар. Бу мәчет кайчандыр Кытай ханы тарафыннан төзетелгән. Бүгенге көндә инде бик иске булса да, бинаның җисмән торуы һәм нигезенең ныклыгы аның кайчандыр хөкемдар акчасына төзелгән булуын бик ачык күрсәтеп тора. Бу мәчет Сарайга кушып диярлек салынган. Аның Кытай ханы сараена караган ягында гаять биек бер манарасы бар. Манараның урам ягындагы йөзендә, алты аршын биеклектәге зур һәм дүртпочмаклы мәрмәр ташка Аятел-Көрси чокып язылган, ә астарак манараның кайчан төзелгәне теркәлгән. Бу мәчетнең вакыфы хәзерге вакытта да Сарай тарафыннан идарә ителә, кайбер нәрсәләр дә бирәләр икән. Кайчандыр вакыфлары бик күп булган, диләр.

Кайчандыр Кытай ханы мөселман булган икән, дип тә сөйлиләр. Мәчет тә шул вакытта салынган, ди. Ул заманнарда вакыф мәчет белән идарә итү хокукының төркиләрдә булуын шарт итеп куйганга, мәчетнең мөтәвәлли һәм имамнары ул вакытларга кадәр төрки кешеләре булган. Мәчетнең имамы һәм мөтәвәллие белән

Дәвамы. Башы журналның 1 нче (2017) санында.

мин дә күрештем. Чынлап та шулай, кытайлашкан булсалар да, төркичә яхшы беләләр иде. Бер өйдә кунакта да булдым: ханымы төркичә тагын да яхшырак сөйләшә иде. Бу кешеләрнең төрки халыктан булулары һич шик тудырмый. Ничек кенә булса да, әлеге мәчет кайчандыр Кытайда мөселманнарның дәрәҗәле урыннар тотуларына дәлил булып тора. Бирегә зур акча кертелгән, башка мәчет белән чагыштырып та булмый. Мондый дәлилләрне күргән саен, йөрәгем телгәләнә, иляһи йа Рабби, безнең мөселманнар нинди дәрәҗәләргә ирешкән булганнар һәм нинди хәлгә төшкәннәр. Болар эзләнсә, өйрәнелсә, әллә ничә том китап язылыр иде.

Минем башыма шундый уй килә: Кытайдагы исламият турында да, менә мондый дәлилләр турында да берни белмибез, болар тарихыбызда да билгеле түгел. Ислам тарихында Кытай мөселманнары хакында бернинди мәгълүмат юк. Без, мөселманнар, гомумән, шундый хәлгә төшкәнбез ки, үткәнебез дә, бүгенге хәлебез дә, киләчәгебез дә – берсе дә билгеле түгел. Безне җаһиллек харап иткән.

Пекинда болардан башка тагын утыз мәчет бар, ләкин аларның күбесе бик кечкенә, кайберләре исә бик иске, җимерек хәлдә. Шул рәвешле бу җирләрдә безнең әллә никадәр мөселман кардәшләребез, төрки кардәшләребез бар, тик ни чара, без үзебез турында үзебез дә берни белмибез булып чыга. Мәүләбез хәлебезне төзәтергә насыйп әйләсен.

Пекин мөселманнарын мәҗүсиләрдән аерып алу мөмкин түгел, үзләре дә аера алмыйлар. Ләкин бөтен җирдә, мөселман өйләренең ишегенә гарәп язуы белән кәлимә-и тәүхид, кайберләренә исә: *«Йа мүфәттиха-л-әбваб!»* [«Әй, ишекләрне ачучы!»] – дип язылган була.

Кибетләрдә исә комган һәм тәсбих рәсеме ясалган була. Мөселманнар мәҗүсиләргә карата бик нык дошманлык хис итәләр. Мөселман кешесе мәҗүсиләр белән бервакытта да дуслык мөнәсәбәте кормый. *Чынлыкта: «Мөшрикләр нәҗестер»* (Тәүбә: 28), ягъни күп аллага табынучылар ару түгел, пычрак дигән дәрәҗәле һәм катгый аятькә таянып эш итәләр. Мәҗүси өендә мөселман кешесе хәтта чәй дә эчми, мәҗүси кулыннан йомырка алып ашамый. Шулай булса да, мөселманнар һәрвакыт ышанычлы һәм тынычлык саклаучы булып торалар икән. Ә үзләре мәҗүсиләрнең барлык гадәтләрен кабул иткәннәр: чәч үстерәләр, тырнаклары да нәкъ мәҗүсиләрнеке кебек. Хатыннары да, мәҗүси хатыннар кебек, аякларын кечерәйтәләр[1]. Хатыннарда хиҗап юк, башлары ачык.

Пекин мөселманнары турында хәзергә менә бу кадәр мәгълүмат белән чикләнәчәкмен. Боларны гел илдәге тынычлыкны саклау өчен сайлап алалар икән.

Кытай хөкүмәтенең пайтәхете һәм хакимият үзәге булган бу шәһәр, бик борынгы кала булганга, монда заманча яңа берни дә юк диярлек. Биредә хәйран калып карарлык бер нәрсә бар, ул да булса – шәһәрне әйләндереп алган дивар.

Әлеге дивар шәһәрнең иң төп бизәге һәм матурлыгы булып тора. Дүрт ягы да тигез булганга, ул квадрат рәвешендә һәм бер ягының озынлыгы 5 километрдан аз гына артык икән. Дүрт ягын бергә санасаң, якынча 21,5 километр булыр дип исәпләдем. Дивар өстенең киңлеге – 21 адым, биеклеге исә 30 метрлап бар. Шәһәрнең зур өлешен тулысынча әйләндереп алган бу дивар моннан 500 ел элек кытайларның үзләре тарафыннан төзелгән. Һәр капка янында дивар өстенә күтәрелә торган юллар бар. Кирәк булса, ат яки башка хайван белән дә менәргә

[1] Кытайда X гасырдан алып XX гасырның башларына кадәр дәвам иткән әлеге йола буенча, аяклары кечкенә һәм нәфис булсын өчен, кыз балаларның (бигрәк тә югары катлауга караган гаиләләрдә) аяк бармакларын бәйләп, кыскан аяк киеме кидерә торган булганнар *(тәрҗ.иск.)*.

мөмкин. Капкаларның барысының да өстендә һәм диварның дүрт почмагында бик зур өчәр-бишәр катлы гаскәр казармалары бар. Бу биналар диварга аерым бер күркәмлек өсти.

Пекин шәһәрен карар өчен урамнарда йөрергә дә кирәкми. Бу диварның өстендәге бер җирдән китеп, тагын шул җиргә әйләнеп кайтсаң, шәһәр эчендәге бөтен урамнарны, бөтен тыкрыкларны күргән булып чыгасың. Ник дигәндә, дивар шәһәрдәге иң биек дигән йортлардан да биегрәк.

Әлеге диварның эчендәге шәһәргә Иске Пекин диләр.

Диварның көнчыгыш тарафына кушып төзелгән тагын бер дивар бар. Анысы моннан 200 ел элек төзелгән. Шулай да бу дивар беренчесе белән чагыштырганда тәбәнәгрәк һәм бик артык нык та түгел. Әлеге яңарак булган диварның кайбер җирләре җимерек, кирпечләре дә нечкәрәк һәм бик гади кирпеч. Искерәк диварның кирпечләре шаккатырлык, һәрберсе 20 бармак озынлыгында, калынлыгы – 10 бармак, киңлеге 8 бармак кадәр. Ул вакыт үткән саен ныгый гына бара икән. Белем ияләре бу диварның ташларына бик югары бәя бирәләр, ди.

Игътибар итик: әлеге ныгытманы моннан 500 ел элек төзегән халык – Аурупалылар тарафыннан вәхши һәм варвар дип атап йөртелгән көнчыгыш халкы. «Бүгенге көндә миллиардлар сарыф ителсә дә, моның кебек бер нәрсәне булдыру мөмкин түгел», – дип әйтсәк тә урынлы булыр.

Мәдәни алманнар[2] чәлдергән обсерватория

Диварның төньяк тарафының нәкъ уртасында гаять зур һәм төзек расатханә, ягъни обсерватория булган. Ул моннан 500 ел элек, дивар белән бер үк вакытта төзелгән. Бу расатханә эчендә төрле-төрле күзәтү җиһазлары, зур сәгатьләр, урын табып билгеләү җайланмалары торган, барысы да җиз һәм бакырдан коелган булган. Фәнни кыйммәтен санамаганда да, бары тик бакыры гына да миллионнар белән бәяләнерлек булган. Андагы җиһазларның фәнни кыйммәтен, әлбәттә, мин бәяли алмыйм. Биредә сөйләгәннәрем һәммәсе әлеге расатханәнең мөдиреннән алынган мәгълүматтан гыйбарәт. Монда Аурупа талавыннан элегрәк, тагын шулай ук бакырдан һәм җиздән (бронзадан) коелган бер шар булган. Бу шарның диаметры – 2,5 метр һәм ул тулысынча бакырдан коелган. Авырлыгы турында сорагач, мөдир кытайлар исәбе белән бик авыр булганын әйтте, ләкин мин бик аңлый алмадым. Әлбәттә, диаметры 2,5 метр булган шарның эче тулы булган хәлдә, авырлыгын якынча булса да аңларга була. Минем исем киткән нәрсә – шундый зур һәм авыр шарның әле әйләнеп тә торган булуы.

Менә шул шарны 1900 елда бөтен мәдәни Аурупа милләтләре бергәләшеп Кытай сараен талаганда расатханәдән чәлдерү араларында иң мәдәни булган алманнар өлешенә тигән икән. Алман гаскәриләре ул зур шарны һәм тагын берничә җиһазны аннан чәлдергәннәр. XX гасырның фән-белем хезмәтчеләре, шул рәвешле бүгенге мәдәнилеккә тагын бер «ялтыравык» өстәгәннәр. Шәһәргә килгәч, алманнар иң башлап нәкъ менә бу җиргә ядрә яудырганнар. Биредәге фәнни җиһазларның калдыкларындагы ядрә эзләре әле дә шул килеш тора.

Аңлашылганча, шәһәрне саклау булмаган, аурупалы гаскәрләр, кәефләренә күрә ядрә аттырып, Пекинга керүгә, котырган хайван кебек як-якка ташланганнар, сарайга һәм өйләргә басып кергәннәр, күзләренә ни күренсә, барысын да

[2] Алманнар – немецлар *(тәрҗ.иск.)*.

Пекин. XX гасыр башы

җыйганнар, бөтен шәһәрне талаганнар. Вакыйганың шаккаттыргыч ягы шул: болар барысы да, әлеге дә баягы, шул бичара XX гасырга ябыштырыла, мәдәнилек дип аталып, халыкларның аңын томалый.

Кытай сараенда никадәр нәфис сәнгать әсәре, борынгыдан сакланып калган әйберләр, борынгы китаплар булса, баскынчылар барысын да алганнар, Аурупага ташыганнар. Болар Пекинны, урамнан-урамга, йорттан-йортка йөреп, нәкъ өч көн буе талаганнар. Бары тик мөселман мәхәлләләре генә беркадәр тынычлыкта калган, бу да бары тик инглиз һәм рус гаскәрләрендә мөселманнар да очрау аркасында гына булган. Мөселман гаскәриләр аларны яклап, саклап калган. Гомумән, ул вакыйгада мөселманнардан берәү дә шәһәрне ташлап китмәгән, үзләре дә тынычлыкны, тәртипне саклап калырга тырышканнар. Мөселман гаскәриләр бары тик боларга гына ярдәм иткәннәр. Мәҗүсиләрнең барысы да, әле дошман гаскәре басып кергәнче үк, шәһәрне ташлап качкан. Шул сәбәпле, сарай да бөтенләй бушап калган булган. Кытай ханы Богдихан да, гаиләсе белән, башкаларга ияреп качып киткән.

Бичара Богдихан үзенең җанын һәм гаиләсен мөселманнар арасында, Пекиннан ерак түгел бер мәчеттә яшеренеп саклап калган. Җанын саклап калганнан соң, бу мәчеткә һәм мәхәллә халкына үз кулы белән хәтта рәхмәт хаты да язып биргән, ул әле дә мәчеттә ядкяр итеп саклана.

[Петербургта яшәгәндә мин рус офицеры, полковник Верещагинның өендә Кытайдан китерелгән гүзәл сәнгать әсәрләре күргән идем, ул аларны сатарга җыена иде. Мин хәтта сатып алучы да тапкан идем. Сатулашу да булды. Барлыгы 600ләп әйбер бар иде. Верещагин боларның исемлеген төзегән, барысына бергә 500 мең сум акча сорый иде. Сатып алырга теләгән кеше биш көн буе бу әйберләрне карады, тикшерде һәм, нәтиҗәдә, аларны 200 мең сумга бәяләде. Тик Верещагин

ул бәягә сатарга теләмәде. Бәясен азсынды, кыйбаткарак сатарга өметләнә иде, ахрысы. Чагыштырып уйлап карагыз: бары тик бер рус офицеры гына да шулкадәр әйбер чәлдергән, ә генераллар, баш кешеләр күпме әйбер чәлдергәннәрдер!]

Сүз башына кире кайтыйк. Алдарак телгә алынган расатханә әле дә үз урынында тора. Анда шулай ук бакырдан ясалган кояш сәгате һәм җир табып билгеләү җиһазы бар. Боларны да чәлдерәсе булганнар, ләкин урыннарыннан кубарып ала алмаганнар. Шуңа күрә әле дә үз урыннарында торалар. Кояш сәгатенең диаметры – 7 аршын. Кытайларның риваятьләренә күрә, бу нәрсәләр гарәпләрдән калган. Кояш сәгатенең һәм әлеге җиһазның өстендәге гарәп саннары моны раслый да кебек. Тик башкарылыш ысулының XIV гасырга тартым булуы гына бераз шөбһә тудыра. Шул ук вакытта болар икәү диварның өстенә түгел, җиргә утыртылган, бары тик диварга кушылып ук тора. Шулай булгач, диварның төзелүеннән дә алдарак чорга каравы мөмкин. Болардан кала тагын берничә борынгы җиһаз да бар, ләкин аларның нәрсә икәнлеген бик төгәл әйтеп булмый икән. Өсләрендә бары тик кытай язулары гына бар. Мөдирнең әйтүе буенча, болар һәммәсе йолдызлар белән бәйле нәрсәләр икән.

Минем игътибарымны бик нык җәлеп иткән нәрсә һаман да шул алманнар чәлдергән шар иде. Ул кадәр авыр нәрсәләр моннан 500 ел элек ничек андый биеклеккә менгезелгән һәм ничек очлы тимер өстенә утыртыла алган? Бүген тагын да шул ук вәхши кытайлар анда шул ук каешларга, шулай ук бакырдан шар коеп куйганнар. Тик монысының эче буш, шулай булса да 124 кило авырлыгында. Тагын шул ук очлы тимергә утыртылган, ләкин бик авырлык белән әйләнә. Мөдирнең әйтүенә күрә, моннан элеккесе, эче тулы булса да, гади шарлар кебек аз гына кул тидерүгә әйләнә башлый торган булган. Моннан тыш, бу шарда кайбер йолдызлар да күрсәтелмәгән, ди. Алманнар аннан ул гаҗәеп шардан башка да кайбер җиһазларны алып киткәннәр. Төгәл генә белә алмадым, чөнки мөдир атамаларын кытайча әйтә, ә тәрҗемәче миңа аларны тәрҗемә итә алмады.

Расатханә мөдире булып торган кеше 93 яшендә иде. Нәселләре белән шул расатханә мөдирлеге хезмәтен башкарганнар. Ата-бабалары 14 нче буынга кадәр әлеге өлкәнең белгечләре булганнар.

Шулай итеп, бу дивар хакында мин менә шулкадәр мәгълүмат бирә алам. Ә, тагын бер нәрсә исемә төште: янәсе әлеге диварның кирпечләрен, ташларын саклау өчен, тагын да шул ук Германия һәм Англия илчелекләре тарафыннан сакчылар куелган, диварның өстендә ары-бире йөренеп торалар. (Ба'дә һараби'л-Басра. Басра харап булганнан соң...) Кыйммәтле нәрсәләрне чәлдергәннәр, үзләре карак. Инде килеп, дивар ташлары урланмасын дип, сакчылар куйганнар, имеш. Никадәр күз буяучы милләт! Бөтен мәмләкәтне талаганнар, нәрсә бар чәлдергәннәр, ул җәннәт кебек сарайларны утка якканнар, инде бу диварларның кирпечләрен хунхузлардан саклаячаклар, ди, имеш. Сәбәбе шул: болар фәнни һәм сәнгати яктан гаять кыйммәтле, бер данәсе фәлән-фәлән доллар тора, ди, имеш. Боларны читтән тыңлап торучы бичара, самими шәрыклылар тагын да шул беркатлылыклары белән моңа ышаналар. Ни дә булса, фән-белемгә бәйләп сөйләнсә, билгеле, кешеләр хөрмәт белән карыйлар. Югыйсә төп караклар – моны сөйләгән кешеләр үзләре. Мәмләкәтне кат-кат тунадылар, ул да аз күренде, соңыннан сугыш чыгымнарын түләтү исеме белән миллионнар белән исәпләнгән бурычка батырдылар.

Йә, бу нинди ваемсыз милләт, килгәннәр, мәмләкәтне талаганнар, аннары сугыш чыгымнарын түләтәләр. Мәмләкәтне шыр-ялангач калдырганчы талаганнан соң, «ташлары урланмасын» дип, сакчы гаскәриләр куялар.

(Шаркылдап көләрлек хәлләр бу.) Без боларны әле һаман да мәдәнигә саныйбыз.

Пекин

Бик борынгы кала булганга, Пекинның төзек, җыйнак урамнары бик аз. Шулай да дивар эчендә калган өлешендә илчелекләргә караган бер төзек урам бар. Биредә бөтен чит илләрнең илчелекләре үзләренә бер ныгытма төзеткәннәр. Бигрәк тә инглиз, рус, алман илчелекләре урнашкан җирләрне аерым бер мәмләкәт дип әйтерлек. Рус илчелеге бик зур булса да, кешеләре алай күп түгел. Болар утыз-кырык гаскәрине эченә алган хәрби бүлек, илчелек төркеме, консуллыгы, почтаханәсе белән барысы бергә 120ләп кешедән торган рус оешмасы булып торалар.

Әмма инглиз илчелеге бик күп санлы һинд гаскәре тота. Аларның кайберләрен полиция хезмәтендә файдалана. Болар берничә мең кеше бардыр дип уйлыйм. Японнарга килсәк, әйтелде инде, һәр эштә идарә аларның кулында. Башка илчелекләр дә бу урамда урнашкан. Биек-биек биналар бергә җыелышып тора. Әлеге урам Аурупа шәһәрен хәтерләтә.

Билгеле булганча, һәр илчелекнең үзенең хезмәт төркеме генә түгел, миссионер төркемнәре дә була. Бу корткычлар Пекинны да үрмәкүч кебек пәрәвезгә сарганнар, бик яхшылап урнашканнар.

Кытай императорының сарае да аерым дивар белән әйләндереп алынган, ул да үзе аерым бер мәмләкәт кебек тора.

Болардан башка тагын берничә төзек урам бар. Төзек дип, тигез, киң урамнарны күз алдында тотып әйтәм. Боларда матур күтәртмә юллар, биек биналар, кибетләр кебек нәрсәләр һич юк. Бары тик бик матур, төзек капкалар гына бар. Бу капкалар бөтен шәһәрнең бердәнбер бизәге булып тора.

Шәһәрнең кеше утырып йөри торган, кеше ташый торган чаралары 192 нче[3] биттә әйтелеп киткән (кеше тарафыннан тартып йөртелә торган ике тәгәрмәчле) арбалардан гыйбарәт. Авыр йөк ташу өчен хайван җигелә торган арбалар да кулланыла.

Болардан тыш, тагын үтәли чыкмас урамнар, ике кеше янәшә сыймаслык тыкрыклар, үтеп булмаслык баткак җирләр дә бар. Көне буе яңгыр яуса, урамнар үтеп йөри алмаслык була. Пекиндагы арулыкның дәрәҗәсен аңлатыр өчен мин менә болай дияр идем: безнең Истанбулның иң пычрак урамы Пекинның иң ару урамнарыннан да арурак. Бары тик илчелекләр урнашкан урам гына чыгарылма тәшкил итә. Аны исәпкә алмаганда, бу чагыштыру йөзгә-йөз дөрес.

***

Бөтен Пекин белән бөтен Истанбулны чагыштырсак, арулык ягыннан Берлин белән Истанбул арасында никадәр аерма булса (күргәннәр булса), Истанбул белән Пекин арасында да шулкадәр аерма бар.

Пекин турында башка нәрсә сөйләүнең кирәге дә юктыр дип уйлыйм.

Төрекчәдән ***Асия Рәхимова*** *тәрҗемәсе* ■

[3] Бу – әсәрнең госманлы-төрек телендә басылган басмасындагы бит саны *(тәрҗ.иск.)*.

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

САБЫЙЛАР ӨЧЕН ДИНИ МИРАС

Дин дәресләре

Сөнгатулла Бикбулат

Бишенче дәрес
Дөнья яралтылу, фәрештәләр. Иблис вә шайтаннар. Истигазә-сыгыну

Мөгаллим: Сез барыгыз да белдегез инде: элек бернәрсә дә булмаган: күк тә, җир дә, адәмнәр дә, хайваннар да. Бары кем генә булган?

Шәкертләр: Аллаһы Тәгалә генә булган.

Мөгаллим: Шулай шул. Элек Аллаһы Тәгалә генә булган. Аллаһы Тәгалә дөньяны нәрсәдән яралткан әле?

Шәкерт: Юктан бар кылган.

Мөгаллим: Әйе, юктан бар кылган. «Яралткан» дигән сүз үзе – юктан бар кылган дигән сүз. Аллаһы Тәгалә бөтен дөньяны юктан бар кылган. Безгә күренгән нәрсәләрне дә, күренмәгән нәрсәләрне дә Ул яралткан. Беләсезме, безгә күренмәгән нинди зат бар?

Шәкерт: Аллаһы Тәгалә бар.

Мөгаллим: Безнең бөтен җир йөзе күренә торган дөньядан санала. Ә аңардан башка без күрми торган нәрсәләр дә бар. Әнә, күктә без кояшны, айны һәм йолдызларны күрәбез. Анда без күрмәгән әллә нәрсәләр бардыр әле. Әнә шул безгә күренгән вә күренмәгән бөтен Галәмне Аллаһы Тәгалә яралткан. Аллаһы Тәгалә боларны нәрсәдән яралткан әле?

Шәкерт: Юктан бар иткән.

Мөгаллим: Аллаһы Тәгалә иң башлап фәрештә дигән мәхлукны яралткан. Ул вакыт әле безгә күренгән дөнья да, без дә, хайваннар да – берсе дә яралтылмаган булган. Ул фәрештәләр безгә күренмиләр, чөнки алар безнең кебек гәүдәле түгелләр. Алар кайвакыт икенче сурәткә дә керә алалар. Аллаһы Тәгалә фәрештәләрне шулай итеп яралткан. Алар элек заманнарда изге кешеләргә кеше сурәтендә күренгәннәр. Фәрештәләр һәрвакыт Аллаһы Тәгаләнең хезмәтендә торалар. Аңа коллык (гыйбадәт) кылалар. Фәрештәләр арасында Җәбраил исемле бик олуг бер фәрештә бар. Аның соңында һәр кешене андый-мондый начарлыкка, һәлакәткә төшүдән саклый торган һәм эшләгән эшләрен, кылган яхшылык-яманлыкларын язып тора торган фәрештәләр дә бар. Боларга «сакчы» вә «язучы» фәрештәләр диләр. Аннан соң җан алучы фәрештә дә бар. Фәрештәләр һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәт кылалар, дигән идек. Алар һәрвакыт Аллаһы Тәгаләгә буйсынганнар. Тик фәрештәләрнең берсе, бик тәкәбберлек кылып, Аллаһы Тәгаләнең бер әмерен тыңламаган. Шунлыктан Аллаһы Тәгалә аны хозу-

Дәвамы. Башы журналның 7 нче (2021) санында.

рыннан сөргән. Менә сез әгәр ата-аналарыгызның сүзләрен тыңламасагыз, алар сезне тиргиләр, кайвакыт куып та чыгаралар бит. Шулай түгелме?

Шәкерт: Шулай, мөгаллим әфәнде.

Мөгаллим: Ә менә Иблис Аллаһының әмерен тыңламаган, аңа карышкан һәм шуңа күрә сөрелгән. Иблиснең аның бик күп иярченнәре дә бар. Аларга «шайтан» диләр. Ә бөтен шайтаннарның башлыгы Иблис. Иблис вә бөтен шайтаннарның эшләре кешеләрне начарлыкка котырту, аздыру гына. Шулай булгач, алар яхшы мәхлуклар булалармы, яманмы?

Шәкертләр: Әлбәттә, начар, әлбәттә, яман.

Мөгаллим: Шулай шул. Алар бик яман затлар. Иблис һәм шайтаннар гел адәм балаларын котырталар, безне гел яман юлга кертергә тырышалар. Алар безгә күренмәсәләр дә, һәрвакыт безне начарлыкка өндәп кенә торалар: хәлфәгә карышырга, ата-аналарның сүзләрен тыңламаска, сабак укымаска кушалар. Шулай түгелме?

> «Ул фәрештәләр безгә күренмиләр, чөнки алар безнең кебек гәүдәле түгелләр. Алар кайвакыт икенче сурәткә дә керә алалар.

Шәкерт: Шулай.

Мөгаллим: Әнә шундый эшләрнең барысына да безгә күренмәгән шайтаннар өнди. Шулай булгач, безгә алардан качарга, аларның явызлыкларыннан сакланырга кирәк. Иблис һәм шайтаннарның явызлыкларыннан котылуны Аллаһыдан сорарга кирәк. «Йа, Раббым, шайтанның явызлыгыннан Синә аркаланабыз, Синә сыенабыз», – дияргә кирәк. Дөресме, балалар?

Шәкертләр: Дөрес, хәлфә, дөрес.

Мөгаллим: Әлбәттә, дөрес. Менә син берәр нәрсәдән курыксаң, хәзер әнкәңнең кочагына атыласың бит. «Әнкәй, әнә, миңа тия», – дип, хәзер аңа йөгерәсең. Шулай ук без, Аллаһы бәндәләре дә, шайтанның явызлыгыннан Аллаһыга сыенырга тиеш. Тик безгә аны да гарәпчә итеп әйтергә кирәк. Беләсезме ничек?

Шәкертләр: Ничек?

Мөгаллим: Менә, белмәсәгез, өйрәтәм: «Әгүүзү-билләәһи-минәш-шәйтаанир-ражииием». Йә, Габдуллаһ, белдеңме инде?

Шәкерт: Мин моны элек тә белә идем, әнкәй өйрәткән иде.

Мөгаллим: Син аны белә идең, фәкать нәрсә икәнлеген, мәгънәсен генә белмәгәнсез. Менә аның мәгънәсе ничек: «Рәхәттән сөрелгән шайтанның явызлыгыннан Аллаһы Тәгаләгә сыенам». Менә бу сүзне һәрвакыт әйтергә, ятканда да, берәр эшкә керешкәндә дә – гел кабатларга кирәк. Бигрәк тә Коръән укырга керешкәндә әйтү тиеш. Син Коръән укый беләсеңме әле?

Шәкерт: Белмим.

Мөгаллим: Йәле, шайтаннан ничек сыенырга кирәк?

Шәкерт: Әгүүзү-билләәһи-минәш-шәйтаанир-ражииием…

Мөгаллим: Афәрин, шулай кирәк. Йәле, барыбыз бердән әйтик: «Әгүүзү-билләәһи-минәш-шәйтаанир-ражииием».

*Текстны басмага **Мәдинә Әбделганиева** әзерләде.* ■

МӨҺАҖИРЛЕКТӘГЕ ТАТАР КИТАБЫ

Бөек шагыйребез Котб әсәренең Истанбул басмасы (1968)[1]

Хатыйп Миңнегулов, филология фәннәре докторы

«Хөсрәү вә Ширин» кульязмасының (1383) тәүге бите

Ахыры. Башы журналның 10 нчы (2021) санында.

Төрек кардәшебез М.Нәҗмеддин әзерләгән басманың яртысыннан күбесен (ягъни 179-460 битләрне) Котб әсәренең тексты («Metin») алып тора. Латин хәрефләре белән, нигездә, гамәлдәге төрек язуында бирелгән «бәйтикеюллыкларның саннары – тәртибе эзлекле рәвештә куеп барылган, Бәркә Фәкыйһ юллары белән бергә аларның саны 4730 дип билгеләнгән. Кайбер битләрдә астөшермә рәвешендә аерым юлларга карата «мисрагъның вәзене бозыктыр» дигән искәрмәләр дә күзгә ташлана.

Мәгълүм ки, кулъязмаларны, аеруча башка язудагы текстларны уку, аңлату, бигрәк тә икенче графикада бирү, ягъни транслитерацияләү, гомумән, җиңел эш түгел. Бу процесс еш кына билгеле бер әзерлекне, күнекмәләр булуны сорый. Ул аеруча элеккеге чорларга кагылышлы кулъязмалар белән эш иткәндә зарури. Фәндә, рухи тормыш тарихында язма чыганаклардагы сүзгыйбарәләрне, кайвакыт хәтта аерым юлларны төрлечә уку, аңлату очраклары, шуларга нисбәтле туган бәхәс-аңлашылмаучылыклар да еш очрый. Кол Гали, Мөхәммәдьяр, Габдерәхим Утыз-Имәни, хәтта Г.Тукай, Г.Исхакый текстлары белән эш иткәндә дә аерым бәхәсләр, төрлелекләр тууы күпләребезгә мәгълүм.

Әйткәнебезчә, Котб әсәре автограф түгел, ул 1383 елда Бәркә Фәкыйһ күчергән бердәнбер нөсхәдә безгә килеп җиткән. Шуңа күрә аны башка текстлар белән чагыштыру мөмкинчелеге юк. Бу Париж нөсхәсе белән эш итүне тагын да җитдиләндерә, катлауландыра. Алдарак язганыбызча, Котб әсәрен текстологик яктан җентекле өйрәнеп, аны гавамга җиткерүче – А.Зайончковский.

Сер түгел, соңгы ярты гасырдагы тикшеренүләр, Котб әсәреннән публикацияләр, нигездә, Варшава басмасына таянып алып барылды. Париж нөсхәсе белән берлектә А.Зайончковский транслитерациясен дә еш файдаландык. Казан басмалары, шул исәптән 1969 елгы һәм аннан соңгы публикацияләр – моның ачык мисаллары. Без дә шәхсән Варшава басмалары белән эш иттек. Төрек галиме дә үз элгәргесенең хезмәтләренә таяна, әмма кайбер урыннарда тәнкыйди рухта. Аерым сүз-гыйбарәләрнең укылышында, латин язуында бирелешендә үзенчә эш итә. Бу хакта, ягъни «фәрекъаермалар» турында кереш мәкаләдә үзе дә искәртә һәм аерым, конкрет мисаллар да китерә. Истанбул, Варшава һәм Казан басмалары арасындагы әлеге төр фәрекъ-төрлелекләрне ачыклау, Котб әсәрен тагын да тулырак, тирәнрәк аңларга һәм аңлатырга ярдәм итәр иде. Әмма бу җентекле, махсус, аерым тикшерүне сорый. Шуңа күрә без ул мәсьәләгә биредә тукталмыйбыз. Бары шунысын гына искәртеп үтәсем килә: гомуми планда караганда да, текстлар бирелешендә, укылышында кайбер төрлелекләр күзгә ташлана.

***

Алтын Урда чорында, җирлегендә яшәп иҗат иткән бөек шагыйребез Котбның «Хөсрәү вә Ширин» әсәре – үзенең идея-эстетик байлыгы, сәнгати камиллеге белән элеккеге рухи мирасыбыздагы иң кыйммәтле ядкярләрнең берсе. Аны тагын да тирәнрәк һәм тулырак аңлау, кабул итү – саваплы һәм файдалы гамәл. Шуңа күрә Котб әсәренең 1968 елгы Истанбул басмасын өйрәнү, андагы факт-мәгълүматларны, фикер-күзәтүләрне тәнкыйди файдалану һәм әлеге китапны гыйльми-мәдәни әйләнешкә кертү, безнең уебызча, һич тә зыян итмәс, файдага гына булыр иде. ■

Соклангыч шәхес иде

Эльмира Шәрифуллина

Туй. Фаил, мин, әни (каенана), Идрис Туктар һәм Вил Шәрәфетдинов. 1968 ел

Кайчагында, кемнедер сагынып искә алганда: «Андый кешеләр юк инде ул хәзер», – дип куябыз. Бу, гадәттә, аның кешелек сыйфатларын, чиста күңелле, иманлы булуын искә төшергәндә шулай әйтелә. Әле менә язучы Идрис Туктарның 125 еллыгы уңаеннан истәлек язуымны сорагач, иң беренче булып телемә шушы гыйбарә килде: «Андый кешеләр юк инде ул», – дип кистереп әйтү ярамаса да, миһербанлы, риясыз, дөрес гамәлләр генә кылып яшәгән кешеләр сагындыра шул. Идрис Туктар минем хәтеремдә олы җанлы, әмма кече күңелле, кешеләрне, бигрәк тә балаларны ихлас ярата белгән, шаян-шук сүзле, гомере буе китап дөньясы белән яшәгән, көр һәм хөр тавышлы, чын баһадир ир-ат булып истә калды.

Гомер юлымда 1967 елда очрады ул миңа. Алар, минем булачак ирем Фаил Шәфигуллин белән, үзләре яшәгән Яшел Үзән шәһәреннән Язучылар берлегенә килгәннәр дә, минем китап кибетендә эшләвемне белеп (ул вакытта кибетнең эчке бер бүлмәсендә китапларны почта белән җибәрү бүлегендә хезмәт куя идем), сирәк кайта торган китапларның зур исемлеген төзеп, яныма кергәннәр иде. Фаил белән ешрак очраша башлавыбызның да, ныклап йөреп китүебезнең дә төп сәбәпчесе шушы исемлек булды. Алга таба, мин Фаилгә кияүгә чыгып, Яшел Үзән шәһәренә күчкәч, без Идрис абый белән еш булмаса

да аралашып, ярдәмләшеп яшәдек. Минем кызым белән аларда, аның бездә куна калганы да, иркенләп гапләшеп, чәйләп утырганнарыбыз да булды. Ул, холкы белән шаян сүзле, җор телле булса да, җитди мәсьәләләрдә төптән уйлап, акыллы киңәш тә бирә, кайгың булса, аңа үз язмышындагы авырлык кебек итеп кушыла да белә иде. Ләкин үз тормышындагы, үткән юлындагы кыенлыклар, күргәннәре-кичергәннәре турында зарланып та, мактанып та сөйләп утырганын хәтерләмим. Ә бит Идрис абыйның башыннан үткәннәре ай-һайһай!.. Бәлки, кызыксынып сорау бирмәгәнгә сөйләмәгәндер. Ә бәлки, хатын-кыз алдында сугыш мәхшәрләрен, фәкыйрьлек газапларын искә алуны урынлы түгел дип санагандыр, чөнки ул хатын-кызга үтә дә сак, итагатьле мөнәсәбәттә иде. Идрис абыйның катлаулы тәрҗемәи хәлен мин, Казанга күченеп килгәч, кайсын укып, кайсын Фаилдән ишетеп белдем. Әйтик, ун яшендә әтисе белән бергә алтын юу приискасында эшли башлау. Безгә, мәсәлән, язучыларның шахтерлар тормышыннан алып язылган әсәрләрен укып, кечкенәдән тәэсирләнеп, бу эшнең ни дәрәҗәдә газаплы хезмәт булуын аңлап үскән буынга, Идрис абыйның бала чагына туры килгән бу гаять тә авыр өлешне күз алдына китерү кыен түгел. Ә менә бүгенге ун яшьлек баланың, билдән суга батып, өлкәннәр белән бергә мондый вазыйфага алынуын фаразлап булмый да булмый. (Иң беренче чиратта, ата-ана үзе баласының «кавырсыны катмаган килеш» бил бөгә башлавына каршы булачак.) Шуның өстенә, эш белән бергә (параллель рәвештә) башлангыч белем алу. Димәк, кечкенәдән белемгә омтылу да, тырышлык та – гаиләнең акыллы тәрбиясе дип нәтиҗә ясарга кирәктер биредә. Бу сыйфат исә, ягъни «Гыйлемгә омтылуда гомернең бер генә минутын да заяга уздырмаска!» – дигән девиз Идрис Туктарның бөтен тормыш юлында кызыл җеп булып сузылгандыр дип уйлыйм. Утыз алты яшендә Казан дәүләт педагогика институтына укырга кереп, аны кырык яшендә тәмамлап, укыту эшенә керешә, газета-журналларда эшли һәм иҗат эшенә чума ул.

Искиткеч бай биографияле, өч сугышны – Беренче бөтендөнья сугышы, Гражданнар һәм Бөек Ватан сугышларын узган, хәтта 1919 елда Колчакка каршы агитация алып баруда гаепләнеп, бер ел чамасы Владивосток төрмәсендә утырып чыккан язучының укучыга әйтер сүзе күп һәм мәгънәле иде. Идрис Туктар бигрәк тә балалар өчен классик хикәяләр калдырды. «Авыраяк», «Абыем бүреге», «Батырлыкта – матурлык» кебек җыйнак новеллалар дәреслекләргә кертелеп, берничә буын баланы тәрбияләде. «Икән-микән белән Бугай», «Бәхет белән Шатлык», «Асыл чыпчык» исемле әкиятләр, халык авыз иҗаты кебек тапкыр әйтелгән җор телле, фәлсәфи «җөмләләр»е укучысы күңелендә асылташлар кебек җемелдәгән нәни сөенечләр булып урын алды.

Безнең гаиләдә Идрис Туктарның автографлы берничә китабы саклана. Шуларның берсе – кызыбыз Раушаниягә язылган «Батырлыкта – матурлык» китабы. *«Кадерлебез Раушания! Сине сагындым да инде мин! Барчагызны да Бөек Октябрь бәйрәме белән котлыйм. Әткәй-әнкәйләреңне минем өчен дә үбеп-үбеп ал, яме! Идрис бабаң. 5 ноябрь, 1976 ел»*. Ул аны, Казанга килгәч, Кызыл Байрак урамындагы фатирыбызга килеп бүләк иткән иде.

«Эш-хезмәтеңә бирелү, шигырьләр уку, музыка тыңлау, матурлыкка гашыйк булу – боларның һәммәсе дә камилләшүнең иң сокландыргыч нурлы маяклары», – дип язды ул «җөмләләр»енең берсендә. Идрис Ильяс улы Туктаров үзе дә гомере буе камиллеккә омтылып, тирә-юнендәгеләргә үрнәк булып яшәгән соклангыч шәхес иде. ■

«Ихласым бик дан – милләт юлына»

Шәкүрә Юзеева

Илдар Юзеев әнисе Шәкүрә апа белән

Башкортстанга җәйге сәфәрләребезнең берсендә Ямады авылындагы Илдар Юзеев музеенда да булдык. Анда шагыйрьнең әнисе Шәкүрә апаның истәлекләре язылган бер дәфтәр кадерләп саклана икән. Бу язмаларны укыгач, һич икеләнмичә, Илдар һәм Нил Юзеевларга язучылык талантына әниләреннән күчкән, дип әйтергә була. Аларда бәләкәй чакларыннан ук туган тел һәм хезмәткә мәхәббәт тәрбияләгән Шәкүрә апа. Үзе авыр тормышта үсеп, кешеләргә, дөньяга, табигатькә ярату хисен саклап кала белгән, күп еллар урын өстендә ятып, Илгә-Ватанга һәм милләткә игелекле уллар тәрбияләргә көч тапкан ул.

Халкыбызга ике Габдулла Тукай исемендәге дәүләт премиясе лауреатларын – шагыйрь Илдар Юзеев һәм галим Нил Юзеевларны тудырган Ананың үзенә сүз бирик.

Редакциядән

Туган авылым

Минем туган авылым Башкортстан Республикасындагы Мишкә районының Иштыбай авылы булып, табигый яктан бик матур урынга урнашкан. Авылның читеннән зур булмаган Әнәк исемле елга үтә. Шул елганың күпереннән чыгып әзрәк баргач та, тау башлана. Тауның башында көтүлек-болыннан чикләвек урманы башланып, берничә километрга сузыла. Ул урманда чикләвек, кура җиләге, карагат, җир җиләге, каен җиләге, бөрлегән, балан, шомырт, миләш кебек җимешләр мул була.

Иштымбай – уртача зурлыктагы бер мәчетле авыл. Авыл халкы игенчелек, малчылык белән шөгыльләнә. Урта һәм ярлы тормыштагы крестьяннардан торып, зур байлар булмый. Авылда төрле нәрсәләр сатучы бер сәүдәгәр була.

Авыл культура ягыннан бик артта булып, ир балалар өчен генә башлангыч мәктәп эшли. Бер мәчет, бер мулла. Дәверендә Әкълимә апаларның кардәше Вәсфи

Гильмияров абый белемле кешеләрдән булып, пенсиягә чыкканчы Бөре педагогия институтында укыта.

Гражданнар сугышы чорында авылда хат язу өчен, җәйге каникул вакытында мине чакыралар иде.

Безнең авыл Бөре шәһәреннән 35 километр ераклыкта урнашып, тирә-ягында су юлы һәм башка тимер юл кебек уңайлыклар да юк.

Хатын-кызлар надан, укый-яза белүче булмый, иске гореф-гадәтләргә нык ышанып яшиләр.

Көз көне каз өмәләре башлана. Бу көн өй өчен бәйрәм төсе ала. Казларны тазартып бетергәч, матур атларга утырып, кызлар елгага китәләр, кайтуларына «каз табикмәге» пешереп кунак итәләр. Кич, каз ашы пешереп, кызларны, күршекүләннәрне кунакка чакыралар.

Кышкы озын төннәрдә кызлар, җиңгәчәләр кич утырып тула басарга – йон, киндер сугарга сүс җебе эрлиләр. Шуларны әзерләп бетергәч, тула басу башлана. Сәкенең такталарын алып, читән кебек үргән агач куялар да, йоннан суккан тукыманы кайнар суга манып, кызлар ике якка да утырып (дүртәр кыз), як-яктан куллары белән тотып, бер теге якка, бер бу якка өтеп басалар. Тышта хуҗалар ачулану куркынычы булмаган җирдә егетләр дә гармун белән кызлар чыкканчы көтеп торалар.

Яз көне, җир судан корыгач, сүстән эрләп суккан киндерне тукмаклыйлар. Аппак кәртәне ике башыннан элеп куялар да, шуның өстенә киндерне салып, ике тукмак белән ритмлы итеп, кәртәгә тукмак белән суккач моңлы тавыш ишетелеп торсын өчен, алмаш-тилмәш бәрәләр. Читтән тыңлаганда бик моңсу булып ишетелә. Шулар янына егетләр, кызлар җыела. Киндер күлмәк, ашъяулык, тастымаллар һәм башка кирәк-яракларны үзләре сугалар иде. Ул вакытта сатучылар, киҗе-мамык дигән төрле төстәге фабрик әзерләп чыгарган җепләрдән дә, матурлап, үзләре сугалар иде.

Яшьләр өчен ул вакытларда клублар булмагач, буш вакытларын аулак өйләргә җыелып күңел ачалар. Кызларның ата-аналары кунакка китеп, мич ашлары пешереп әзерләнгәч, егетләргә хәбәр таратыла. Егетләр гармунда уйный, кызлар җырлыйлар, бииләр. Балдак салыш, арка сугыш, телефон сугу кебек төрле уеннар уйныйлар. Кайвакыт, кеше белмәсен өчен, мунчага җыелып уйнаучылар да булган.

Язгы сабаннар сөрелеп, ашлыклар чәчелеп беткәч – Сабан туе, соңрак җыеннар үткәрелә. Аларның эчтәлеген язып тормыйм, чөнки алар бар җирдә дә бертөрле була.

Балачагым

Минем әтием Хәбибулла Нуримөхәммәт улы Башкортстанның Кушнаренко районындагы Әхмәт авылының урта крестьян гаиләсендә дөньяга килгән. Берничә ир туганы һәм бер кыз туганы булып, алар шул авылда игенчелек һәм малчылык белән көн күргәннәр. Олы туганы бик фәкыйрь булган һәм, берничә баласын ятим калдырып, яшьли үлгән. Калганнары урта тормышлы булып яшәгәннәр.

Кече улы – әти мәдрәсәдә укып белем алгач, аны Иштыбай авылына мулла итеп куйганнар. Чөнки авылның мулласы картаеп үлгән була. Картәтине мин белмим, кайчан вафат булгандыр. Картәнинең бик картаеп үлгәнен хәтерлим.

Шуннан соң әтине минем әниемә – Подлуб авылы Әхмәтдин мулланың иң олы (баш баласы) кызы Тәзкирәгә 1903 елны, 18 яшендә өйләндергәннәр. Әни 1885 елда дөньяга килгән, 1973 елны вафат булды.

Әни үз әнисен белми, бер кыз туганы белән бик яшьли ятим кала. Картәтием һәм картәнием дә искечә бик мәгълүматлы булалар. Алар һәрвакыт газета-журналлар алдыралар.

Байлыгы зур түгел иде. Алты почмаклы, ике ягы да бик кечкенә өй, шуңа терәп салган тормый торган зур гына бер йорт. Шул өйдә кызлар мәктәбе ачып, анда Гыйльми апа укыта иде. Ул вакытта әле мәктәп хөкүмәтнеке түгел, картәти аны үз карамагына алып, апа да укыткан өчен хак алмый иде булса кирәк.

Бер ат, бер сыер, өч-дүрт сарыклары бар иде.

Әкълимә белән Фәтхия апалар шәһәрдә укыйлар иде. Мин аларда укыганда Әкълимә апа Самарадамы, Уфадамы укыта иде.

Картәтием чама белән 72 яшендә, урманда утын кискән чагында паралич сугып, 2-3 көн ятып вафат була.

Картәни сугыш вакытында Казанда Гыйльми апаларда 90 тирәләрендә картаеп, сугышның ачлык афәтен күреп дөньядан китә. Әкълимә апа 72 яшендә, Уфада паралич сугудан берничә ай ятып, Гыйльми апа исә 72 яшь тирәсендә йөрәк авыруыннан, Фәтхия апа 32 яшь тирәсендә бавырына операциядән, Хәмит – минем яшьтәшем фронтта вафат була.

Әти ягыннан ике бабай яшьрәк вакытларында дөнья куялар. Ике зур бабай картайганчы яшиләр. Алар турында башкасын белмим.

Әтинең Иштымбайда салып куйган йортлары булмаганлыктан, әнине өйләнүгә үк алып килми. Зур булмаган алты почмаклы, яшел калай түбәле өйне эшләп бетергәч, әнине барып ала. Шуннан яңа гаилә тормышы башлана.

Килү белән 18 яшьлек әнине бер бала: «Әби, ашка бар безгә», – дип чакыргач, гомерем озын булырмы икәнни дип эченнән генә шатланган, бу хакта миңа күптән түгел генә сөйләгән иде.

Мин, олы бала буларак, 1906 елның башында дөньяга килгәнмен. Зәйтүнә дип исем кушарга уйласалар да, нишләптер, Шәкүрә дип куйганнар. Миңа иптәшкә Подлуб авылыннан 8 яшьлек ятимә кыз алып кайтып, аны тормышка чыкканчы әни карап үстергән. Зифаның чит кеше кызы икәнен мин бәләкәй чакта аңлап җитә алмый идем.

Әнинең барлыгы 10 баласы булган: бишесе бала чакта үлгән, бишесе яшәгән. Икенче кызы – Әминә Фирганәдә укып, шунда пенсиягә чыгып, шунда паралич сукканнан соң (ике мәртәбә сукты, беренчесеннән терелеп, 4-5 ел яшәде) 62 яшендә Фирганәдә вафат булды. Гарәби, Зөфәр дигән уллары фронтта үлде. Мошфика (Мәрьям) Сәмәркандта үзенең гаиләсе белән яши.

Бик кечкенә чагымны хәтерләмим.Үземне белә башлагач, күрше кызлары белән төрле уеннар уйный идек. Мин, биек койма башына утырып, «калакапка» башында кибет ачып, балчыктан ясаган калач, керәндель, миләш һ.б. уенчыклар белән «сату итеп эшләгәч», безнең урамга шоссе юл ясарга дип өйгән тишекле ташлар өеменнән, ташларга җеп үткәреп, чыбык көянтәгә элеп су китереп уйнап туйгач, күрше кызларын җыеп, «сабак» укыта башлый идем.

Кыр кәҗәсе кебек ыргып-сикереп уйнап йөргән, гамьсез балачагымның бер көнендә, әти мине Подлуб авылына укырга илтеп куйды. Бу 1915-1916 нчы уку елы булырга тиеш. Картәти үзенең тормыш корган зуррак өендә кызлар мәктәбен ачкан иде. Ул елны беренче сыйныф кына булып, аны Гыйльми апа укыта иде. Ул елны укырга-язарга өйрәндек. Иң элек гарәп телендә «Мөгаллиме әүвәл» дигән әлифба, аннан соң «Мөгаллиме сани» дигән китапларны укыганыбыз хәтердә калган *(Әхмәдһади Максудиның иң мәшһүр китаплары. – Ред.)*. Без утырган парталар,

берничә бала утырырлык итеп, озын такталардан эшләнгән иде. Укырга-язарга бик тиз өйрәндем. Гыйльми апа башта ук бик матур язарга өйрәткән иде.

1916-1917 нче елда икенче сыйныфта укыдык. Бу елда уку, матур язу һәм хисап дәресләре керә иде. Апалар башлангыч белемне кайдан алгандыр – белмим. Заманына күрә белемнәре яхшы, гарәпчә бик матур язалар иде.

Ул вакытта Әкълимә апа Самарадамы, Уфадамы укый иде бугай. Мин Әкълимә апага картинәйнең әйтеп торуы буенча хат яза идем. Ул мине бик мактый иде.

Дәресләрне кайвакыт җыр белән тәмамлый идек. Менә шул җырларның берсе:

Бу нурлы мәктәп, укыйк күмәкләп,
Булаек без шәп милләт юлына.
Карап тик тормам, бушка утырмам,
Ихласым бик дан – милләт юлына.

Башка куплетларын хәтерләмим.

Г.Тукайның «Туган тел»ен җырлыйбыз. Мин үзем Тукайның «Су анасы», «Пар ат», «Бала белән күбәләк» һәм башка бик күп шигырьләрен яттан белә идем. Уку сәгатьләре һәм тәнәфес күпме булгандыр, анысын хәтерләмим.

Бервакыт, иптәш кыз белән тәнәфестән соң дәрескә кереп өлгермәгән өчен, апаның почмакка бастырып куйганын гомер буена оныта алмадым, бик тә гарьләнгән идем.

Дәрес әзерләми килгәндә яки башка гөнаһлары булганда, бик сирәк булса да, апа андыйларны «бизәбит» калдыра иде. Ул сүзнең мәгънәсен үсеп, русча белә башлагач кына аңладым.

Яз көне имтиханнар башлана. Тыңларга ата-аналарның кайсылары килә. Уку-язу, шигырь сөйләү һәм җырлау белән тәмамлана.

Кыш көннәрендә апаның укыган кызлары икебезне дә чәйгә чакыра. Апа мине матур итеп киендереп, бәләкәй тәкыя калпак, шәльяулык бәйләтеп, яңа күлмәк кидереп алып бара да, анда оялчан булганлыгымнан, бернәрсә ашамый гына утыра идем.

Кич йокларга ятканда Хәмит, Сәлмән һәм минем арада апа янына яту өчен ызгыш башлана. Чөнки апа безгә бик озын әкиятләр сөйли иде. Патшалар, патшаларның кызлары, малайларның тормышы турында төрле маҗаралар, өч башлы аждаһалар, бармак зурлыгындагы малай һ.б. төрле кызыклы әкиятләр. Мин, басынкы кыз, җиңелеп, Сәлмәннең бу ягына ятам, апа уртада кала.

Шул елны кышкы каникулда, пар атларга кыңгырау тагып, бабай белән Фәтхия апаны алырга бардык. Ул Уразай дигән авылда, Галихан хаҗи дигән кеше тарафыннан ачылган кызлар мәктәбендә укыта иде. Ике катлы авыл йорты. Өске өйдән түбәнге өйгә, идәнне тишеп, труба үткәргәннәр. Аскы өйдәге кешеләр белән шул трубадан сөйләшәләр.

Моңа кадәре байлар йортында булмагач, шаккатып тордым. Өстәлдә мин күрмәгән сый-хөрмәтләр, төрле төстәге хәлвәләр, төрле кәнфитләр, җиләкле, чияле майлар – санап бетергесез... Мин, тагын оялуымнан, апа алып биргән бер-ике коймак, бер чынаяк чәй белән туктыйм.

Картәти инициативасы белән ачылгандыр, рус мәктәбе бар иде. Шул мәктәпнең кечкенә бер бүлмәсендә торып, рус кызы укыта иде. Апа кичләрен, мине ияртеп шул укытучыга барып, русча укырга-язарга өйрәтеп йөрде.

Дәвамы киләсе санда

*Текстны журналга **Гөлнара Халморадова** һәм **Ләйсән Данилова** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Безнең авыл

Ибраһим Гази

Кама Тамагының Олы Карамалы мәктәбендә физик тәрбия дәресе. Кызларның киемнәренә игътибар итегез. 1936 ел

Туган-үскән җирләрне сагынып, тагын үзебезнең авылга кайттым. Малай чакта чабып йөргән урамнар, җәйләрен какы җыйган Зират елгасы, кышын чаңгы шуган Тегермән тавы, язлый сарык саклаган Ике тау аралары, авыл уртасында челтерәп агып торган салкын инеш – барысы да, барысы да үз урыннарында. Тик инеш башындагы карт өянке агачлары гына юк инде: күрәсең, алар, картаюлары җитеп, берәр давыл вакытында ботак очларындагы бүрек-бүрек карга оялары белән бергә ауганнардыр.

Төшеп калмасын дип, ыштанны бөрмәсеннән кысып тоткан килеш, кайчандыр яшен ташыдай атылып йөргән урамнардан мин бүген әкрен генә үтәм. Малай чаклар хәтергә килә, күңел истәлекләр белән тула... Кырык елдан артык вакыт узып киткән булса да, кичә генә кебек, бөтенесе хәтердә...

...Өстемдә алача ыштан белән күк күлмәк. Башымда түбәтәй. Аягымда... аягымда бернәрсә юк. Урамда малайлар йөгерешеп йөргәнне күрәм дә, ни булды икән дип, урамга атылып чыгам. Әллә аю биетүче килгәнме? Юк, пыяла куючы килгән икән. Габсаттар абзыйларның җәен мин ялгыш бәреп ваткан тәрәзәләренә пыяла куеп тора. Тизрәк йөгереп барам. Тәрәзә куюны карап тору үзе бер рәхәт булса, пыялачының стенага сөягән «самахут»ын күз белән «ашау» тагын бер рәхәт. «Самахут»ын тотып карамакчы булып, мин аның елтыр-елтыр иткән көпчәгенә сузылам, ләкин пыялачы минем кулга суга. Болай якыннан «Самахут»ны без әле беренче тапкыр күрәбез. Малик

Хезмәт дәресе. Арткы планда мәктәпне күрәсез. Мөгаен, ул элекке мәчет бинасы булгандыр.

бабайлар авылда черегән бай булсалар да, алар Габдуллаҗанының да «самахут»ы юк, ә безнең ише ярлы-йолкышның ул инде төшенә дә кереп карамаган. Пыялачы артыннан (дөресрәге, «самахут» көпчәге артыннан) ияреп, без бөтен авылны йөреп чыгабыз. Аннары басу капкасына хәтле озатып куеп, күздән югалганчы артыннан карап торабыз.

Кайтышлый мин Габсаттар абзыйларның тәрәзәләрендәге яңа сыланган замазканы куптарып алам да, учымда әвәли-әвәли, үзебезгә таба йөгерәм. Каршыма күршебез Таифә нәнәй очрый.

– Әйдә әле, наным, Хәлфә абыеңнан хат яздырып алыйк, – ди ул миңа.

Таифә нәнәйнең улы сугышта. Ул, еш кына безгә кереп, улы турында сөйләп, елап утыра. Мин аны кызганам. Вакыт булганда, кәҗәсенә бакчадан чүп үләне җыеп бирәм.

Авылда хат укый белүчеләр булса да, оештырып яза белүче бер хәлфә абый гына. Хат яздырырга кирәк булган саен, кулларына биш тиен акча йомарлап, йә берәр йомырка тотып, бөтен кеше хәлфә абыйга бара. Хәлфә абый биш тиен, йә берәр йомырка хисабына «чуктыйн-чук, күптин-күп» сәламнәрне тезеп бирә.

Хат яздырып кайтып килгәндә, Габсаттар абзыйларның олы улы Габдерахман абый, капкадан чыгып, мине туктата.

– Моны син кырып алдыңмы? – ди ул, мине тәрәзә каршына китереп. Мин: «Юк!» – дим, валлаһи-таллаһиларны әйтеп, карганам.

– Ә кулыңда нәрсә?

Минем кулымда берни дә юк. Мин әвәли-әвәли арыгач, замазканы күпер башындагы казлар өстенә ыргытып калдырган идем. Учымны ачып күрсәтәм. Уч төбемә замазка каткан!

– Әйдә әле, әниең катына! – ди Габдерахман абый һәм мине өстерәп алып кереп китә. Әни инде минем кирәкне бирә.

Авыл урамнарын салкын томаннар каплый, кай көннәрне ап-ак кыраулар төшә. Без мәдрәсәгә укырга йөри башлыйбыз. Без инде Коръән укый беләбез, хәер, бер сүз дә аңламыйбыз. «Вә ийякә нәстәгыйн» дигән сүзне кычкырып укып җибәргәндә, миңа гел «идән астагы» булып аңлашыла. Без тарих та укыйбыз. Имеш, хәзрәти Галине дошманнар куып киләләр дә, чокырга төртеп төшереп, өстенә таш ата башлыйлар. Шулкадәре таш белән кыйнауга чыдый алмагандыр, үлгәндер, дип, дошманнар китеп баралар. Хәзрәти Гали баздан чыга, аңа берни булмаган, чөнки Җәбраил фәрештә, аның өстенә канатын җәеп, ташлардан каплап торган... Без укый торган тарих әнә шундый.

Кич белән без тагын мәдрәсәгә җыелабыз. Кайбер малайлар шушында куналар да. Әкият сөйләшеп, йә чиртмеш уйнап, йә мендәрләр белән сугышып, вакыт уздырабыз. Без уйнаганда коточкыч тузан куба, мендәр ертылып китеп, бөтен дөнья каз мамыгы

Безнең мирас №11 ноябрь 2021



Химия дәресе. Атаклы мөгаллим Кадыйр Халитов. (Казанның бер урамы аның туганы, сугыш батыры Рөстәм Халитов исемен йөртә.)

белән тула. Мәдрәсәнең мичен ягарга кем чираты булса, шул, өеннән утын, утыны югы салам алып килеп, мичкә яга. Уйнап туйгач, җен-пәриләр турында әкият сөйләшеп утырабыз. Сукыр Закир әйтә: «Мин быел җен күрдем, – ди, – мәче баласы хәтле генә, үзе кап-кара иде», – ди. «Сукыр шайтан, син аны ничек күрә алдың? Менә без сукыр да түгел, алай да күргәнебез юк», – дибез. «Сукыр булсам да күрдем инде менә, – ди теге, валлаһиларны әйтеп, ант итә башлый, – үзебезнең ишегалдында мәче баласыдай мыяулап тора иде, бисмилла әйтеп, таш белән оргач, юкка чыкты», – ди. Барыбыз да ышанабыз. Тәннәребез чымыр-чымыр итеп китә.

Закир албастылар турында сөйли башлый. Аның әтисен йоклаганда албасты баса, чалкан төшеп йокласа, кузгала алмыйча, ыңгыраша икән. Шуннан ул янына утын пүләне куеп ята башлый. Бер тапкыр шулай басылгач, пүләнне «албасты» өстенә тотып тондырган. Иртән торып караса, пүлән комганга эләгеп, комган танымаслык булып ямьшәйгән.

Мәдрәсәдән кайтырга чыгабыз. Төн кап-караңгы. Мин куркам. Галиәкбәрләр тыкрыгындагы мунча яныннан узганда, барлык белгән догаларымны укырга керешәм. Мунча җене чыгып тотмасын, дип, бик каты шүрлим. Кайтып кергәч, үзебезнең мәчедән курка башлыйм, ул миңа җендер кебек тоела. Бисмилла әйтеп, мин аңа тибеп җибәрәм, ләкин мәче, сукыр Закир күргән мәче баласы кебек, юкка чыкмый, ә һаман аяк астында буталып йөри.

Икенче көнне хәлфә абый, кашларын җимереп, бездән сорый:

– Кичә кич белән кемнәр мәдрәсәдә булды? Мичкә ягарга кем чираты иде?

Без куркуга төшәбез: ни өчен болай ачулы итеп сорый икән? Күрми дә торабыз, имеш. Аяк астында, яңа яуган кар төсле, кичә мендәрдән чәчелгән каз мамыгы аунап ята. Тиз генә җыеп алабыз. Ләкин хәлфә безне һаман әрли: «Кем якты? Ник күбрәк якмадың? Синең өчен мин монда үз утынымны ягармынмыни?» – ди.

Без кичә, албастылар, су аналары белән саташып утыра-утыра, морҗаны ябарга онытып кайтып киткәнбез, имеш. Хәлфә мичкә ягучыны пыран туздыра:

– Бар, бер аягың монда булсын, икенчесе өеңдә булсын! Әниеңә әйт, утын алып килеп хәзер үк яксын! Мин сине, болай булса, мәдрәсәгә аяк та бастырмам!

Малайның төсләре киткән, иреннәре калтырый.

– Хәлфә абый, безнең утыныбыз юк, салам ягабыз, – ди.

– Миңа дисә ник шунда тәртә башыгызны якмыйсыз. Бар, мәдрәсә миче ягылган булсын!

Дәресләрне тыңлый башлыйбыз. Хәлфә әле бер малайның, әле икенче малайның яңагына менеп төшә. Ул да түгел, Закир күңелдән бикләгән аятьне сөйләп чыга алмый. Нәрсәгә бәйләним икән, дип ачуы кабарып торган хәлфә, шушыны сылтау итеп, мескен Закирны колагыннан өстерәп чыгара да, идәнгә сузып салып, каеш чыбыркы белән тунарга тотына. Без, котларыбыз алынып, калтырашып утырабыз.

Мин куркудан белгәнемне дә җыеп әйтә алмыйм. Хәлфә абый яңагыма чалтыратып

җибәрә. Мин авып ук китәм. Торып баскач, иягем дер-дер калтырый, әйтәсе сүземне әйтә алмыйм.

...Шулай истәлекләргә чумган килеш авыл буйлап салмак кына атлыйм. Без укып йөргән мәдрәсә юк инде. Авылның урта бер җиренә унъеллык мәктәп салганнар. Аның тәрәзәләре генә дә безнең мәдрәсәнең ишеге кадәр бар.

Олы Карамалының 6 нчы класс укучылары кура җиләге җыя.

Каршында арба тәгәрмәчләре аунап яткан тимерче алачыгына җитәрәк, бөтенләй көтмәгәндә генә, Габдерахман абыйны очратам. Ул инде картаеп бара, чигә чәчләренә чал кергән. Исәнлек-саулык сорашканнан соң, мин моңа тотам да әйтәм:

– Әй-яй, син мине теге вакытта замазка өчен әнидән кыйнаткан идең!

Габдерахман абый исенә төшерә алмый тора.

– И-и, ул заманнар... – дип куя, – үтте-китте инде алар, бөтенләй булмаган да кебек. «Самахут» күрергә дип, бөтен авыл малае пыялачы Гали артыннан чаба торган иде. Хәзер виласипид кемдә генә юк. Матасыйклы да чатыр-чотыр килеп чыга, афтомашинасы да...

Габдерахман абыйның тимерчедә йомышы бар икән. Сөремләнеп беткән алачыкка килеп кердек. Битләре корымланып беткән бер яшь кенә малай күрек өрдерә. Гурнада янып яткан күмерләр, күрек «уф» итеп өргән саен, дөрләп китеп, очкын чәчәләр. Сандал янында, зур чүкечкә таянып, миңа таныш булмаган урта яшьләрдәге бер кеше басып тора. Алачык эченә кызган тимер, яна торган күмер исе таралган.

Идәндәге тимер-томыр арасыннан нидер эзләүче бер кеше, тавышымны ишетеп, башын калкыта да, миңа бераз карап торганнан соң:

– У, авылдаш, кайттыңмыни! – дип, күрешергә кулын сузып, миңа таба килә башлый. Бу минем замандашым Хәбибрахман. Аның да чыраена картлык төсләре керә башлаган. Без Хәбибрахман белән мәдрәсәдә укып йөргән идек. Хәлфә абый, ике колагыннан күтәреп, аңа «Мәскәү күрсәтә» торган иде.

– Нихәл соң колаклар? – дим мин. – Ул заманнан бирле авыртмый торгандыр инде?

Хәбибрахман, көлеп, колакларын сыпырып куя.

– Укып йөргән булдык инде без дә, – ди ул, гурнадан тәмәкесен үрләтеп алып, авызыннан төтен чыгара-чыгара. – Минем малай, әнә, Мәскәү университетының физика бүлеген бетереп чыкты. Кунакка кайткан чагында шундый нәрсәләр сөйли, карчык белән, исебез-акылыбыз китеп, тыңлап торабыз. Безгә ялган, аңа чын: яңа ай ясыйлар, ди, ясап бетергәч, җир тирәли әйләнеп йөрерлек итеп очыртып җибәрәчәкләр, ди. Янәсе, караңгы төннәрдә бер генә ай җитми, күрәсең! Тагын бер ай кирәк!

Алачыкка тагын кешеләр керә, сүзгә ияреп сүз чыга тора. Безнең авылдан шушы кырык ел эчендә нинди укымышлы кешеләр килеп чыккан, шуларны санарга тотынабыз. Мин инде ул кешеләрнең исемнәрен дә белмим, күргәнем дә юк. Аларның күбесе Совет власте заманында туып, үзебезнең авылдагы унъеллык мәктәпне бетереп чыккан кешеләр. Алар, безнең кебек, иске мәдрәсәдә укымаган. Яңа мәктәптә,

Безнең мирас №11 ноябрь 2021



Олы Карамалы авылының бүгенге күренешләре

совет мәктәбендә, фән «чишмәсе»ннән эчеп үскәннәр. Алар бездән бәхетлерәк.

Киләшчә белән каптырып тоткан утлы тимер өстендә чүкеч бии, очкыннар безнең аякларыбызга сибеләләр. Алачык эче тимер тавышыннан чаң-чоң итеп тора. Сөйләшер өчен без тышка чыгабыз. Хәбибрахман, бармакларын бөгеп, санарга керешә, башкалар кычкырып әйтеп торалар.

– Сәгъдиевләрнең Миңлеҗамалы – духтыр, бөктеңме бармагыңны? Гыйззәтев Мәхмүт – очучы, Айтугановларның Мәнафы – агроном, Уразаев Гаптелхак – мал духтыры, Галимов белән Галимова Фәридә – мондый духтырлар, санап өлгерәсеңме?

– Малик белән Фәридә үлделәр бит, аларны санамыйм.

– Как санамыйсың? Безнең авылныкылар, үлгән булса да сана.

– Бармакларың бетмәдеме әле? – дип кычкыра арттан икенче берәү. – Хәзер мин әйтә башлыйм, санарга тотын. Исмаева Нәгыймә – инженер, Хөснуллин Хәсип – полковник, Тимерханова Мәгъсүмә немец теле укыта. Немец теле укытуны әллә син ансат дип беләсеңме? Мөхетдинова Асия духтырлыкка укыды, хәзер инде ул духтыр булырга тиеш.

– Укытучыларны ник бер дә телгә алмыйсыз? – дип Самат чәчрәп чыга. – Тукта, оясы белән әйтим әле. Бөгә башла бармагыңны! Ә? Бармак бетте? Ботинкаңны сал да аяк бармакларыңа күч.

Һәм менә ул дистәләп укытучыны санап чыга. Кая монда бармак җиту! Бер безнең Олы Карамалыдан гына шулхәтле укытучы! Санаганда бәхәсләр дә кубып куя.

– Шагеевларның Әшрәфе укытучы түгел, ә зоотехник. Белмисең икән әле, ә тыгылган буласың.

– Ә бухгалтерларны санамыйбызмыни?

– Рабочий классны оныттыгыз, – дип килеп кысыла яшьләрдән берәү. – Безнең авылдан шахтерлар да бар. Шагеев Зәкине кая куясыз? Кизел шахталарында күмер чыгара. Ә кочегарларны? Миңнуллин Хәбибулла кочегар бит. Тимерханова Әнисә Казанда мех фабрикасында эшли. Ә тракторчылар? Ә комбайнчылар? Сафаров Мөнир – тракторчы. Уразаев Наил – комбайнчы.

– Хәзер анда эшләми.

– Эшләмәсә, эшләгән, барыбер.

Уртада – Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Газинур Әүхәт улы Габидуллин һәм «Безнең мирас« журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон классик әдип Ибраһим Газиның авылдашлары белән. Олы Карамалы. 7 октябрь, 2021 ел. ***Ленар Гобәйдуллин фотосы***

Бик күп, санап бетерерлек кенә түгел. Финанс работниклары да бар, райисполком председательләре дә, умартачылар да, мәктәп директорлары да, кассирлар да, җырчылар да, төрле югары уку йортларында укучылар да…

Кешеләр, кызып китеп, һаман саныйлар. Мин, аларны туктату өчен, болай дип куям:

– Карагыз әле, Олы күлнең без малай чактагы су анасы үлде микән инде?

Дөресен әйтим, Олы күлдәге су анасын минем үземә күрергә насыйп булмады. Ә менә сукыр Закир, коенырга барган саен, су анасының елаганын ишетеп кайта торган иде.

– Хәзерге заманда су анасы Тукай әкиятендә генә калды инде, – дип куя Габдерахман абый, көлеп, – бер дә елаганы да ишетелми, малайлар җәй буе күлдән кайтып кермиләр, аларга да тими.

– Заман башка, тияргә курка, – дигән була, шаярып, Хәбибрахман.

Дөрес әйтә Хәбибрахман. Заман башка. Әле моннан утыз-кырык еллар гына элек су аналарыннан, албастылардан өркеп яшәгән агайларның кызлары, уллары бүген докторлар, инженерлар, ветеринарлар, очучылар, бухгалтерлар булып эшлиләр. Бер караганда, бу искиткеч түгелмени? Ләкин без инде күнеккән. Бер дә гаҗәпләнмибез. Моннан утыз-кырык еллар элек хөкем сөргән албастыларны да инде онытып барабыз. Әйдә, онытыла бирсеннәр, кирәкләре сукыр бер тиен. Әмма шулай да кайвакыт, искене искә төшереп, гыйбрәт алу бик файдалы, бүгенгенең кадере арта төшә.

Мин Габдерахман абыйга шулай дип сөйләп бирәм.

– Күрше, – ди Габдерахман абый, – әйдә, миңа кереп, бер чәйләп чыгыйк. Замазканы кайчандыр кырып алгансың икән, мин инде аны күптән бәхилләдем. Иске күршеләрчә бер рәхәтләнеп сөйләшеп утырырбыз.

Һәм без Галиәкбәрләр тыкрыгы белән түбән очка төшеп китәбез. ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Гарифҗан Мөхәммәтшин шигырьләре

Керим әле урманнарга

Рөстәм Яхин көе

Керим әле урманнарга,
Урманнар арасына;
Сөйлим әле моңнарымны
Сандугач баласына.

Керим әле урманнарга,
Урманнар арасына;
Сагышларны адаштырыйм
Каеннар арасында.

Керим әле урманнарга,
Урманның карасына;
Бәлки, дәва табалырмын
Йөрәгем ярасына.

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Безнең гомер

Безнең яшәү бары каралама,
Язалмадык акка күчереп.
Хәлсезләндек, ахры, яши-яши,
Хәтсез югалтулар кичереп.

Ихласы да булды, уены да –
Үзебезчә булды барсы да.
Такыр юлда кайчак сөртенгәнбез,
Ашыгудан, әллә ярсудан.

Башлаганы булган, ташлаганы,
Югалтканы... сөеп бетерми.
Уйламыйча нокта куйганбыз шул,
Кую кирәк чакта өтерне.

Изге эшләр азрак башкарылган,
Кыеклары күбрәк кылынган.
Заманы да килде – йөрмәдек шул
Чәчәк җыеп кына болыннан.

Без күрәсен башка кемнәр күрсен –
Язмышларга шулай язылган.
Сабырлыклар кайчак җитмәгәндер,
Түзәр чакта тузып азылган.

Ә гомер бер, күпме үкенсәң дә,
Булмый аны кире кайтарып.
Безнең гомер бары каралама,
Соң төшендем, беткәч картаеп.

Ак кәгазьгә күчереп өлгермәдек,
Анысына вакыт калмады...
Ә шулай да юкка яшәлмәгән,
Гомер үткәч, шуны аңладым.

Бу дөньяда юкка яшәлмәгән –
Нидер кала җирдә бездән дә.
Искә алыр кемдер без утырткан
Алмагачтан алма өзгәндә.

Гарифҗан Мөхәммәтшин (уңнан беренче) каләмдәшләре һәм хезмәттәшләре – Шәүкәт Галиев, Ринат Мөхәммәдиев, Марат Әхмәтов, Аяз Гыйләҗев, Ренат Харис белән туган төбәгендә – Балтач районында. 18 май, 1994 ел. ***Мидхәт Шакирҗанов фотосы***

Редакциядән: *Танылган шагыйрь, тәрҗемәче, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Гарифҗан Мөхәммәтшин күптән түгел гомер бәйрәмен билгеләп үтте. Әдипне олы юбилее белән ихластан котлап, саулык-сәламәтлек, иминлек, иҗат уңышлары теләп калабыз!* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Яңгыр астындагы мәхәббәт

Ибраһим Гази

Көзге көннең көлүе, көлүе дә елавы... Әле генә ялтырап кояш килеп чыга, ул да булмый, тагын болыт, тагын яңгыр... Шәһәр бакчасында умырылып-умырылып яфрак коела. Сары яфрак. Бакча юлы яфрактан чуп-чуар...

Бакчачы хатын, себерке белән себереп, яфракларны күч-күч өеп бара. Ул себереп киткән җиргә шундук тагын умырылып-умырылып кызыл яфрак төшә...

Аулак бер эскәмиядә егет белән кыз бер-беренә сыенып утырганнар. Кызның иңбашларында, чүмәлә итеп өелгән чәчләрендә – юеш яфрак. Егетнең аркасына каз тәпие сыман өрәңге яфрагы кунган, шундый ук яфрак тезләрендә дә... Яңгыр бер ява, бер туктый. Кояш бер күренә, бер кача. Әллә кайда, бик еракта, пароход тавышы... Гүя: «Туңам, бик туңам!» – дип зарлана.

Бакчачы хатын, себерке сабына таянып, яфрак бураны астындагы кыз белән егет ягына елмаеп карап тора. Тегеләр бер-беренә сыенышып утырганнар, кыймылдап та бакмыйлар. Аларның кешедә эшләре юк. Аларга яңгыр ни дә, яфрак коелу ни... Хатын карап-карап тора да аннары тагын юеш кызыл яфракларны себерергә, өем-өем өяргә тотына... Үзе һаман елмая...

Ә бакчада умырылып-умырылып сары яфрак коела...■

Кыйсса итеп сөйләрлек

Алмаз Хәмзин

Рәсемдә: өченче рәттә сулдан өченче – Фәннур Сафин, уңнан икенче – Фәрит Солтанов; дүртенче рәттә уңнан беренче – Наис Гамбәр, уңнан икенче – Марсель Галиев, сулдан икенче – Азат Ганиев, икенче рәттә уңнан өченче – Фәридә Гаффарова; алда уртада – укытучы-остаз Флера Сафиуллина. 1970 ел

Узган гасырның туксанынчы ел башы. Без, телевидениеда эшләүче бертөркем редакторлар, режиссерлар – Фәннур Сафин, Риман Гыйлемханов, Рөстәм Фатыйхов, Гасиман Ширгазин, милли күтәрелешнең шытып килгән чорында,әлеге хәрәкәт йогынтысына ияреп, экранга шактый кыю тапшырулар чыгара башладык. Әлбәттә, телевидение җитәкчеләре һәм башка өлкән остазларыбыз да бу юнәлешкә ияреп киттеләр. Легендага корылган байтак әсәрләрне экранлаштыру дисеңме, язучыларның әсәрләрен телевизион форматта халкыбызга тәкъдим итүләрме, яңа патриотик җырлар яңгыратумы – болар барысы да безнең тарафтан эшләнеп, бернинди каршылыксыз, милләтебезнең рухын ныгытуга зур өлеш кертте.

Менә шул чорлардагы халәтнең кайбер лирик шагыйрьләребезнең иҗатында чагылуы да табигый хәлдер. Мәсәлән, бу фикерем халкыбызның яраткан шагыйре Фәннур Сафин шигырендә ярылып ята. Ул – телевизион фильмнарның берсенә үз кулы белән язылып, беркайда да басылмыйча, минем архивта әлегә кадәр сакланган кадерле ядкяре хәзер дә актуаль, дип әйтер идем.



Фәннур Сафин

Яшүсмер Фәннур

Болгар гимны

Гомер буе эшчән, батыр булдык,
Баш имәдек җирдә беркемгә.
Табигатьтә байлык һәр адәмнең
Үз кулында, рухы иркендә.

Кушымта:
Алтын куллы болгар – зирәк халык! –
Диеп таный җирдә бар гавам.
Яшьләрдә дә йолдыз булып янсын,
Алга барсын безнең бу дәвам!

Бу дөньяның ярлы-ябагае
Кызыгадыр безнең байлыкка. –
Корал алып яулап алмак булса,
Җир-су анам, үзең ярлыка!
Кушымта.

Гел иминлек теләп илләр гиздек,
Туганлык та дуслык теләдек.
Уйлый калсаң, безнең изгелекне
Кыйсса итеп кенә сөйләрлек!

Кушымта:
Алтын куллы болгар – зирәк халык! –
Диеп таный җирдә бар гавам.
Яшьләрдә дә йолдыз булып янсын,
Алга барсын безнең бу дәвам! ■

Остазларым белән горурланам

Әнвәр Хәйри

Әнвәр Хәйри (1947-2014)

СССР заманында бик күп оешмаларда, газета-журнал редакцияләрендә, югары уку йортларында, мәктәпләрдә дивар газеталары чыга иде. Шәхсән мин белгәннәрдән, әйтик, Татарстан Язучылар берлегендә – «Тынгысыз каләм» (язучы-шагыйрьләр Гөлшат Зәйнәшева, Фаил Шәфигуллин, Камил Кәримов, Марсель Галиев һәм Ләбиб Лероннар төрле елларда (1960-1990) аның редакторы булды), «Яшь ленинчы» газетасы редакциясендә – «Пионерстан», Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында «Әдәби сүз» газеталары шундыйлардан иде. Ул газеталарның бер өлеше минем архивымда саклана да әле. «Балкондагы мирас» дип йөртәм мин аларны. Олуг галимебез – әдәбиятчы һәм фольклорчы, филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Марсель Хәернас улы Бакировның «Безнең мирас» журналханәсенә алып килгән «Әдәби сүз» газетасы да (алар җәмгысе өч төргәк) – һәммәбез өчен кадерле ядкяр, кыйммәтле мирас. Күренекле татар галиме, исламият белгече, язучы, тәрҗемәче, текстолог, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре (1991), Татарстанның атказанган фән эшлеклесе (1999), Татарстанның Каюм Насыйри исемендәге премиясе лауреаты (2004) Әнвәр Хәйринең (1947-2014) биредә бирелгән истәлек язмасы һәм фотосурәте әлеге газетаның «Татар бит мин, үзем дә чын татармын» дигән махсус кушымтасыннан (1994 ел) алынды.

Ләбиб Лерон

Еллар, еллар... Әй, бигрәкләр дә тиз узып китәләр бит шул тиктормас еллар дигәнең! Булсын иде аларны беразга гына туктатып торып яки кире кайтарып алып! Юк шул, булмый!.. Кара син аны, ни арада утыз елга якын вакыт үтеп тә киткән. Югыйсә әле генә булып узган кебек, ул еллар һаман да күз алдында торалар. Шуларны искә төшереп утырып, кулыма каләм алдым. Юк, мин үзем турында язарга җыенмыйм. Башкалардан аерылып торган җирем юк. Минем язмыш – дәһшәтле сугыш елларыннан соң ачлы-туклы, ярым ялангач үскән, авыр тормышның бөтен тәмен татыган авыл малайлары һәм кызлары язмышы. Мин бүген үземнең остазларым – безгә барлык белемнәрен, йөрәк җылыларын биргән кадерле укытучыларым һәм сабакташларым – 476 нчы төркем егетләре һәм кызлары турында бераз искә төшермәкче булам. Безнең өчен бик кадерле булган бу кешеләрнең кайберләре инде арабыздан да китеп бардылар. Аларның авыр туфраклары җиңел, рухлары шат булсын иде!..

1966 ел. Университетка керү теләге белән Казанга килдем. Ләкин мин, берни дә белмәгәнлектән, соңга калып килгәнмен икән. Кабул итү имтиханнары тәмамланган иде инде. Күземә яшьләр килеп, төп бинадан чыктым да: «Нинди бәхетле кешеләр укый икән биредә?» – дип уйланып басып торам. Шулвакыт авылдагы бер сабакташым килеп чыгып, мине тынычландырды да, үзе белән ияртеп, Театр училищесына алып китте. Конкурс зур булса да, мин керә алдым. Авылдан килгән бар байлыгым – зур чемодан (фанердан ясалган) белән арыш капчыгына тутырган урын-җиремне бер кардәш тиешле кешеләргә куеп торып, укып йөри башладым. Фатирсыз интегеп, өч ай буена бакчаларда, татар зиратында, подъездларда, вокзалларда йоклап йөрдем. Әллә нәрсәләр булып бетте... Ләкин мин беркемгә дә зарланмый идем, чөнки уку теләге көчле булды. Училищеда безне ул чактагы университет доценты

Университет укытучылары Фәһимә Хисамова белән Мөхәммәт Мәһдиев имтихан алган вакытта

Галимә Диләрә Тумашева, комсомол һәм партия эшлеклесе Борис Леушин, галим-мөгаллимнәр Хатыйп Миңнегулов һәм Марсель Бакиров. 1985-1990 нчы еллар

Вахит абый Хаков татар теленнән укытты. Укуга хирыслыгым сәбәплеме, белмим, ул бервакытны миңа: «Университетта укырга кирәк сиңа...» – дип әйтеп куйды. Анда бер курс укыгач, документларымны алып, имтиханнарны уңышлы тапшырып, университетка, күпме татар зыялылары тәрбияләп чыгарган бүлегебезгә укырга керү бәхетенә ирештем.

1967 ел. Безне, укырга кереп тулай торака урнашу белән үк, Актаныш районының Чишмә колхозына көзге басу эшләренә булышырга җибәрделәр. Группа җитәкчебез – Флера апа Гыйльманова (Ганиева), ягъни безнең икенче әниебез. Һәрвакытта көләч йөзле, ярдәмчел, барыбызны да кайгыртып йөрүчән, күбәләк кебек җиңел һәм җитез хәрәкәтле, бал корты кебек эшчән Флера апабыз бер ай эчендә төрле җирдән җыелган авыл балаларыннан менә дигән бердәм, дус-тату 476 нчы төркемне туплап кайтты. Кешелеклелеккә һәм бер-беребезгә теләсә кайчан ярдәм итәргә әзер булу сыйфатына без аннан өйрәнә идек. Шуңадыр да инде, группабыздагы кул-аяклары хәрәкәтләнми торган Энгель исемле бер гарип сабакташыбызны без, егетләр, һәркөнне аның тулай торагына барып, күтәреп укырга алып килә идек, химкорпустан «Бегемот»ка, аннан төп бинага, төп бинадан химкорпусның 4 нче катына, шулай ук башка җирләргә күтәреп йөгерә, соңыннан тулай торагына илтеп куя идек. Ул гәүдәгә авыр, таза иде, ә без – «кефир малайлары», иртән эчкән кефир пары белән көне буена иптәшебезне күтәреп йөгерәбез, тик зарланмый, шулай булышырга кирәк дип саный идек. Чөнки мондый игелекләргә безне Флера апабыз өйрәтә иде, юк, сүздә генә түгел, ә үзенең гамәле белән дә... Ул кафедра эшләреннән бушаган арада тулай торакка да йөгереп килеп җитә, безнең яшәү шартларыбыз, ашау-эчүебез белән кызыксына, кемгә нинди ярдәм кирәклеген сораша иде. Бу искиткеч кешелекле, гаҗәеп нечкә күңелле укытучыбызны, икенче әниебезне без бик нык ярата идек һәм хәзер дә бик еш сагынып, яратып искә алабыз.

Безнең бүлегебез татар зыялыларын әзерләп чыгару остаханәсе булганлыктан, анда укытучы остазларыбыз да берсеннән-берсе булганрак олуг шәхесләр иде. Кайсының гына исемен телгә алсак та, күз алдына тирән белемле, киң күңелле, ярдәмчел һәм тыйнак, сабыр һәм үзенең кыяфәте, килеш-килбәте, үз-үзен тотышы белән дә сине тәрбияли һәм үзенә карата ихтирам уята торган затлар килеп баса.

Еллар үткән, укыган еллар бездән ерагайган саен, без үзебезне олы тормыш юлына бастырган остазларыбызның кадерен ныграк белә барабыз, аларны олылап, сагынып, мактап искә алабыз. Аларның безнең өчен эшләгән изгелекләрен мәңге онытырлык түгел! Шундый остазларда белем ала алуыбыз белән без бик бәхетле. Алдарак билгеләп үтүемчә, безнең 476 нчы төркем үзенең бердәм, тату, тырыш булуы белән аерылып тора иде. Укытучылар да безне үз итәләр, яраталар һәм кичләрен даими рәвештә тулай торакка, безнең бүлмәләребезгә килеп, озаклап сөйләшеп утырырга да вакыт табалар иде. Башка уку йортларында ничек булгандыр, ә безнең остазларыбыз тулай торакка килеп йөрүне күркәм бер гадәткә әйләндергәннәр иде.

Безнең бүлекнең «атасы» Хатыйп ага Госман булса, «анасы» Диләрә апа Тумашева иде. Үзләренә дә, безгә дә бик таләпчән, ләкин һәрвакытта безгә карата яхшы теләктә булган бу ике «хуҗабыз»ның күзләренә генә карап тора идек. Алар бик күп нәрсәгә күзләребезне ачтылар. Флера апа Сафиуллина, Фәһимә апа Хисамова, Алмазыя апа, Вахит абый Хаков, Сәгадәт абый Ибраһимов, Илдус абый Гыйләҗев, Гомәр абый Саттаров, Камил абый Биктаһировлар безгә туган телебезнең барлык нечкәлекләрен, аның гүзәллеген һәм бөеклеген танырга өйрәттеләр. Аларда укыган бер генә кеше дә Бөек Татар Теленә битараф калмас. Без аларның дәресләрен мөкиббән китеп тыңлый идек.

Белемнәренең тирәнлеге һәм сабырлыклары белән безне сокландыра торган Резидә апа Ганиева, Флера апа Гыйльманова (Ганиева), гаҗәеп кызыклы, мавыктыргыч итеп сөйли торган җор телле Мөхәммәт абый Мәһдиев, әдәбият белеменең фәлсәфи биеклекләрен җиренә җиткереп төшендереп бирүче Ибраһим абый Нуруллин, шигърият диңгезенә сәяхәткә алып кереп китүчеләр – Нил абый Юзиев белән Зәет абый Мәҗитов, борынгы чыганаклар белән безне дә үзе кебек бик бирелеп, төбенә чумып эшләргә өйрәтә торган Хатыйп абый Миңнегулов, тылсымлы кулъязмалар дөньясына җитәкләп алып керүче Альберт абый Фәтхиев, серле шәрык телләренең ачкычларын кулларыбызга тоттыручылар – мәһабәт гәүдәле, үзенең чибәрлеге белән бөтен хатын-кызны «аяктан ега» торган җырчы-шагыйрь һәм танылган галим Мостафа абый Ногман белән хур кызыдай чибәр, белеме белән үз

Беренче рәсемдә: галим Хатыйп Госман (уртада) һәм Ибраһим Нуруллин (сулда); икенче рәсемдә: Флера Ганиева (уңда) һәм Дания Заһидуллина (уртада)

фәненә гашыйк итә торган Лена апа Таҗиева кебек укытучыларыбыздан белем алу хәтеребезгә гомеребезнең иң матур еллары, иң бәхетле мизгелләре булып уелып калды. Алар бездә гаҗәеп бай әдәбиятыбызга карата олы мәхәббәт тәрбияләделәр, беренче мөстәкыйль фәнни адымнар ясарга өйрәттеләр. Шушындый олы шәхесләр алдында ничек баш имисең дә, ничек итеп аларга гомер буе бурычлы булып, рәхмәт әйтеп искә алмыйсың ди инде?! Һәр укучы тормышта ирешкән уңышлары белән укытучысы алдында мәңге бурычлы булып кала.

Шушы сүземне раслап, үзем дә тормышымда, эшемдә, иҗатымда ниндидер уңышларга ирешкәнмен икән, алар, һичшиксез, минем остазларымның уңышлары, казанышлары дип саныйм. Чөнки алар миңа кеше өчен иң кыйммәтле байлык – белем бирделәр, каләм тибрәтергә, уйларга-фикерләргә, серләр тулы фән дәрьясында колач салып йөзәргә өйрәттеләр һәм мин аларның бу изгелекләрен гомерем буе да түләп, кайтарып бетерә алмам кебек.

Әлеге сүзләремне, иң олы рәхмәтләремне мин, беренче чиратта, безне гарәп теленнән укыткан Лена апа Таҗиевага юллыйм. Чөнки мин университетка кергәч тә гарәп теле укытылганын белеп бик шатланган идем. Француз телен өйрәнү дәресләреннән качып, гарәп теле дәресләренә йөргәнем өчен миңа «чара кулланып» бер семестр стипендия түләмәсәләр дә, барыбер гарәп теленә йөрдем, өйрәндем. Лена апа үзенең сабырлыгы, студентларга теләктәшлеге, искиткеч киң күңелле һәм шул ук вакытта бик таләпчән булуы, дәресләрне кызыклы һәм мавыктыргыч итеп уздыра белүе белән безне җәлеп итә иде. Авыррак, катлаулырак темаларны ул дәрестән соң калып, хәтта тулай торакка килеп тә аңлата, вакытын кызганмыйча безнең белән шөгыльләнә иде. Серле вә тылсымлы гарәп язмалары, борынгы кулъязма чыганаклар белән эш итү алымнарына ул өйрәтте безне. Эш сөю, түземле булу, кабаланмыйча эшләп, үз алдыңа куйган максатка ирешергә тырышу, вакыт белән исәпләшмичә, һәрдаим чыганаклар өстендә эшләү кебек асыл сыйфатларны да һәм борынгы бабаларыбыз калдырган гарәп язулы гаҗәеп бай мирасыбызны сабырлык вә түземлек белән өйрәнергә кирәклеге турындагы акыллы фикерләрен дә сеңдерде ул безгә. Лена ападан «йоккан» әлеге матур «авыру» белән мин үзем дә менә инде чирек гасырдан артык «авырыйм». Борынгы чыганакларны өйрәнү, берәүнең дә кулы тимәгән һәм гасырлар серен үзендә саклап ятучы, әллә нинди язу үрнәкләрендә язылган тылсымлы китаплар дөньясында гизү кебек мавыктыргыч та, авыр һәм катлаулы да, кызыклы һәм хыялый да, серле һәм биниһая күп көч вә түземлек таләп итә торган башка һөнәр юктыр төсле тоела миңа. Мин гүя борынгы бабаларыбызның рухлары белән очрашам, аларның кичерешләре, акыл байлыгы, уй-хыяллары, каһарманлыклары һәм фаҗигаләре-һәлакәтләре күз алдыма килә. Әйтерсең лә, мин, һәр борынгы чыганакны ачу белән, шул китаптагы вакыйгаларда үзем дә катнашам, ерак бабаларыбыз белән сүзсез генә серләшеп утырам… Менә шундый, берни белән дә алыштыргысыз, гаҗәеп серле дөньяга кертеп җибәрде мине Лена апа. Минем кулдан ничә дистә яки йөз мең борынгы китап узгандыр – әйтә алмыйм, әмма шунысы ачык: аларның һәрберсе – яңа бер ачыш, яңа бер дулкынлану, кичерешләр дөньясы булып тора. Кайберәүләр өчен борынгы китаплар, бәлки, тузанлы, гөмбәле һәм кулга алырга да шикләндерә торган искелек калдыклары гына булып торадыр, ә минем өчен алар – әйтеп бетергесез байлык! Менә шушы байлык дәрьясында йөзәр өчен акыл, белем, түземлек, сабырлык, эш сөю, авырлыклар алдында каушап калмау һәм максатыңа һәрчак тугрылыклы булып калырга өйрәткән Лена апага һәм барлык башка Остазларыма дөньяның бөтен рәхмәтләрен һәм ахирәт нигъмәтләрен телим. Алар алдында башымны иям… ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

КАРА ТӘКЪДИР

(Ачы язмышлы шәхесләр)

КӘРИМИ ФАТИХ (1870-1937)

Татар журналисты, язучы, мәгърифәтче, җәмәгать эшлеклесе, сәясәтче. 1870 елның 30 мартында Бөгелмә өязенең (хәзерге Әлмәт районы) Миңлебай авылында ахун гаиләсендә туган.

1937 елның 4 сентябрендә ул Мәскәүдә кулга алына һәм 27 сентябрьдә төрек шпионы буларак хөкем ителеп, шул ук көнне атып үтерелә. Каберенең кайдалыгы билгесез.

КӘРИМ ЯРЛЫ (1901-1937)

Татар шагыйре, каһарман шагыйрь Фатих Кәримнең абыйсы. Габдулла Әхмәтвәли улы Кәримов (Ярлы Кәрим) 1901 елның 16 июнендә Башкортстанның Бәләбәй өязендәге (хәзерге Бишбүләк районы) Ает авылында мулла гаиләсендә туган.

1926 елда Ярлы Кәрим, Гражданнар сугышында алган яралар һәм контузияләр нәтиҗәсендә каты авырып китеп, хастаханәгә эләгә һәм шул авыруыннан терелә алмыйча, 1937 елда Уфада вафат була.

Дәвамы. Башы журналның 10 нчы (2020) санында.

КИНЗИН МӘҖИТ (1911-1974)

Юллар төзү инженеры. Яркәнд шәһәрендә Русиядән күчеп килгән татар гаиләсендә туган. 1935 елда аның гаиләсе Кытайдагы Колҗа каласына күченеп китә.

Мәҗит Кинзин 1943 елда яңа хакимият тарафыннан кулга алына. Иреккә чыккач, ул Көнчыгыш Төркестан Республикасы гаскәрендә майор булып хезмәт итә.

1954 елда Казакъстанга күчә. Алма-Атада җирләнгән.

ЛАТИФЗАДӘ АБДУЛЛА (1890-1938)

Кырымтатар шагыйре. 1890 елның 26 августында Акмәчеттә (Симферополь) мөгаллимнәр гаиләсендә туган.

1937 елда контрреволюцион эшчәнлектә гаепләнеп кулга алына һәм, хөкем карары чыгарылып, 1938 елның 17 апрелендә атып үтерелә.

МАКСУДИ САДРИ (1878-1957)

Тюрколог. Казан губернасының Биек-тау төбәгендәге Ташсу авылында мулла гаиләсендә туган. Франциядәге Сорбонна университетын тәмамлаган. Бөек милләтче. Русиянең Дәүләт Думасы (1907-1912) һәм Төркиянең Бөек Милли Мәҗлесе депутаты (1930-1938).

Садри Максуди Ватанына кайта алмыйча, 1957 елның 20 февралендә чит җирдә вафат була. Истанбулда җирләнгән.



Текстны басмага ***Рабит Батулла** әзерләде.* ■

Безнең мирас №11 ноябрь 2021

Мирасыбыз хәзинәсенә бөртекләр

(«Безнең мирас» журналын укыгач)

Илдар Низамов

«Безнең мирас» журналының 8 нче санын (2021 ел), укып бетергәч тә, җыеп куймадым, кул астында кала бирә: әһәмиятле берничә тарихи фактны өстисе килү күңелне кыбырҗытып тора. Тәвәккәллим әле, бәлки, күңел бушату гына булмыйча, кемгәдер кирәге дә чыгар.

Менә Миркасыйм Госмановның «Минем соңгы археологик табышым...» дигән язмасы (21-25 б.) тарихи, фактик чыганак буларак та, кеше хисләрен сурәтле тасвирлаган сәнгати әсәр буларак та бик тәэсирле. Тик хәзер әйтәсе фикерем фотосурәткә карата. Анда бу текстта берни дә әйтелмәгән шәхесләр дә бар. Ә әйтәсе килә. Менә Миркасыйм абый белән янәшә утырган Вахит абый Хаков турында ничек әйтми түзим! Бөтен халкыбызга яхшы мәгълүм галим, йөзләрчә шәкерте бүген дә татар мәдәниятен, әдәбиятын, фәнен яшәтүдә, аны үстерүдә тугры хезмәт иткән мәшһүр мөгаллим. Безне укытырга дистәләп дәреслек, кулланма язып чыгарган, телебез тарихын, аның төп асылын ачып биргән хезмәтләр язган белгеч буларак тарихыбызда лаеклы урын алган. Дөньякүләм билгеле Казан федераль университетының атаклы профессоры Вахит Хөҗҗәт улы Хаков – минем дә остазым: ике диссертациямнең дә җитәкчесе, күпчелек фәнни хезмәтләремнең мөхәррире яисә рецензенты. Хәер, аның халкыбызга әле озак хезмәт итәргә лаеклы мирасы турында мин дә берникадәр язганмын. Менә китапханәләрдән табып булырлык берничәсе: «Советская тюркология», 1986, №4 (автордашы – С.Ибраһимов); «Кыйблага тугры калып», бүгенге «Безнең мирас» журналы (элгәре

Алгы рәттә (сулдан): Нил Юзиев, Гомәр Бәширов, Вахит Хаков, Миркасыйм Госманов (уңнан өченче) һәм арттагы рәттә уңнан беренче – Гомәр Саттаров. 1961 ел

«Мирас» журналы) 1996, №7,8; «Остазларым, шәкетләрем» – КФУ нәшр., 2013; «Хөҗҗәт углы – хакыйкать иясе»; «Бөртектән – көшел». – ТКН, 2016.

Бу фотосурәттә татар филологиясе факультеты галим-галимәләренең бик яшь чагы. Шулай да танып була. Менә арттагы рәттә уңнан беренче – Гомәр абый Саттаров. Татар кафедрасына аспирантурага кергәндә бик тинтерәтсә дә, без озак еллар эшлекле бәйләнештә булдык – Татар филологиясе буенча диссертацияләр яклау советының әгъзалары идек. Гомәр абый шагыйрь дә иде – шигырьне аягүрә генә чыгару остасы. Әлеге Советның икебезгә дә чыгыш ясарга туры килгән бер утырышыннан соң, миңа багышлап та шигырь чыгарган иде. Ул аны соңыннан машинкада бастырып та бирде. Аның төрле юнәлешле гыйльми эшчәнлеге, мөгаллимлек тырышлыгы фәнни матбугатта да, гаммәви чараларда да шактый киң яктыртылды.

Бу фотосурәттәге бүтән затлар да төрле сыйфатлары белән үрнәк алырлык кешеләр. Өметләнәм ки: сурәтне күңел биреп «тикшереп», тасвирнамәне дәвам иттерергә алынучылар булмый калмастыр.

***

Икенче язма Нурихан Фәттах көндәлегеннән өзек – «Алар бик нык ышаналар...» (хатыны Руфинә Фәттахова әзерләп биргән; 53-55 б.). Аны башлап җибәргән фотосурәтне дә бик бирелеп, андагы унбер кешене дә хәтергә төшереп, истәлекләргә бирелеп, уйланып-хисләнеп утырдым. Иң башта, әлбәттә инде, Нурихан абыйның үзен зиһен төпкелләреннән үткәрдем. Мин, Елга техникумында укыганда, Казанның иҗатчы яшьләре белән аралаша башладым. Башлыча «Яшь сталинчы» газетасының мөхәррире, шагыйрь Гали Хуҗи, урынбасары Рафак Тимергалин, бүлек мөдире, шагыйрь Рәшит Гәрәй җитәкчелегендә эшләп килгән яшь язучылар түгәрәгендә Илдар Юзеев, Суфиян Поварисов, Рәшит Шәкүрев, Миншәих Зәбирев, Равил Сәгъдиевләр белән аралашып, әсәрләребезне тикшерәбез, өлкәнрәк әдипләребезне тыңлыйбыз. Арада Нурихан абый Фәттах та булгалый.

Техникумны тәмамлап, Агыйделдә, Караиделдә штурман булып эшләп алып, аннары «Кызыл таң» газетасына күчеп, анда сигез ел эшләп, Башкортстанны аркы-

Тарих-филология факультетының татар әдәбияты бүлеге студентлары (КДУ, IV курс): беренче рәттә сулдан – Роза Хафизова, ..., ..., уңда – Сәгадәт Ибраһимов; икенче рәттә – Фатих Хәсәнов, ..., ..., Рафак Тимергалин; өченче рәттә – Нурихан Фәттах, Настя Боярова, Зәет Мәҗитов. 1950 ел, май

лыга-буйга гизгәндә дә Нурихан абый белән очрашкаладык. Казанда яшәгән башкортстанлылар Госман Садә, Роберт Миңнуллин, Фәнил Мансуров һәм башкалар, якташым – райондаш шагыйрь Самат Шакир Уфага килгәндә, «Кызыл таң»га керми китмиләр иде. Туган телебез, милләтебез, бу төбәк турында аеруча мәгълүматлы Нурихан абый белән бик теләп аралаша идек.

Казанга кайтып, башта «Социалистик Татарстан»да, аннары Татарстан китап нәшриятында эшләгәндә инде аралашу ешайды, мин аңа этимологиягә караган сораулар бирә идем. «Шәҗәрә» китабын да ул миңа, култамгасын салып, шуны истә тотып биргәндер. Әле менә фотосурәттәге нурлы йөзенә карыйм да, аңа рәхмәт хисе янә ташып китә. Хатыны Руфинә ханымның һәм балалары Алмаз белән Чулпанның кешелекле булганнары (җае чыгып, алар белән аралашкаларга туры килде) өчен дә зур рәхмәт.

Янә рәхмәт менә әлеге фотосурәтне калдырганы өчен. Үземә берничек тә кагылышы булмаган очраклы фотосурәттә моңарчы шундый якын, кадерле кешегә юлыгып, берьюлы шулкадәр истәлек-хатирәгә бирелгән юк иде әле. Миңа да таныш тагын менә кемнәр Нурихан абый белән укыган икән: Роза ханым Хафизова (фотосурәттә беренче рәттә сулдан беренче) күренекле язучыбыз, балалар матбугаты мөхәррире иде; шул темага багышланган әсәрләремне бастырды; укучылар белән очрашуларда бергә катнаштык, безнең район мәктәпләренә дә кайткаладык.

Аның белән бер рәттә, уңнан беренче Сәгадәт абый Ибраһимов филология фәннәре кандидаты, КФУның татар теле кафедрасы мөгаллиме иде. Гаҗәп тә тыйнак, итагатьле, шул ук вакытта шәкертләренә, хезмәттәшләренә гадел, таләпчән, әз-әкрен сөйләп, күп җиткерә ала торган чын галим-мөгаллим иде ул. «Газета теле», «Татар телендә синтаксик синонимнар» кулланма-дәреслекләре, җөмлә төзелешенә караган мәкаләләре журналистларга, укытучыларга дәрес биргәндә ышанычлы чыганаклардан булды. Берсендәге: *«Илдар дуска. Тормыш диңгезен өйрәнеп язган әсәрләрең янында тел дәрьясына багышланган китапларың да урын алсын. Сәгадәт»,* – дигән теләген берникадәр үти алуыма сөенәм. Кызы Лилия Татарстан китап нәшриятында рәссам вазыйфасында озак еллар эшләде. Әтисе белән фикердәшләр иде.

Фоторәсемнең икенче рәтендә сулдан беренче – Фатих абый Хәсәнов. Күренекле мөхәррир, тәрҗемәче. Мин, Мәскәүдә укып кайтып, Татарстан китап нәшриятында сәяси һәм тарихи әдәбият редакциясе мөдире булып эшкә керешкәндә, ул шундагы алты мөхәррирнең берсе, иң җаваплы әсәрләрне басма-

га әзерләү аңа тапшырыла иде. Көне буе баш күтәрми эшли торган тырыш кеше. Ул, энесе Мансур – Татарстан Хөкүмәте Рәисенең урынбасары, Татарстан Фәннәр академиясенең беренче президенты, Татар энциклопедиясе басмаханәсенең җитәкчесе кебек зур җитәкче кергәндә дә, кульязмасыннан бик аерылмый иде.

Сурәттә Фатих абый Хәсәнов белән бер рәттәге икенче таныш егет – Рафак абый Тимергалин. Аны инде телгә алдык. Элек тә язганым бар иде. «Социалистик Татарстан» газетасында алты ел аның кул астында эшләдем, күп нәрсәгә өйрәндем. Нәшриятка күчкәч тә, фикердәшләр, иҗатташлар булдык – нәшрият чыгара торган сәяси басмаларның даими тәрҗемәчесе иде ул. Университетта махсус тәрҗемә курсын укытканда, булачак журналистларга аның тәҗрибәсен дә җиткерергә тырыштым. Үзен дә дәресләргә чакыра идек.

Фотосурәтнең өске рәтендә Нурихан абый белән тагын бер егет –Зәет абый Мәҗитов. Күренекле шагыйрь, галим, университет мөгаллиме. Аның турында белгечләр язганны да табып була, аларга нидер өстисем юк. Аралашучан, ихлас кеше буларак ярата идем. Бакчаларыбыз язучыларның Васильево янындагы дача ширкәтендә иде. Янәшәдәге сулыкка балык тотарга йөрибез. Вакыт табылганда, читтәге елга һәм күлләргә дә баргалыйбыз. Бик иртүк торып. Зәет абый Мәҗитовның бакчасы белән күрше Мөхәммәт абый Мәһдиев тә иртә тора. Безне капкасына сөялеп, сүзсез генә озатып кала. Балыкчы белән ни сөйләшәсең… Зәет абый белән дә әллә ни гапләшми идек, күп булса, бакча хәлләре, табигать кызыкмызыгы, балыкчы мәзәкләре…

***

Җанга ятышлы шундый хатирәләр кузгатканы өчен «Безнең мирас»ка тагын бер кат рәхмәт әйтеп, өченче фотосурәткә күчик. Ләбиб Леронның Әтнә районына багышланган язмасын (60-68 б.) «Искра» хуҗалыгының элеккеге рәисе Фәйзи абый Галиев, Татарстанның Беренче Президенты Минтимер Шәймиев һәм район башлыгы Габделәхәт Хәкимовның Олы Әтнәдә мәдәният-спорт комплексын ачу тантанасында төшкән фоторәсеме ачып җибәрә. Әтнәләрне биредә мәдәният-спорт комплексын ачу тантанасында котлау мизгеле. Президент турында да, Габделәхәт Гыйлемхан улы турында да әйтеп тормыйм, район җитәкчесен Илбашы да, автор да бу текстта бик урынлы тасвирлаган.

Ә менә Фәйзи абыйны телгә алмый булмый, гәрчә аның турында язмаларымда әйткәләгәнем булса да. Ул үзе дә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы иде, унлап китабы бар. Тарихи әһәмиятле фактларны гына яңартып алыйм. Казан артында да манаралы мәчетләр бер-ике генә калган иде. Мокшыдагысын саклап тотарга Фәйзи абый бөтен көчен куйды. Ниһаять, аны музей итеп булса да сакларга рөхсәт алды. Авылдашы – галим Илдар Әүхәдиевнең дә тырышлыгы белән чын мәгънәсендә тарихи-мәдәни үзәк барлыкка килде. Ачылышы да саллы бер тантана булды. Язучылардан Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, мин дә чакырылган идек. Музейның фикерләр дәфтәрендә уртак язмабызны калдырдык. Әдәби кичә Түбән Шашы авылының яңа салынган мәдәният йортында бик зурлап үтте. Планда култамга белән китап сату да каралганга, мин юньле-башлы китабымны таба алмаганга борчыла башлаган идем дә, Фәйзи абый Лаеш тирәсеннән «Мәхәббәт хакы» дигән калын китабымны табып кайткан булып чыкты. Сөендерде. Гариф абый өчебез исеменнән иртәнгә үк кичәнең төнге өчкә чаклы ничек үтүе турында репортаж мәкаләсен дә язып өлгерткән, безгә кул гына куярга кушты. Язма «Социалистик Татарстан»да басылып чыкты.

Фәйзи абый гомере буе көндәлек язып барды. Авылы белән колхозының гына

түгел, бөтен районның, төбәкнең елъязмасы. Бервакыт ул редакциядә, шулардан китап «ясап» булмасмы, син булышмассыңмы, дип сүз кузгатты. Бик кызыксынсам да, баш тартырга туры килде: Мәскәүгә ике елга укырга китеп барыш иде – газетаның Казан арты төбәгендәге үзхәбәрчесеннән ризалык алдык. Бер елдан кайткач, белешсәм: кечтеки генә «брошюра» чыгара алганнар. Шундый рухый хәзинәнең әрәм булып ятуына көенү көчәйде генә.

Язмыш, диген. Шул елны ук Фәйзи абыйны СССР Югары Советына депутат итеп сайладылар. Бер килүендә кунакханәдә Гариф абый Ахунов белән дә бергә туры килдек. Теге «китап» искә төште дә, тәкъдим ясадым. Килештеләр. Бер елдан Татарстан китап нәшриятына эшкә кайткач, уртак тырышлыкның уңай нәтиҗәсенә дә ирешелде: «Авылым гадәтләре» дигән саллы гына китап дөнья күрде. Аннары дәвамы һәм башка китаплар… Фәйзи абый Язучылар берлегенә кабул ителде.

Аның белән гел аралашып яшәдек. Соңгы тапкыр мин аның янына, туксанын тутырып, котлау-тантаналардан соң бераз ял итеп алганын чамалап, кереп чыккан идем. Язып утыра. Яңа гына чыккан калын китабын сыйпый-сыйпый күрсәтте. Ашыкмыйча гына култамгасын салды. Керүемнең төп сәбәбен әйттем: беренче китабының Гариф абый Ахунов әдәби эшкәрткән кульязмасын студентларга сабак биргәндә нәшрияттан алган идем, миндә калган. «Шуны кайсы музей-архивка тапшырыйм?» – дидем. Бик исе китмәде: «Үзең кара инде», – диде.

Фәйзи абый юк инде. Авылыбыздан Әтнәгә, Казанга сирәк кенә барырга туры килгәндә гел ул яткан зират яныннан үтәбез, рухы шат, урыны оҗмахта булсын, дип дога кылабыз.

***

Инде җай чыккан икән, журналыбызның бу санындагы тагын бер язмага карата да фикер әйтү теләге бар. Себергә багышланган язма да уңай тәэсир калдырды. «Азат Себер» газетасы белгечлегем буенча да якын, җитмәсә әле, таныш исемнәр дә дикъкатьне арттырды: *«Азат Себер»не ил күләмендә билгеле татар матбугатына, Себер өлкәсе газетасына әверелдергән кеше Муса Йосыпов була…»* – дип язылган журналда. Аның турында Галимҗан Ибраһимов сүзләре дә искә төшерелә.

Әйе, таныш исемнәр… Бу газеталар мин Уфада эшләп алган «Кызыл таң» газетасының элгәреләре. Газетта эшли башлагач та, аның илле еллык тарихы белән кызыксынып киттем. Баш мөхәррирребез урынбасары Үзбәк абый Гыймадиев, байтак еллар тикшеренү нәтиҗәсендә, мул материал туплаган иде, шул исәптән Муса Йосыпов турында да. Уртаклашты. Язмалары газетабызда да чыкты.

Атаклы мөхәррирне, «Азат Себер»не зиһендә яңартырга янә бер сәбәп булды: инде Казанга кайтып, тарихи темаларга, аерым алганда, күренекле язучы, журналист, җәмәгать эшлеклесе Гыйлемдар Баембәтев турында повесть язарга алынгач, тагын ярты гасырдан соң боларны искә төшербез дип кем уйлаган. Гражданнар сугышы барган фаҗигале көннәрдә дә татар газеталары чыгу – зур тарихи казаныштыр. Атаклы 5 нче армия органы булып Бөгелмәдә Гыйлемдар Баембәтев тырышлыгы белән чыга башлап, Себергә кадәр озын, авыр юл кичкән татарча «Кызыл яу» газетасы да – татар матбугаты тарихының якты сәхифәләре булып санала ала. Менә шул газета, Омскида да бераз чыкканнан соң, «яулар» тәмамлангач, «Азат Себер»гә нигез була да инде. Хәер, бу хакта сүзне дәвам иттерү – белгечләр эше. Аларга уңышлар телик.

Илдар Низамов, *галим, ветеран журналист* ■

Мирхәйдәр Фәйзи кабере – Баймакта

«...Драматург һәм шагыйрь Мирхәйдәр Фәйзинең тормышы (бер кыш Казанда балалар китапханәсендә эшләвен һәм бераз Уфада яшәп алуын санамаганда) Юлык (*монда яшәгәндә М.Фәйзи атаклы «Галиябану» пьесасын яза.* – Ред.), Баймак, Темәс авыллары белән бәйле. 1928 елның июль башында бу олы әдип һәм кызыклы шәхес Баймакта туберкулез авыруыннан вафат була. Ул Гражданнар сугышы каһарманнары каберлегендә тантаналы шартларда җир куенына иңдерелә.

Хәзер матур бер шәһәргә әверелгән Баймак уртасындагы ул каберлек әле дә бар. Кайчандыр Мирхәйдәр Фәйзи каберенә йолдызлы һәйкәл дә куелган була (фотосы саклана). Ул таушалгач, 1980 елларда, күренекле драматург Туфан Миңнуллинның да тәкъдимен истә тотып, шәһәр җитәкчелеге яңа кабер ташы куйган иде. «Видный советский драматург Мирхайдар Файзи. 1891-1928», – дип язылган ул истәлек ташын мин 1988 елның көзендә фотога да төшергән идем. Ләкин хәзер ул затлы таштан куелган һәйкәл юк, ахры, һәрхәлдә, 1994 елның җәендә без, Зәфәр Бәширов белән, аның урынында бер тимер казык кына күрдек. Ә Мирхәйдәр Фәйзи заманыннан бирле чыгып килүче «Октябрь байрагы» газетасы яңа бинага күчкән. Менә шул җыйнак бина каршында Мирхәйдәрнең мөлаем бюсты редакциягә килеп-китүчеләрне каршылый һәм озатып кала. Димәк, баймаклылар әдипне бөтенләй үк онытмый, олылый әле».

(Чыганак: Лирон Хәмидуллин. Ак төннәр хәтере: Әдәби очерк, эссе, хатирәләр. – Казан: Татар.кит.нәшр., 2002. – 224 б.) ■

Баймак районының үзәк китапханәсендә М.Фәйзигә нисбәтле стенд. 20 октябрь, 2021 ел

Баймакта Мирхәйдәр Фәйзигә куелган бюст. 20 октябрь, 2021 ел

Татарстаннан килгән баш мөхәррирләр Вахит Имамов («Мәдәни җомга»), Рөстәм Галиуллин («Казан утлары»), Ләбиб Лерон («Безнең мирас») – М.Фәйзи кабере янында. Баймак. 20 октябрь, 2021 ел

Истә, һаман да истә!

Драматург Мирхәйдәр Фәйзинең туууына 130 ел

Татар әдәбияты классигы, драматург, шагыйрь, фольклорчы Мирхәйдәр Мостафа улы Фәйзи (Фәйзуллин) 1891 елның 1 ноябрендә (кайбер чыганакларда – 31 октябрьдә) Оренбург губернасының Орск өязендәге Күкшел авылында туган. Ул миллионер Хөсәеновларның утары дип санала. Әдипнең әтисе Мостафа («мишәр Мостафа») чыгышы белән Казан губернасының Чистай өязендәге Шыкмай авылыннан, әнисе исә Оренбург янындагы Каргалыдан.

М.Фәйзи әүвәл шигырьләр яза. 1912-1913 нче елларда ул шигырьләрдән генә торган ике китап бастыра. Шул ук елларда Орскидагы драмтүгәрәк өчен «Яшьләр алдатмыйлар» исемле беренче пьесасын иҗат итә.

М.Фәйзи 16 сәхнә әсәре яза, 7 пьеса тәрҗемә итә, халык җырлары җыентыгын төзи, 200дән артык шигырь һәм дистәләгән хикәя яза, 70 көндәлек дәфтәре калдыра.

М.Фәйзи Баймак районында (Башкортстан) якты эз калдырган: 1919-1921 нче елларда ул Юлык авылында мәдәни-агарту эшләрен башкара, аннан Темәстә драмтүгәрәк режиссеры һәм «Кызыл Урал» газетасында хезмәткәр булып эшли.

М.Фәйзи 1928 елның 9 июлендә Баймак шәһәрендә вафат була һәм шунда җирләнә.

Җырчы Мәрьям Рахманкулованың туууына 120 ел

Җырчы, Татарстан Композиторлар берлеге әгъзасы (1940), ТАССРның (1944) һәм РСФСРның халык артисткасы (1957) Мәрьям Мәннан кызы Рахманкулова 1901 елның 20 ноябрендә Казан шәһәрендә туган.

1929 елда ул Казан шәрык музыка техникумын вокал буенча (Е.Ковелькова классы) тәмамлый. 1928-1934 нче елларда Татарстан радиосы солисты һәм музыкаль редакторы була.

Мәрьям Рахманкулова 1930 елда Мәскәүдә Милли театрлар олимпиадасында катнаша, анда үзенең беренче грампластинкасын яздыра.

1934-1938 нче елларда ул Мәскәү консерваториясе каршындагы Татар опера студиясендә вокал (Е.Петренко классы) һәм композиция буенча (Г.Литинский классы) укый.

1939-1960 нчы елларда – Татар опера һәм балет театры солисты.

Мәрьям Рахманкулова 1990 елның 8 февралендә вафат булды.

Тарихчы Корбангали Халидинең тууына 175 ел

Этнограф, тарихчы, дин эшлеклесе, чыгышы белән татар булган казакъ галиме Корбангали Халиди 1846 елның 1 ноябрендә (кайбер чыганакларда – 30 ноябрь) Аягүз шәһәрендә туган. Корбангалинең әтисе Халид Казан өязендә сәүдәгәр була, ул чыгышы белән Арча районының Орнашбаш авылыннан.

Корбангали Халиди 1874-1913 нче елларда Чүгүчәк (Сергиополь) мәчетендә имам вазыйфасын башкара. 1897-1898 нче елларда ул Чүгүчәкнең абруйлы байларыннан булган Рамазан Чанышев белән бергә егерме ай хаҗ сәфәрендә була.

К.Халидинең беренче китабы «Тарихи җәридән җәдидә» дип атала. Ул Казан сәүдәгәре Шәмсетдин Хөсәен улының матди ярдәме белән 1889 елда Казан университеты табыгханәсендә басыла. Галимнең «Тәварихы хәмсәи Шәркый» дип аталган, 799 биттән торган икенче китабы 1910 елда Казанның «Үрнәк» басмаханәсендә нәшер ителә.

К.Халиди 1913 елда вафат була.

Әдәбият галиме Альберт Яхинның тууына 90 ел



Күренекле әдәбият галиме, педагог, журналист, 1977 елдан СССР Язучылар берлеге әгъзасы, РСФСРның атказанган мәдәният хезмәткәре (1973) Альберт Гатуф улы Яхин 1931 елның 8 ноябрендә Татарстанның Арча районындагы Арча бистәсендә туган.

Ул 1949 елда – Тымытык урта мәктәбен, 1954 елда Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаганнан соң, Азнакай районының Тымытык авылы урта мәктәбендә ике ел укыту бүлеге мөдире булып эшли. Альберт Яхин 1956-1959 нчы елларда аспирантурада укый, 1964 елда «Шамил Усманов иҗаты» дигән темага кандидатлык диссертациясе яклый.

1959-1975 нче елларда ул «Чаян» республика сатирик журналы редакциясендә эшли: анда тугыз ел – җаваплы сәркатип һәм җиде ел баш редактор вазыйфаларын башкара. Альберт Яхин 1975-1981 нче елларда Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетында татар әдәбияты кафедрасына җитәкчелек итә. 1975 елда әдипнең «Әйттем исә кайттым» дигән сатирик хикәяләр һәм фельетоннар китабы дөнья күрде.

А.Яхин 2010 елның 2 октябрендә вафат булды.

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Алтын йөрәкле кеше

Әхтәм Зарипов

Роберт Әбелмәмбәтов
(1942-2002)

Әлеге дәрәҗәле исем өчен республика конкурсында 2000 елда җиңүгә ирешкән Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры директоры Роберт Шәрифҗан улы Әбелмәмбәтов мондый титулга лаек булганнардан соңгы шәхес түгелме икән? Театр 2022 елда мактаулы директорына 80 яшь тулуны тантана белән билгеләп үтәр иде, хәзер инде, аны хәтерләүчеләр дә бетеп баргач, тантанага өмет итү буш хыял гына булыр.

Роберт Шәрифҗан улының Тинчурин театры директоры вазыйфасына кадәрле тормыш юлын искә төшереп узыйк.

Ул 1942 елның 25 февралендә Оренбург өлкәсенең Зиянчура районындагы Юлгытлы авылында туган. Урта мәктәптән соң Казан театр училищесында укып, һөнәри артист белеме алгач, 1964 елда Г.Камал исемендәге Татар дәүләт ака-

демия театрына эшкә алына. Театр коллективы бар яктан да килгән бу чибәр егетне үз итеп, яратып кабул итә. Режиссерлар аңа зур өмет баглап, роль артыннан роль биреп, артистның иҗади мөмкинлекләрен сыныйлар. Роберт бу сынауларны җиңел уза.

Без, аның коллегалары, Робертны үз итеп, «Әбүл», дип йөри идек. Аның «Әбүл» дигәнгә үртәлгәнен дә, кимсенгәнен дә хәтерләмим. Ул тормышыннан да, иҗатыннан да канәгать иде. Бер сүз белән әйткәндә, күндәм кеше иде Роберт. Тормышы хыялларына тәңгәл килгәндерме-юктырмы, безнең карашка, чибәр булуы аңа, ярдәмнән бигрәк, зыянны күбрәк китермәдеме икән? 1964 елда Г. Камал театры ремонтланган бинасында эшли башлады. Сәхнәсе заманча таләпләргә туры килә, яктырту техникасы яңача, грим бүлмәләре иркен. Иң кирәкле саналган буфетта һәрчак төрле ризыкны алып була.

Хрущев заманын хәтерләүче, икмәккә дә тилмергән чакларда, буфетыбыздан әҗәткә өчпочмак алып ашаганын онытмастыр. Ул гына түгел, кайчакларда, нәфес чыгып, 50 граммны да «кара дәфтәр»гә яздырып алырга була иде. Әнә шул «кара дәфтәр»гә яздырганда, безгә Әбүлнең ярдәме кирәк иде. Театрның буфетчысы (Үзбәкстан якларыннан кайткан) Сания атлы чибәр хатын иде. Буфет тирәсендә яшь артистларның өзелмәве, өчпочмак яки 50 грамм аулаудан да бигрәк, шул Саниянең игътибарына лаек булу иде шикелле. Әмма Саниянең күзе дә, күңеле дә безнең Әбүлгә төшкән икән. Кирәк нәрсәне «кара дәфтәр»гә яздырып алу өчен, Әбүлнең аңа бер җылы карашы җитә иде.

Ничек булгандыр, Әбүлебез бермәлне Сания һәм аның кызы белән бергә кысынкы гына бер бүлмәдә яши башлады. Безнең: «Кайсы белән йоклыйсың?» – дип төрттерүләребез дә, яшь аермасы да бу парны аера алмады. Әбүл Саниянең (беренче иреннән туып) ияреп кайткан кызын да үз баласы кебек карап үстерде, кияүгә бирде.

Ни кызганыч, Сания ханымның Әбүлдән баласы булмады. Әбүл өчен бала үстерү мәшәкатьләрен театр алыштырды…

…К.Тинчурин театры директоры булганчы, Әбүл күп сынаулар аша уза. Аңа гына түгел, әлеге театрга да сынау арты сынау килә.

Игътибарны театрның тарихына юнәлтик.

Алдынгы колхозчыларның Беренче Бөтенсоюз съезды карары нигезендә, Кәрим Тинчурин инициативасы белән, татар дәүләт академия театрының филиалы буларак, колхоз-совхоз театры оештырыла. Аның беренче «оя»сы Шәле авылында булып, беренче директоры итеп Гали Ильясов билгеләнә.

Тәүге спектакльләре К.Нәҗми һәм К.Тинчурин язган «Булат бабай семьясы» дигән пьеса буенча куела. Яңа театрның иҗаты шуның белән башлана. Ә 1938 елдан театр «6 нчы татар дәүләт колхоз-совхоз театры» дип атала башлый. Үзәге Балтач районына күчерелә. 1940 елда бу театр – Арчага, 1942 елдан Буага күчерелеп, «Буа дәүләт колхоз-совхоз театры» дип үзгәртелә. 1944 елдан ул, Казанга кайтарылып, «Татар дәүләт республика күчмә театры» дип атала башлый. Төпләнгән урыны булмый. Кем якты йөз күрсәтсә, шуның бинасында эшлиләр.

1960 елда әлеге театрга Казан Кремленең Спас манарасында урын бирелә.

Ә 1979 елда, Татарстан Министрлар Советы карары белән, Татар дәүләт республика күчмә театры «Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дип үзгәртелә. Ниһаять, директор Роберт Әбелмәмбәтов тырышлыгы белән, 1988 елның 4 маенда РСФСР Мәдәният министры карары буенча, театрга Кәрим

Тинчурин исеме бирелә һәм ул «Кәрим Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры» дип йөртелә башлый. Шул ук елда, ниһаять, театр үз бинасына ия була. Бу чакта инде безнең Әбүлебез – Роберт Шәрифҗан улы Әбелмәмбәтов – Рәсәйдә мактаулы һәм иң булдыклы директорлар сафында исәпләнә иде.

Аңа кадәр директор булганнарның директорлык чорын Әбүлнеке белән чагыштырганда, безнең Әбүл, Мөхәммәт Хәмзиннан кала, икенче урында. (Беренче директор – Гали Ильясов, икенче директор – Әсгать Мәҗитов. Аннары М.Хәмзин, С.Шакиров, М.Шиһапов...)

Дилбегә 1984 елдан Әбүл кулында. Әбүлгә кадәрге чорда, исеме алышынса да, җисеме үзгәрмәгән театр турында Илдар Юзеев:

«Син һәрвакыт юлда...
халык белән:
Салкын кышны, эссе җәйләрен.
Рәхмәт сиңа безнең уйны-хисне
Тамашачы белән бәйләрең.
Син һәрвакыт юлда... халык белән.
Тормыш үзәгеннән киләсең.
Син фаҗига булып кайгырасың,
Комедия булып көләсең»,

– дип язган иде.

Роберт Шәрифҗан улы Әбелмәмбәтов җитәкләгән театрның Чиләбе, Төмән, Уфа, Оренбург, Екатеринбург, Мәскәү һәм Петербург шәһәрләрендә, Казакъстан, Үзбәкстан, Азәрбайҗан һәм Төркияләрдә уңышлы гастрольләреннән соң, халык шагыйре Илдар Юзеев бу театрга багышланган башка шигырендә Роберт Әбелмәмбәтовка:

«Фаҗига һәм көлке тамашасын
Җитәкләүче артист Робертка
Рәхмәт төшсен шундый заманда да
Әйләнмәгән өчен роботка.

Әйтмик пока, әмма белеп тор:
Булмас, ахры, синдәй директор!»

– дигән бәя бирә.

«Робот» сүзен уйлап чыгаручы һәм әсәрләрендә кулланучы кеше чех язучысы Карел Чапек дигән мәгълүмат бар. Ул – кеше үз үрнәгендә, кешенең кайбер физик функцияләрен кабатлый алучы хиссез, тоемнарсыз, фикерләүдән мәхрүм, эшләүчесе кушканны гына үтәүче автомат җайланма, машина. Шагыйрь директорга роботка әйләнмәскә куша. Әмма, мәгълүм булуынча, кешедә, аның табигатендә роботлык тумыштан ук килә. Ләкин кеше яшәешендә бу сыйфатын кулланмый. Гомере буена үз максатына, теләкләренә ирешергә омтыла.

Әгәр аны тормыш кайчакларда роботка әверелергә мәҗбүр итә икән, ул үз максатларыннан баш тартмый гына, робот кебек кушканны гына үти башлый. Андый кешене күндәм кеше диләр. Күндәм булу начар түгел. Әбүл бик тә күндәм кеше иде.

Күндәмлек өчен илләр белән илләр, милләтләр, аерым шәхесләр сугыша. Күндәмлек белән уңышка ирешүләр дә булгалый. (Япония белән Көньяк Кореяның тарихына игътибар итик.)

Г.Камал театрының директоры булып эшләгәндә әлеге театрның исеме илдә иң дәрәҗәлеләр сафында санала, даими тамашачысы репертуарын яратып кабул итә, хуплый. Әмма театр өчен иң мөһиме – тамашачының сәхнәдән үз проблемаларына аналогия табуында. Театр сәнгате һәр тамашачыга үз аналогиясен табу мөмкинлеге бирергә тиеш. Шулай булмаганда, тамашачы спектакльдән мәзәк кенә көтә. Безнең тамашачы – тамаша дип мәзәк табу, көлке эзләү остасына әверелгән халык. Аның рухи халәте, шул кысалардан чыгып, уйлану, чагыштыру, үзендә яңа фикер туу баскычына күтәрелә алмый. Театрга тамашачының яратып йөрүен тәэмин итүне аның элекке директоры Рәшидә Җиһаншина һәм баш режиссеры Марсель Сәлимҗанов репертуарны көндәлек идеология тоткынлыннан коткарып, тамашачы зәвыкларына буйсындыруда күрәләр.

Роберт Әбелмәмбәтов та, директорлык чикмәнен бөркәнгәнче, әзер учакка утын өстәүдән уза алмый. Ул гына да түгел, күндәмлегенә тап төшергән тактик хаталар да ычкындыра. Шуларның берсе Мәскәүгә Щепкин исемендәге театр училищесына икенче төркем студентлар укытырга рөхсәт сорап, СССР Мәдәният министрына гариза-хат язуы булгандыр дияргә җирлек бар.

Бу вакытта баш режиссер Марсель Хәкимовичның Камал театрыннан бер төркем яраннары белән Нократ елгасы буенда ял итеп яткан чагы була.

Әбүл уйлавынча, әгәр Мәскәүдән уңай җавап килсә, баш режиссер моңа шатланачак һәм, булдыргансың, дип, директорны мактаячак. Җавап озак көттерми. Чөнки мәдәният министры Демичевның сәркатибе – 1 нче татар студиясен укыткан Галина Петровна Аржанова. Баш режиссерны директор министрлыктан килгән хат белән каршы ала. Тик Марсель Хәкимовичны бу шатлык үрти генә:

– Кем кушуы буенча Щепкин училищесын сорадың? – ди ул Әбүлгә. Әбүл ыкмык килеп нидер әйткәч, Марсель Хәкимович:

– Ишкәнсең икән ишәк чумарын! – ди.

Әбүл:

– 1 нче щепкинчыларыбыз картая ич, алмаш кирәк… – дип өсти.

Марсель Хәкимович:

– Алмашны мин Щукин училищесында, Вахтангов традицияләрендә укытмакчы идем, – ди.

Бу сөйләшүләр ни белән тәмамлангандыр. Әмма Камал театрының баш режиссеры 2 нче татар студиясенә абитуриентлар әзерләүгә игътибар бирми. Курсны тәмамлап кайткан яшь артистларны да колач җәеп каршыламый, күңеленә хуш килгәннәрен генә сайлап ала.

Студия тәмамлаган яшь артистлар барысы бергә булганда гына театрда тамыр җибәреп эшләп китәләр. Бүген Камал театрында 2 нче студиядән 25 студенттан 5 кеше калса, 1 нче студиядән 80 яшьләрен тутырганнардан 7 артист (22 студенттан 7) исән санала.

Әбүлнең «самостоятельность» күрсәткәне өчен җәза алуы болар белән генә бетми.

Иң көтелмәгәне аны Камал театры директоры вазыйфасыннан алып, күчмә театрга директор итеп билгеләү булгандыр.

Әмма, күндәм кеше буларак, Әбүл әлегә исемсез, бинасыз, режиссерсыз театрга күчеп, үз бинасы, исеме булсын өчен законлы көрәш башлый. Ул көрәш еллары

Тинчурин театры бинасы

һәм юллары турында профессор Илтани Илалова язган китапта барысы да бар. Анда язылганнарны кабатламаска тырышып, үзем күреп белгән кайбер эпизодларны гына язып узам.

Әбүл өчен иң авыры театрның үз бинасын булдыру өчен көрәшкә тотыну булгандыр. Бу көрәш театрның Спас манарасындагы түбәсен давыл куптарып атудан соң башлана. Авырлыкның чигенә җиткән артистлардан бер төркем энтузиастлар партия Үзәк Комитетына хат язып салалар. Тикшерүләр башлана. Әбүл бу хат турында белмәү позасына баса. Төрле комиссияләрнең тикшерүләреннән соң, Татарстан хөкүмәтенә дә театр турында хәстәрлек күрү мәшәкате өстәлә. Профсоюз урамындагы аптекалар складе булган бинаны ремонтлау башлана. Тамаша залы булмаса да, үз бинасы булган театр артистлары өчен тораклар булдыру буенча да директор күп чаба. Нәтиҗәдә, Каюм Насыйри урамында складлар, гараж һәм тулай торак төзелә.

«Күчмә» сүзе бетерелгән театрның утрак тормышка, яңача эшләү режимына күчү чоры башлана. Чегәннәрчә яшәүгә ияләшкән артистларга гел шәһәрдә эшләүгә күчү аерата авыр була. Шул авырлыкларны сәбәп итеп, конфликтлар чыга, директорны гаепләүчеләр баш калкыта, баш режиссер итеп эшкә алынган Рабит Батулланы эшеннән китәргә мәҗбүр итәләр. Театрга Кәрим Тинчурин исемен даулау, Батулла киткәч, Әбүлнең үзенә генә кала. Моның өстенә, Камал театры яңа бинасына күчкәч бушап калган М.Горький урамындагы театр бинасы өчен көрәш башлана. Бу очракта Качалов исемендәге рус театры белән сынашу иң хәтәре була. Чөнки Качалов театры да авария хәлендә, аңа да яшәргә кирәк. Әлеге көрәштә җиңеп чыгуда Роберт Шәрифҗановичның роле гражданлык батырлыгына тиң. Хәер, аның һәр башкарган эше батырлык үрнәге булырлык.

Режиссерлар кытлыгын җиңеп, театрга баш режиссер табу эше дә гыйбрәтле.

2 нче студияне Щепкин училищесына җибәрүгә каршы булган Марсель Сәлимҗанов Вахтангов театры базасындагы Щукин училищесына хәерһак булуын сиздергән иде. Рус театрында эшләгән Рәшит Заһидуллин Щукин училищесының режиссура факультетында укып кайткач, Әбелмәмбәтов аны Тинчурин театры-

на чакыра. Бу аның Марсель Сәлимҗановка җавабы кебек яңгыраса да, Әбүл үчле кеше түгел. Ул күндәм кеше. Күндәмлек роботлыкка охшаса да, дөньяны күндәмнәр өстери.

Үзенә аерым китап язарлык Әбүлгә багышланган язмамны түгәрәкләү өчен, каләмемне аны күргән-белгән, аның кул астында эшләгән артистлардан өч кешегә бирдем. Сүз куешкандай, өчесе дә Әбүлгә мөкиббән.

Әмма сүз озынга киткәнгә, Татарстанның халык артисткасы Ләлә Миңнуллина язмасыннан өзек китерү белән чикләнергә булдым.

«Роберт Шәрифҗан улы Әбелмәмбәтов хезмәт юлын 1966 елда Г.Камал исемендәге данлы театрда актер буларак башлап җибәрә. Аның сәхнә өчен яратылган бик күркәм кыяфәте, таланты халык күңелендә урын алырлык, онытылмаслык образлар тудырырга мөмкинлек бирә. 1978 елдан 1983 елга кадәр Роберт Шәрифҗан улы шул ук театрда директор урынбасары, аннан соң директор булып эшли.

1984 елдан ул – К.Тинчурин исемендәге театрда директор. Театрда директор булып эшләү өчен бик зур көч, тәвәккәллек, осталык кирәк. Иң авыр хезмәтләрнең берседер ул. Аның тышкы матурлыгы эчке дөньясының, күңеленең матурлыгы белән тәңгәл килә. Әдәпле, тәртипле, намуслы – бу сыйфатлар аңа тумыштан бирелгәндер. Аның хезмәттәшләренә кычкырганын, ямьсез, күңелне рәнҗетерлек сүзләр әйткәнен ишеткәнем булмады. Гозере төшкән, ярдәм сорап мөрәҗәгать иткән кешеләргә, ачык йөзле булып, булдыра алганча булышырга тырышты һәм булышты да. Безнең карашка, ул бик тә көчле дипломат һәм оештыру сәләтенә ия эшмәкәр иде. Дәүләт даирәләрендә эшләүче хезмәткәрләр белән сөйләшә, алар белән уртак тел таба белә иде Роберт абый. Театрыбыз бинасыз, режиссерсыз калган чорда да ул югалып калмады. Коллектив белән бергәлектә шушы авыр хәлләрдән чыгу юлларын табып, театрны элек эшләгән туган бинасына кайтарып, Дамир Сиразиев, Рәшит Заһидуллин кебек режиссерлар һәм, әлбәттә, сәләтле артистларыбыз белән театрыбыз иҗат үрләре яулады. Ул республикабызда гына түгел, Рәсәй Федерациясендә дә танылуга иреште.

Роберт Шәрифҗанович гаиләдә дә үрнәк булырдай ир иде. Әле студентка чагымда (ул вакытта Роберт абый Камал театрында артист булып эшли иде) мин алар белән гастрольгә чыктым. Аның тормыш иптәше Сания ханымга булган мөнәсәбәте соклану хисе уята иде. Алар бер-берсен кадерләп, ихтирам итеп, матур гомер кичерделәр. Мәскәү, Ленинград, Екатеринбург, Сургут, Төмән кебек зур шәһәрләрдә уңышлы гастрольләр оештыруы – аның талантлы җитәкче булуына ышанычлы дәлил. Роберт абый бөтен яктан да килгән, бары тик җылы сүзләргә генә лаек Олуг Шәхес».

Инде язмамның исеменә әйләнеп кайтыйк. Бу исемне ишеткәч, миндә конкурсны кем оештырган, хәзер бармы ул конкурс, булса аның элементлары нидән гыйбәрәт, кем аларны саный һәм сайлый дигән сораулар туган иде. Хезмәттәшләре язып биргәннәрне укыгач, сорауларымның һәммәсенә җавап таптым. Аңа бу исемне халык бирүенә инандым. Халык әйтсә, хак әйтә. Аны оныттырып та, җуйдырып та булмый. Шиксез, аны сагыналар, һәр эшен хәтерлиләр. Үзеннән якты истәлекләр генә калдырган кеше онытылмый, үрнәк шәхес буларак, исәннәр күңелендә Алтын йөрәкле кеше буларак яши.

Варисларга күчеп яшәсен Алтын йөрәкле шәхесләр истәлеге. ■

Җуелмас хәзинә

«Бөдрә тал» җыры

«Халык җырлары безнең киләчәктә мәйданга киләчәк әдәбиятымызга, бер дә шөбһәсез, нигез булачактыр».

Габдулла Тукай

Бөдрә тал

(Татар халык җыры)

Талдан талга куна микән
Таң алдыннан сары ла сандугач?

Кушымта:
Бөдрә тал,
Чит җирләргә чыгып гыйбрәт ал!

Җырлау түгел, еларсың да,
Өзелеп-өзелеп кенә лә сагынгач.
Кушымта.

Сары сазлык, һай, селкенчәк,
Борыла-сарыла үсә бөдрә тал.
Кушымта.

Бөдрә таллардай боргаланып,
Нишләп йөри икән лә безнең яр?!.

Кушымта:
Бөдрә тал,
Чит җирләргә чыгып ла гыйбрәт ал!

Бу җырны заманында Разия Тимерханова (1918-1997) башкаруында тыңлый идек. Әлеге җырның берничә варианты бар. Тагы берсе мондый:

Талдан талга кунып сайрый микән
Таң алдыннан сары ла сандугач?
Сандугачлар тавышы моңлы икән,
Сөйгәнеңне өзелеп сагынгач.

Кушымта:
Бөдрә тал,
Чит илләргә чыгып гыйбрәт ал!

Ак аргамаккаем, һай, печән ашамас,
Иярләсәң, биле дә бушамас.
Кай илләргә барсаң да, бер үк кояш,
Туган-үскән җиргә лә охшамас.
Кушымта.

Агыйделкәйләрне, һай, кичкәндә,
Аюлар күрдем аргы якларда.
Туган илкәемне сагынып җырлыйм,
Чит илләрдә йөргән лә чакларда.

Кушымта:
Бөдрә тал,
Чит илләргә чыгып гыйбрәт ал!

«Бөдрә тал» җырын башкаручыларның берсе – Разия Тимерханова (1918-1997). Аның әти-әнисе – Кама Тамагының Олы Карамал (Олы Карамалы) авылыннан: әтисе Дәүләтша – «Зингер» тегү машинасын төзәтү остасы, әнисе Гыйззениса исә кубыз, курай һәм гармунда оста уйнаучы булган. Р.Тимерханова җырлаган җырларның кайберләре: «Агач башы», «Бакалы», «Камәр», «Зиләйлүк», «Тәфтиләү», «Сакмар су», «Зөбәрҗәт», «Таң атканда», «Кар суы», «Сибелә чәчәк», «Бөдрә тал», «Салкын чишмә», «Каз канаты». Җырчы «Кәләү Гайшә», «Кылый кантон» кебек онытылып барган борынгы озын көйләрне дә башкара һәм аларны тасмага яздыра.

(Сәхифәне, «Тәртип» радиосында яңгыраган «Саф вә раушан күзге» тапшыруы (авторы һәм алып баручысы – Гөлфия Мөхәммәтгәрәева) материалларына нигезләнеп, Ләбиб Лерон әзерләде. ■

ТАТАР ҖЫРЧЫЛАРЫ. КАДЕРЛЕ МИЗГЕЛЛӘР

Әлфия Галимова 1922 елның 30 маенда Кама Тамагы районындагы Олы Карамалы авылында туган. Мәгърифәтче Садыйк мулла нәселеннән ул. Заманында аның бабасы Садыйк авылда мәктәп ачып балалар укыта. Анда Әлфиянең әтисе Әхәт тә белем ала, аннан укытучы була. Әнисе Шәмсеҗиһан татар балаларына рус теле укыта.

Чистай шәһәрендә яшәгән вакытта әнисе Әлфияне укытучыларның мәгърифәт клубында эшләүче җыр түгәрәгенә алып бара. Шунда кызчык беренче тапкыр композиторлар әсәрләрен, симфоник музыка ишетә, фортепианода уйнарга өйрәнә.

1944 елда ул Казанга килә һәм театр янында «Мәскәү консерваториясе каршындагы опера студиясендә уку өчен җырчылар сайлау бара» дигән игъланга күзе төшә. Ул Н.Җиһанов, М.Мозаффаров, А.Измайлова кебек күренекле шәхесләрдән торган комиссия алдында Мансур Мозаффаровның

Татарстанның халык артисты Әлфия Галимова минем өчен ачылмаган исем. Аның хакында аз ишеткәнмен. 2015 елның 25 мартында вафат булды ул. Мин, бертөркем артистлар белән, аны соңгы юлга озатырга бардым. Казанның үзәктән ерак почмагында бер бүлмәле җыйнак кына фатирда яшәгән ул. Җиһазлары да берничә дистә ел яшәгән, тыйнак җиһазлар иде. Фатирының гаҗәеп җыйнаклыгы, тузан бөртеге дә булмаган чисталыгы истә калган. Без килгәндә фатирда 15ләп кеше бар иде, арада ике ханым туктаусыз елыйлар. Бераз тынычланган күк булалар да... кабат еларга тотыналар... Соңыннан белдем: Әлфия апаны чиратлап караган, тәрбияләгән ханымнар икән алар. Җырчының хәле начарлангач, туганнары ярдәмгә бу ике ханымны чакырганнар. Алар Әлфия апаны яратканнар, бик яхшы карап, тәрбияләп торганнар. Берсе туктаусыз: «Аның кебек яхшы кешене минем беркайчан да очратканым юк иде. Шулкадәр әйбәт иде бит ул», – дип кабатлады...

Әлфия Галимова һәм Рөстәм Яхин. Мәскәү, Тимерьюлчылар клубы

Әлфия Галимова Алтынчәч ролендә

Муса Җәлил сүзләренә язган «Җиләк җыйганда» дигән җырын башкара, икенче һәм өченче турларга узып, югары бәяләнә. Мәскәүгә укырга керергә теләүче 400 кеше арасыннан егерме бише генә сайлап алына. Алар арасында Әлфия Галимова да була.

Мәскәү консерваториясенең татар опера студиясе. Җитәкчеләре А.Измайлова (утырган), сулдан: А.Шәнгәрәева, М.Ханов, В.Жарков, Ә.Галимова. 1950 ел

«1950-1961 нче елларда Әлфия Галимова Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет театры солисты була. Кыска гына вакыт Казан музыка училищесында укытып ала. Ә 1966 елдан 1986 елга кадәрге иҗат эшчәнлеге Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе белән бәйле аның.

Концертларда төрле опералардан катлаулы арияләр, аерым күренешләр, романслар җырлый Әлфия Галимова: Н.Җиһановның «Алтынчәч» операсында – Алтынчәч, Җ.Фәйзинең «Башмагым»ында – Сәрвәр, Дж.Россининың «Севилья чәчтарашы»нда – Розина, Глинканың «Иван Сусанин»ында – Антонида, Ш.Гуноның «Ромео һәм Джульетта»сында – Джульетта, Н.Римский-Корсаковның «Кар кызы»нда – Кар кызы партияләре. Җырчының аңа гына хас үзенчәлекле ягы – ул татар халык җырларын аеруча зур профессиональ осталык белән башкарган. Аның репертуарында «Уел», «Зөбәрҗәт», «Бөдрә тал», «Әллүки» һәм халкыбызның борынгы, озын, катлаулы башка җырлары урын ала. Ә «Гөлҗамал» шулар арасында иң уңышлысы.

Татарстанның халык язучысы Гомәр Бәширов еллар буе Татарстанның халык артисты Әлфия Галимовага хатлар язып тора. Хатларында – киңәшләр, фикерләр, соклану. Бер хатында мондый юллар бар: *«Мәгълүм ки, «Гөлҗамал»ны башкалар да җырлыйлар. Минемчә, бу җырдагы моңның иң нечкә нюансларын, иң нәфис һәм шул ук вакытта иң тетрәткеч борылышларын Сез һәммәсеннән дә тирәнрәк, күңелгә үтемлерәк итеп бирә аласыз...»*

Кемнәрне беләбез без? Музыкаль талымыбыз кайсы җырчыларны тыңлап формалаша? Барысы да үзебездән тора...

Сулдан: М.Имашев, М.Галиев, С.Гарифуллин, Ә.Галимова, Ф.Вәлиева. 1976 ел

Көлке куа килә...

Гаҗәпләнү

(Халык мәзәге)

Монголиядә Диңгез флоты министрлыгы булдырырга җыеналар икән. Безнекеләр бу уңайдан бик гаҗәпләнгән:

– Ник кирәк ул сезгә? Сездә диңгез юк бит!

– Нучтуж! – дигән монголлар. – Сездә Мәдәният министрлыгы бар бит әле.

Тәлгат Нәҗмиев (1950-2014)

Хәзер дә шулай

(Мәзәк)

1983 елда Горькийдагы Югары партия мәктәбе базасына бер айлык редакторлар курсына җибәрделәр. Кайбер көннәрдә экскурсияләр дә оештыралар иде. Менә шулай Горький (Түбән Новгород) шәһәренең тарихи Кремле белән таныштырып йөриләр. Гид сөйли:

– Бу Кремль татар-монгол яуларыннан саклау өчен салынган. Алар бик явыз, усал булганнар...

Әлбәттә, бу төркемдә татарлар барын гид белмәгәндер. Шунда Татарстан телевидениесе редакторы Мөкатдәс Йосыпов түзмәде:

– Мы и сейчас такие! – дип кычкырып куйды.



«Фәнни коммунизм кафедрасы һичнинди җәмәгать эшендә, өмәләрдә катнашмаган студентларны «бишле» билгесенә аттестацияләгән...»

Студент:

– Аттестациялисезме? Бирегез бишне!..

«Тарих-филология факультетын ике мөстәкыйль факультетка бүлүгә әзерлекле кадрлар җитешмәве дә комачаулык тудыра...»

«Кафедра партгруппалары белән студент партгруппалары арасында бәйләнеш йомшак...»

«Өсталләрне студентлар пычратып бетергәннәр».
Яз:
– Язма!

Шаян рәсемнәр Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы студентлары чыгарган «Әдәби сүз» дигән дивар газетасыннан (баш редакторы – галим, әдәбиятчы, фольклорчы, профессор Марсель Бакиров) алынды. 1980-1990 нчы еллар.
*(Рәсемнәр авторы – **Марсель Бакиров**.)*

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

Без барыбыз да – балачактан

«Балачак мирасы» сәхифәсе – иң әүвәл сезнең өчен, өлкәннәр. Халкыбызның күңел җәүһәрләрен – такмак-такмазаларны, табышмак-башваткычларны, әкиятләрне, әдипләребезнең хикмәтле һәм гыйбрәтле, мәгънәви һәм тәрбияви әсәрләрен хәтерегезгә сеңдерегез, аларны озын-озакка сузмыйча, балаларыгызга һәм оныкларыгызга җиткерегез, нәниләргә бишек җырларын көйләргә дә онытмагыз. Кыскасы, укыгыз, уйланыгыз һәм бер нәтиҗә ясагыз да... һәрвакыт безнең «Балачак мирасы» белән бергә булыгыз!

Каюм Насыйри (1825-1902)

Комсыз эт

(Мәсәл)

Авызына сөяк капкан бер эт күпердән чыкканда суда үзенең шәүләсен күрде. Үзе кебек ул эт тә авызына сөяк кабып йөгереп бара икән. Ләкин аңар судагы этнең сөяге зуррак кебек күренде. Шунлыктан, үзенең авызындагы сөякне суга төшерде дә, үзе суда күренгән эт авызындагы сөякне алмакчы булып, суга сикерде. Ләкин ул арада инде авызындагы сөяге дә су төбенә киткән иде.

Зәкия Туфайлова (1907-1977)

«Әни» сүзе

«Әни» диеп язып куйдым
Яңа яуган ак карга.
Таптамагыз!
Һич ярамый
«Әни» сүзен таптарга.

Сакау кызлар

(Мәзәк)

Бер әбинең өч кызы булган. Өчесе дә сакау сөйләшә икән. Беркөнне боларга кунак килгән.

Әби кызларына:

– Сөйләшмәгез, тик кенә утырыгыз, кунак сезнең сакау икәнегезне белеп китмәсен, – дигән.

Менә берзаман казанда ботка кайный башлаган. Әби моны күрмәгән. Олы кызы түзмәгән, әйткән:

– Быкый-быкый ботка тачый, богатсагыз ни буя? – дигән.

Икенчесе:

– Әни, чүләчмә, диде ләбача, тик утычаң ни буя? – дигән.

Кече кыз:

– Кем тәчсә дә, мин тәчмәм! – дигән ди.

Шулай итеп, кунак бу кызларның сакау икәнлекләрен белеп, өенә кайтып киткән.

Тизәйткечләр

(Кат-кат әйтергә)

Башта башлап баскыч башына бас. Баскыч башына басканда башыңны бәрмә.

***

Бүрәнәгә басты бүдәнә,
Бүдәнәне басты бүрәнә,
Гаеп бүрәнәдә дә бар,
Бүдәнәдә дә бар.

Әхмәт Гадел (1942-2012)

Бишек җыры

Ай, нәни

Күк күгәрчен очадыр,
Зәңгәр күкне кочадыр.
Минем улым бәү-бәү итә,
Йолдызларда очадыр.

Әлли-бәлли бәү, нәни,
Йоклап китәр бу бәби.
Җылы моңнар канатында
Үсеп җитәр бу нәни!

Күгәрченнәр күкләрдә,
Төшәләр җим чүпләргә.
Үсеп җиткәч, минем улым
Үрнәк булыр күпләргә.

Күгәрченем-йолдызым,
Минем йомшак кондызым!
Әкиятләр кочагында
Назланырсың төнозын!

*Сәхифәне **Ләбиб Лерон** әзерләде.* ■

ОКТЯБРЬ

Фотолар һәм видео beznenmiras.ru сайтында

● 4 октябрьдә Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә күренекле шагыйрә Саҗидә Сөләйманованың (1926-1980) тууына 95 ел тулу уңаеннан, театр артистлары һәм җырчылар катнашында, әдәби-музыкаль кичә (режиссеры – Илдар Хәйруллин) булып узды.

● 7 октябрьдә «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон һәм журнал хезмәткәре Ленар Гобәйдуллин Кама Тамагында эшлекле сәфәрдә булды. Алар район хакимияте башлыгы Наил Альберт улы Вазыйхов белән очрашты, районның туган якны өйрәнү музеенда һәм татар әдәбиятының классигы Ибраһим Газиның (1907-1971) туган авылы Олы Карамалыда булдылар. Редакция хезмәткәрләрен Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Газинур Габидуллин озатып йөрде.

● 7 октябрьдә Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы даими вәкиллеге Федоровка районының Каралачык авылы мәктәбе китапханәсенә татар телендәге йөзгә якын китап һәм газета-журналлар бүләк итте.

«Татар телендә чыккан китаплар, «Казан утлары», «Безнең мирас», балалар өчен «Сабантуй» басмалары – барлыгы йөзгә якын китап һәм газета-журналлар тапшырдык, – диде Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстандагы даими вәкиллеге җитәкчесе, Уфаның «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Альфред Дәүләтшин.

● 10 октябрьдә сәясәтче, 1990-1995 нче елларда Татарстан парламенты депутаты, РФ Дәүләт Думасының өченче чакырылыш (1999-2003) депутаты, Азнакай районының Мәлбагыш авылы тумасы Фәндәс Сафиуллин сиксән биш яшендә вафат булды.

● 13 октябрьдә Екатеринбургта герой-шагыйрь М.Җәлилгә бюст ачылды. Чарада Бөтендөнья татар конгрессының Милли Шура рәисе Васил Шәйхразыев катнашты.

● 14 октябрьдә Буа дәүләт сатира театры җитәкчесе, Татарстанның халык артисты Раил Илдар улы Садриевка нисбәтле «Сез әле мине белмисез» дигән шигъри-музыкаль кичә узды. Юбилярны Татарстан Мәдәният министры урынбасары Ленар Хәкимҗанов, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, нәфис сүз остасы Җәвит Шакиров, җырчылар Салават Фәтхетдинов һәм Фирзәр Мортазин котлады.

● 15 октябрьдә Казанның Тинчурин скверында җәмәгатьчелек Хәтер көнен билгеләп үтте. Быелгы искә алу чарасына килгән зыялылар арасында татар язучылары шактый иде.

● 15 октябрьдә Татарстан мөфтиятендә Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән Мөхәммәд бин Зәйед исемендәге Гуманитар фәннәр университеты ректоры Халид әл-Йабхуни җитәкчелегендә делегация килде. Мөхтәрәм кунакларны мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин каршы алды. Ул, университет җитәкчелеген «Хозур» нәшрияты бастырган китаплар белән таныштырып, истәлеккә гарәп телле басмаларны бүләк итте.

● 18-22 октябрь көннәрендә «Безнең мирас», «Казан утлары» журналлары һәм «Мәдәни җомга» газетасы баш мөхәррирләре Ләбиб Лерон, Рөстәм Галиуллин һәм Вахит Имамов, Оренбургта (Абдуллино районында), Чиләбе өлкәсендә (Кизилдә, Аркаимда) һәм Башкортстанда урнашкан татар һәм башкорт авылларында, аерым алганда, Аетта (абыйлы-энеле Ярлы Кәрим һәм Фатих Кәрим туган авыл), Дусәндә (К.Хәкимов), Туксанбайда (Акмулла), Тормайда (биредә язучы Х.Исмәгыйлев яши), Эстәрлебашта (З.Зәйнуллин), Җиргәндә (Дәрдемәнд, М.Әмир, Г.Шәрәфетдинов), Акман-Ибрайда (С.Рәмиев), Моракта, Морадымда, Баймакта (монда М.Фәйзи җирләнгән), Сибайда, Темәстә, Инзердә, Архангелдә, Кырмыскалыда, Кушнаренкода һәм байтак кала-салаларда булып, атаклы шәхесләребезгә нисбәтле истәлекле урыннарны күреп кайтты. ■

МИРАСВОРД

Шарль ... (француз әкиятчесе)

Габдулла Тукайның 1907 елда язган шигыре

Афзал Шамов повесте

Хәмит ... (фольклорчы, әдәбият галиме)

Изге, бөек, хөрмәтле

... Акопян

Көтү, күрергә теләү (диал.)

Әкиятләрдә: бик кечкенә фантастик зат

Ыргыту, ташлау

... Сакаева

1913-1914 елларда Казанда татарча чыккан тәрбияви-педагогик журнал

Сәгыйть Рәмиев шигыре

Алтын ... дәүләте

Тәртипләп өелгән утын

Урылган игеннең бер бәйләм итеп җыеп бәйләнгән сабаклары

Диңгез төбеннән энҗе җыючы

... Туишева

Рахит (иск.)

һәм (иск.)

Куе кызыл төс

Әйттем ... кайттым

Мишәр абзые

Чуаш шагыйре Константин Иванов поэмасы

Шагыйрь ... Кари

... Юзиев (әдәбият галиме, тәнкыйтьче)

Язучы ... Хафизова

... сакчысы

Татарстан-дагы район

Жай, уңай, көй

Танылган рус язучысы

Борынгы Рим императоры

Ркаил Зәйдулла пьесасы

Телсез (диал.)

Билгеле бер вакытта укылырга тиешле дога, аять

Католик рухание

Чехия каласы



Композитор ... Мөлеков

«...-Артур» (башкорт һәм татар халык җыры)

Аз санлы төрки халык

Җәвәхарлал ...

10 нчы санда дөнья күргән мирасвордның җаваплары:
Султан уңга: санам, «Ләгу», каноэ, Әлмән, Лаисов, Баян, «Мират», оран, стан, әвен, Азат, Аван, әбәк, җар, юка, Муса, АИ, Арсланов, Әхәт, рапа, «Ра», рәмел, Вәли, Хисам.
Өстән аска: Әлмөхәммәтов, бу, Марс, Әсхәр, «Атака», Таҗи, сәкен, «Таз», ага, Наҗар, нун, лар, ТАИС, ая, Мөэминова, Гарәфи, ревю, нам, очанак, опера, нарвал.

Рәис Габдулла төзеде.

«Безнең мирас»
елъязмасы / ноябрь

Баку шәһәре. XIX гасыр. ***Фотосурәт news.cision.com сайтыннан алынды.***

625 ел элек (1396)

Моңа кадәр Алтын Урданың бер олысы саналган Кырым мөстәкыйль ханлыкка әверелә башлый. Бу вакытта Кырым белән идарә итүче Туктамыш ханның ныгып китүе Сарай белән Хаҗитарханны кулга төшергән, Азак-Тын (Дон) далаларын үз кулында тоткан Тимер Котлык белән Идегәй морза өчен бик җитди мәсьәләгә әверелә.

180 ел элек (1841)

Татар телендә беренче басма календарь нәшер ителә. Автор-төзүчесе – тәрҗемәче Рәхмәтулла Әмирханов.

115 ел элек (1906)

Ноябрь аеннан Баку шәһәрендә «Феюзат» (Муллык) исемендә милли-мәдәни вә рәсемле атналык журнал чыга башлый. Нашире – миллионер Зәйни Тагиев, мөхәррире – Галимбәк Хөсәензадә.

100 ел элек (1921)

Татарстан Үзәк Башкарма Комитеты президиумы «Ачлык» исемле әдәби җыентык чыгару турында карар кабул итә. Бу җыентык, «Ачларга әдәби ярдәм мәҗмугасе» исеме белән, 2 китап булып, 1922 елда дөнья күрә. Редакторлары – Галимҗан Ибраһимов һәм Фәтхи Бурнаш.

95 ел элек (1926)

20-25 ноябрьдә Казанда «Хәреф киңәшмәсе» эшли. Нәтиҗәдә, 1926-1927 нче елларда татар телендә дәреслекләр чыгарганда куллану өчен, гарәп имласында 30 хәрефтән торган Әлифба кабул ителә.

55 ел элек (1966)

3 ноябрьдә башкалабыз Казанда Муса Җәлилгә һәйкәл ачыла.

50 ел элек (1971)

21 ноябрьдә язучы Сөббух Рәфыйков (1913-1971) вафат була.

Журналга ***Марат Закир*** *әзерләде.* ■

Содержание. Ноябрь 2021

И останется в мире слово моё...: Ибрагим Гази.

Историческое наследие: «Способ плавления стали «Татара»: история и технология». Я.Мураками; «Кто такой Гуркин?». З.Мухамметшин; «Страшный голод». Р.Шарафиева и Л.Губайдуллин; «Татарские благотворительные общества». Дж.Миннуллин.

Татарский мир: «Сохраним наследие Казаковых!»; «Наиль Вазихов: «Оставление молодёжи в деревне имеет очень важное значение».

Литературное наследие: «Стамбулское издание сочинений великого поэта Котб (1968)». Х.Миннегулов; «Он был личностью, достойной восхищения». Э.Шарифуллина.

Религиозное наследие: «Исламский мир». Габдурашит Ибрагимов; «Уроки религии». С.Бикбулат.

В глубинах памяти: «Горжусь своими наставниками». А.Хайри; «В памяти, до сих пор в памяти!».

Художественное наследие: «Татарские певцы. Дорогие мгновения». З.Гильмутдинова.

Журнал регулярно освещает все значимые события в жизни нашей нации.

Алхәбәр:

Кырым күренеше («Кырымга сәфәр». *Л.Лерон)*

Әдип авылдашлары

Фотоларда – язучы, Г.Тукай исемендәге ТР дәүләт премиясе лауреаты **Ибраһим Гази**ның туган авылы – Кама Тамагы районының Олы Карамалы кешеләре

Олы Карамалы авылы күренеше

Мәктәп укучылары тәҗрибә участогы өчен тирес төйи.

«Большевик» колхозының идарә бинасы



Мәктәптә физик тәрбия дәресе

Садыйк мулла балалары: Галимов Кәбир (ветврач), Галимов Мәлик (ТАССРның атказанган врачы), Галимова Фәридә (табибә). 1940 ел

«ИДЕЛЛӘРЕ, ИДЕЛЛӘРЕ, ИДЕЛЛӘРЕ-КҮЛЛӘРЕ, ШУЛ».

Лобач тавы. XX гасыр башы
Фото Кама Тамагының туган якны өйрәнү музее фондыннан алынды.

Лобач тавыннан Идел елгасы һәм Кама Тамагы күренеше

ИНДЕКС:
ТАТАРСТАНДА – П2343
РОССИЯДӘ – П7074
beznenmiras.ru

«БЕЗНЕҢ МИРАС»
журналына башкача язылу:

- *uslugi.tatarstan.ru* сайты ярдәмендә
- редакциядә
- *podpiska.pochta.ru* сайты ярдәмендә

4 612750 670172

«БЕЗНЕҢ МИРАС» журналын башкалабыз Казандагы «Книги-Китаплар» кибетеннән (Бауман ур., 19 һәм 51), «ТАТМЕДИА» бинасының китап кибетеннән (Декабристлар ур., 2), республикабыз киоскларыннан сатып алырга мөмкин.